Безнең МИРАС

02

февраль 2015

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Татарстан Республикасы Президенты
РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:

«Тарихыбызда халкыбыз горурланырлык, даны еракларга таралган олы шәхесләр аз түгел. Без аларны якын итеп «Тукаебыз», «Җәлилебез» дип йөртәбез. Татар халкының бүген дә аларга тиң шәхесе бар.
Ул – Илһам Шакиров. Бөтен дөньяга таралган татар кешеләре аны яратып, үз итеп «Илһамыбыз» дип йөртә. Әйе, Илһамыбыз безне бер-беребезгә якынайта, туганлаштыра, бөек моңы белән безне бер гаиләгә җыя. Афәрин, Илһамыбыз!»

Илһам Шакировка – 80 яшь!

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдмәнд

Безнең Мирас 12 +
02(37)
февраль 2015

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды. 2012 елның май аеннан чыга.



78

21 «ЧЫҢГЫЗ БАЛАСЫ» ГАЗЕТАСЫ. *Ленар Гобәйдуллин*

107 БЕЛӘЗЕГЕМ, ЙӨЗЕГЕМ... *Руфия Мөхетдинова*

ЭЧТӘЛЕК

2015 ЕЛ — РОССИЯДӘ ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

3 **Алла.** *Сәгыйть Рәмиев*

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

4 **Айрат Сибагатуллин: «Мин Республикада мәдәниятнең киләчәгенә зур ышаныч белән карыйм...»** *Ләбиб Лерон әңгәмәсе*

ТАРИХИ МИРАС

10 **«Инде алмаган ни калды?»**
16 **Кем ул Морад мулла?** *Раиф Мәрданов*
21 **«Чыңгыз баласы» газетасы.** *Ленар Гобәйдуллин*
28 **Кемнәр соң без — татарлар?** *Рабит Батулла*

ПЕДАГОГИК МИРАС

34 **Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, дигән сүз — раст сүз**

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

44 **Батырлыкның йөзе нинди?** *Ләйлә Минһаҗева*
47 **Кардәшлеккә чикләр юк!** *Ильмира Камаева*

ҖИҢҮ — 70!

48 **Кара генерал.** *Рәис Зарипов*
58 **Әткәм сурәте.** *Фоат Галимуллин*

ТАБИГЫЙ МИРАС

61 **Зөбәрҗәт күле**

ӘДӘБИ МИРАС

62 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Йосыф Баласагуни*
68 **«Миңа тигән зәһәр җилләр...»** *Марсель Әхмәтҗанов*
72 **Фазыл Туйкин шигырьләре һәм халык җырлары.** *Әнвәр Шәрипов*
78 **«Җанда ул безнең, йөрәктә, бәгырьдә...»** *Рифә Рахман*
82 **Ачы тәҗрибә авазы.** *Габдулла Тукай*
84 **Атнабай канаты астында.** *Марат Кәбиров*
89 **Фәтхи Бурнаш яктылыгы.** *Нәкыйп Каштанов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-
җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр Комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары — ТР фән һәм мәгариф министры)
Фәрит Шаһиәхмәтов
(«ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
Рүзәл Мөхәммәтшин
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы,
2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

95 **Тукай энциклопедиясе.** *Зөфәр Рәмиев*

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

96 **Һавадагы торна**

СӘНГАТИ МИРАС

100 **Үзебезнең Илһам**

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

102 **Миллият сүзлеге.** *Адлер Тимергалин*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

107 **Беләзегем, йөзегем...** *Руфия Мөхетдинова*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

108 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның февраль ае.** *Ленар Гобәйдуллин*

СПОРТ

112 **Татарлар бар җирдә — батырлар бар!**

ШАЯН МИРАС

116 **«Тыңгысыз каләм» битләреннән**

119 **Мирасворд**
120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Февраль*

Заказ №О-247. Тираж — 1572 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 3.02.2015
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Ленар Гобәйдуллин төшергән, Абдулла Дубин, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Тышлыкның 1 нче битендә — «Сөембикә». 1987-1998 ел. Киндер, майлы буяу. *И.Зарипов рәсеме.*

Сәгыйть Рәмиев
(1880-1926)

АЛЛА

Кем ул — белмим вә нәрсәдер,
Белмим дип юл да эзләнмим,
Мәгәр аннан бүтән затка
Җегенмим мин вә тезләнмим.

Олуг дим мин аны һәм ул
Мине аңлар вә ишетер дим,
Ни сөйлим йә ни уйлыйм, ул
Йолыр, онтыр вә кичерер дим.

Була үпкәм аңа бәгъзан,
Дүнәм хәтта, җитәм чиккә,
Тәмам иркә, очынган бер
Бала төсле китәм читкә.

Ләкин күңлем аны һәр дәм
Үз иткән, ул даим бергә,
Газап чикмәс җаным бер дә,
Мәгәр чиксә чигәр бергә.

Мөкатдәсмен, әминмен бар
Көфердән, бар гөнаһлардан,
Аяк баскан җирем барсы
Гөлстан бер, җиланлардан.

Кем ул андый, сәгыйд иткән
Мине һәм урнымы, белмим,
Беләм тик: бу җаным аннан
Яратылган, мин — ул, ул — мин. ■

1908-1910

Мөкатдәс — изге, бөек
Әмин — имин, ышанычлык
Җинан — җәннәтләр, җәннәт шикелле пакь урыннар
Сәгыйд — бәхетле

Е.Гредюшко фотосы

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЫ
АЙРАТ СИБАГАТУЛЛИН:

«МИН РЕСПУБЛИКАДА МӘДӘНИЯТНЕҢ КИЛӘЧӘГЕНӘ ЗУР ЫШАНЫЧ БЕЛӘН КАРЫЙМ...»

– Айрат Миңнемуллович, Сез — данлыклы, тарихи Саба төбәгендә туып-үскән шәхес. Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетын тәмамлавыгыз да очраклы түгелдер. «Безнең мирас» журналы да юктан гына Сезгә мөрәҗәгать итмәде: халкыбызның ерак гасырларга барып тоташкан бәяләп бетергесез бай мирасын барлауда нинди эшләр башкарыла?

— 2014 ел Россия Федерациясендә һәм Татарстанда Мәдәният елы булып үтте. Ә 2015 ел — Әдәбият елы. Мәдәният елында иң зур вакыйгаларның берсе — Болгар тарихи-археология комплексының ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелүе. Бу — зур горурлык. Болгарның ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелүе турындагы сертификатны Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановка оешманың генераль сәркатибе Ирина Бокова үзе тапшырды. Ул шушы борынгы изге урын биләмәләрендә булганнан соң гына, Болгарның бүгенге һәм киләчәк буын өчен әһәмиятен аңлавын ассызыклады. Димәк, безнең инде ике музей комплексы ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегендә. Казан Кремленең шундый дәрәҗәле исемгә ия булуы исә Татарстан башкаласының истәлекле урыннары белән танышырга теләүче туристлар санын арттырган иде. Республикада Зөя утрау-шәһәрчеген ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертү буенча да зур эш башкарыла. Күптән түгел генә Татарстан Республикасында «Зөянең тарихи-мәдәни һәм рухи мирасы» халыкара фәнни-гамәли конференциясе булып узды. Пленар утырышта Җөмһүриятебезнең Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә катнашты. Конференциянең максаты — Зөянең тарихи-архитектура һәм рухи мирасын өйрәнү, аны саклап калу, төзекләндерү, мәдәни мирас корылмаларын популярлаштыру һәм алар белән идарә итү алымнарын барлау.

Республикабызда 1516 объект дәүләт тарафыннан саклана, 565 объектның мәдәни мирас буларак кыйммәте билгеләнгән, 98 объектта мәдәни мирас билгеләре бар. Татарстанның тарихи-мәдәни корылмаларны саклау, өйрәнү һәм популярлаштыру буенча хезмәте Россия Федерациясендә генә түгел, чит илләрдә дә яхшы билгеле. 2015 елның 5 гыйнварында ТӨРКСОЙның штаб-фатирында Дүсән Касеинов белән булган очрашуда Ирина Бокова да Татарстанның үз мирасына сакчыл карашы турында әйтеп үтте.

Шунысын да ассызыклап кую кирәк — мәдәни мирасны саклау чаралары бөтен республикада киң җәелдерелгән: Әтнә, Арча, Яшел Үзән, Мамадыш, Менделеев, Саба, Спас, Тәтеш, Ютазы һәм башка районнарда актив эш бара. Үткән ел Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәби музей-тыюлыгы ачылды. Әлеге шәһәр тиңдәшсез мәдәни мираска ия: кала үзәге гаҗәеп архитектуралы тарихи йөзен саклап калган, район территориясендә 144 мәдәни-мирас объекты, 250 археология һәйкәле бар. Чистай А.М.Бутлеров, Б.Л.Пастернак, А.А.Фадеев, Л.М.Леонов һәм башка бөек шәхесләрнең исемнәре белән дә кадерле. Сүз уңаеннан, быел Нобель премиясе лауреаты, бөек урыс язучысы Борис Леонидович Пастернакның тууына 125 ел тула, Чистайда язучының мемориаль музее ачылганга да 25 ел була.

Бүгенге көндә, глобализацияләү процессы заманында, халкыбызның мәдәни мирасын саклау иҗтимагый һәм сәяси әһәмияткә ия. Татарстан Республикасында «Мирас — Наследие» комплекслы программасы эшли. Әлеге программа безгә дәүләт саклавында булган күчемсез милек белән беррәттән, матди булмаган мирасыбызны саклау өчен күп эш башкарырга ярдәм итә.

Р.Нәҗмиев фотолары

Мәсәлән, семинарлар уздырыла, укыту-методик әсбаплар әзерләнә; йола һәм бәйрәмнәрне актуальләштерүгә юнәлтелгән методик фильмнар дөнья күрә. Бу өлкәдәге эшчәнлекне Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге башкара: халык биюләре өйрәнелә, музыка уен коралларын халыкка кайтаруга багышланган чаралар күрелә. Күптән түгел генә татарларга хас үзенчәлекле уен коралы — аһәңле гөсләдә уйнау традициясен югалып бара, дип борчылган идек. Хәзер гөсләдә татар көйләрен яңгыратучылар саны көннән-көн арта. Мәсәлән, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты һәм Казан дәүләт консерваториясе каршында барлыкка килгән ансамбльләрне билгеләп үтәргә кирәк. Курай, кубыз кебек уен коралларына музыка мәктәпләрендә укучыларыбыз да битараф түгел. Димәк, алга китеш бар. Бүгенге көндә республикабызда яшәүче җирле халыкларның рухи байлыгын барлау, тикшерү, исәпкә алу эше оештырылды. 2015 елда республика күләмендә каталог та булдырырбыз, дип өметләнәм.

— Казаныбызның меңьеллыгын бәйрәм итәр алдыннан башкалабызда бөек шәхесләргә багышланган һәйкәлләр ачылды. Халкыбыз яшәгән төбәкләрдә һәм илләрдә Габдулла Тукайга да таш сыннар булдырылды. Бу җәһәттән алга таба ниләр эшләнәчәк, кайсы бөек шәхесләребез һәйкәл рәвешендә мәңгеләштереләчәк?

— Халкыбыз үзенең бөек шәхесләрен таш сыннарда мәңгеләштерүгә җитди карый, шуңа да без җәмәгатьчелек алдында җаваплылык тоеп эшлибез. Тиздән башкалабызда күренекле шәхесләребез Рөстәм Яхинның, Һади Такташның һәм Сара Садыйкованың һәйкәлләре барлыкка киләчәк. Кама Тамагында классик драматургыбыз, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинга бюст куелачак. ТР Мәдәният министрлыгы адресына җәмәгатьчелектән тәкъдимнәр килеп тора, алар махсус комиссия утырышларында карала, халкыбызның күренекле шәхесләрен һәйкәл итеп мәңгеләштерү буенча актив эш бара.

— 2014 елда Казан — Төрки дөньяның мәдәни башкаласы, дип игълан

ителде. Мәдәният министрлыгы ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы белән берлектә бу чараны югары дәрәҗәдә оештырды. Сез үзегез канәгатьме?

— Төрки мәдәниятләрнең ТӨРКСОЙ Халыкара оешмасы тарафыннан Казанга 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы статусы бирү — татар халкының бүгенге дөнья мәдәниятенә керткән өлешенең әһәмиятен тану ул. «Казан — төрки дөньяның мәдәни башкаласы» программасы бар гуманитар өлкәләрне үз эченә алган 16 чараны берләштергән иде. Программаны ачу тантанасы 2014 елның 26 апрелендә Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры сәхнәсендә ТӨРКСОЙ исемлегенә кергән дәүләтләрнең иң танылган сәнгатькәрләре чыгышы белән башланып китте. Татар кешесе өчен 26 апрель зур мәгънәгә ия: бу — милләтебезнең бөек шагыйре Габдулла Тукай туган көн. «Казан — мәдәни башкала» программасы кысаларында фәнни форумнар, фестивальләр, концертлар һәм симпозиумнар үткәреп, без татар халкының мәдәни традицияләрен төрле яклап күрсәтә алдык. Масштаблы Халыкара фәнни форумнар — Болгар форумы, II Музей форумы, «Төрки дөньяның мәшһүр мәгърифәтчеләре Мехмет Акиф Эрсой һәм Габдулла Тукай» симпозиумы, төрки халыкларының матди булмаган мирасына, төрки дөньяның әдәбияты һәм музыкасы чыганаклары мәсьәләләренә багышланган конференцияләр уздырылды. Казан Федераль университеты, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Мехмет Акиф Эрсой исемендәге Фәлсәфә һәм сәнгать фонды, Аурупа музейлары Академиясе, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты, Н.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе, Татарстан Республикасы Милли музее, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге һәм башка оешмалар әлеге проектларның партнёрлары булды. Программа чаралары уңаеннан 800дән артык галим Казанга килеп китте. 21 ноябрьдә «Казан — төрки дөньяның мәдәни башкаласы» программасын ябу тантанасы — ТӨРКСОЙ оешмасына кергән илләрнең мәдәният министрла-

ры Советының чираттагы XXXII утырышы һәм II Халыкара җыр бәйгесе — «Төрквидение — 2014» булып узды. ТӨРКСОЙның Генераль сәркатибе Дүсен Касеинов белән төрки илләрнең мәдәният министрлары «Казан — 2014 елда төрки дөньяның мәдәни башкаласы» программасы кысаларында уздырылган чараларга югары бәя бирде. Декабрь азагында«Филармониада» фестивале кысаларында ТӨРКСОЙ белән берлектә гаҗәеп бай, матур концерт үтте. Әлеге концертка Дүсен Курабаевич та килеп, Казанда мәдәни башкала программасы буенча чараларның дәвам итүен ассызыклады. Кыскасы, төрки дөнья белән мәдәни хезмәттәшлек «мәдәни башкала» программасы белән генә чикләнми.

— Татарстан — күпмилләтле республика. Урыс һәм татардан тыш, башка милләтләрнең мәдәниятенә ни рәвешле ярдәм күрсәтелә?

Республиканың күпмилләтлелеге — аның тиңсез байлыгы. Татарстанда 173 милләт һәм этник төркем вәкилләре яши. Төп халыкны тәшкил иткән татар белән урыслардан тыш, Идел буе халыклары — чувашлар, удмуртлар, мордвалар, марилар яши. Аларның һәркайсы уникаль мәдәнияткә ия. Республикабызның үсешенә халыкларның уртак тырышлыгы йогынты ясый.

Мәдәният министрлыгы «Татар халкының милли үзенчәлекләрен саклау» дәүләт программасы белән бергә «Татарстанның дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» программасының да координаторы булып тора. Әлеге программалар башка министрлыклар, идарә тармаклары, институтлар белән берлектә тормышка ашырыла.

Соңгы ун елда татар халкының «Нәүрүз», «Җыен», «Каз өмәсе», «Сөмбелә», урыс халкының «Каравон», «Раштуа», «Масленица» бәйрәмнәре белән берлектә, мордва халкының «Балтай» бәйрәме, «Уяв» чуваш мәдәнияте бәйрәме, Кама арты чувашларының «Учук» фестивале, удмуртларның «Гырон быдтон»ы, мари мәдәниятенең «Семык», керәшеннәрнең «Питрау» бәйрәмнәре торгызылды. Төрле халыкларның милли бәйрәмнәре муниципаль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантлары нигезендә финанслана. Бу әллә ни зур сумма булмаса да, ел саен өстәлә барып, бәйрәмнәрнең эчтәлеген, масштабын киңәйтергә мөмкинлекләр бирә. Татарстан дәүләте сәясәтен тормышка ашыру йөзеннән традицион «Уйнагыз, гармуннар!», «Урыс җыры» кебек республика халык иҗаты фестивале белән беррәттән, «Чуваш сандугачы», «Фин-угыр халыклары иҗаты фестивале» һәм башка гүзәл чаралар даими үткәрелә башлады.

Татарстан халыклары Ассамблеясының эшчәнлеген ассызыклап үтү дөрес булыр. Халыклар дуслыгы йортында урнашкан бу Ассамблея 85 милли иҗтимагый оешманы берләштерә. Биредә 30 Якшәмбе мәктәбе эшли һәм 28 халыкның теле өйрәнелә. Республикада 100дән артык милли-мәдәни үзәк актив эш алып бара. Төрле халыкларның фольклор коллективларына иҗат итү өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Республикада чуваш, удмурт һәм керәшен газеталары чыга.

— Республика мәдәниятенең киләчәген тулаем ничек күзаллыйсыз?

Мәдәниятебезнең киләчәген «Татарстан Республикасында 2014-2020 елларда мәдәният үсеше» дәүләт программасы аша күзалларга мөмкин. Программа мәдәниятнең һәммә юнәлешләрен — музей эшчәнлеген, театр сәнгатен, китапханә эшен, концерт оешмалары эшчәнлеген һәм башкару осталыгын, кинематография үсешен һ.б. колачлый. Музей фондларын тулыландыру, аларның сакланышын тәэмин итү, күргәзмәләр эшчәнлеген активлаштыру, музей залларына комплекслы мәгълүмат бирүче автоматлаштырылган системалар урнаштыру, музейларның PR-эшчәнлеге — болар

барысы да программада каралган. Театр сәнгатенә килгәндә, репертуар театры традицияләрен саклау, иң яхшы классик әсәрләргә нигезләнгән һәм заман драматургиясен кулланган репертуар сәясәтен формалаштыру максаты куелган. Китапханәләрнең эше милли мәдәни мирасыбызны саклау һәм гражданнарыбызны мәгълүмат белән тәэмин итүгә юнәлтелгән. Концерт оешмалары милли музыкаль традицияләребезне саклаучылар, бүгенге заманның музыка сәнгатен үстерүчеләр. Программада халык иҗатына һәм гамәли сәнгатенә зур урын бирелә. Сәнгати белем бирү учреждениеләре дә игътибардан читтә калмаячак, «Мәктәп — училище — ВУЗ» укыту чылбыры үзен аклый һәм аны өзәргә ярамый. Быел музыка һәм сәнгать мәктәпләренең матди-техник базасын ныгыту буенча күпмедер күләмдә гамәл кылынды — 6 миллион сумлык музыка кораллары алынды. Мәдәният тармагын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү буенча да эш бара.

Мин республикада мәдәниятнең киләчәгенә зур ышаныч белән карыйм. Бу елның төп максаты — кеше эшчәнлегенең мөһим бер тармагына дәүләтнең һәм җәмәгатьчелекнең игътибарын юнәлтү иде. Әлеге максатны тормышка ашырдык, дип әйтә алабыз — гаммави чараларда мәдәният темасына багышланган мәкаләләр бермә-бер артты. Мәдәният, мәгариф һәм фән учреждениеләре, иҗтимагый оешмалар мәдәният юнәлешендәге яңадан-яңа проектларны тормышка ашыра, бу темага җәмәгатьчелек белән республика җитәкчелеге арасындагы диалог активлашты.

Шунысын да күреп-белеп торабыз: Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов мәдәниятккә һәрчак игътибарлы булды, чөнки мәдәният — Җөмһүриятебезнең үсешен тәэмин итә торган стратегик юнәлешләр рәтендә тора.

Әңгәмәдәш — Ләбиб Лерон ■

«ИНДЕ АЛМАГАН НИ КАЛДЫ?»

(Милли фаҗигабезне яктыртучы фарсы чыганагы)

*Ахыры. Башы журналның 1 нче санында

Ватан ибне Әүләкәй дигән кешенең илбасар, залим булуы аерым әйтелә. Углы Ко[лә]хмәт әтисе үлгәннән соң бик курка, Ак Идел якларына качып китә. Ул тирәләрдә озак яшәми, үлә. Аны Муса авылы янына күмәләр. Анда зур төрбә бар. Икенче улы Акай Гур[1] белән фетнә оештыра. Аның ике малае була. Габдулланың аякларын кисеп, үтерәләр. Икенче улы Биктәмүш бик бай Мөхәммәтшәрифкә хезмәт итә. Ул байның да үтерелүе турында хәбәрләр бар. Чуваш якларындагы Туган авылында яшәгән Васим исемле кешенең барлыгы билгеле. Ул чуваш булганга, аңа игътибар итмиләр. Аның әнисе чуваш була. Чуваш караклары Акайның атларын урлыйлар. Ко[лә]хмәт белән Акай соңыннан чувашлардан үч алалар: атларын алалар, аларны җәзалыйлар. Шулчакта бер карак чуваш качып, Гурга шикаять яза. Акайны кулга алалар. Шуннан соң Ко[лә]хмәт кешеләре: *«Әгәр безгә Акайны исән-имин килеш бирмәсәгез, без сезгә үзегез сораган бернәрсәне дә бирмибез. Исән булырга теләсәгез, сугышмагыз, туктатыгыз сугышны. Безнең җирләргә кермәгез. Әгәр керсәгез, без сугышачакбыз... Сәлам булсын һидаять юлында булган кешеләргә»*, — дип шикаять язалар. Моңа каршы Гур: *«Миңа Җаек елгасы ягына юлны күрсәтегез. Мин шунда барам һәм крепость төзим. Акайны яхшы урында калдырырмын»*, — дип җавап бирә. Аннан соң барлык мөселманнар җыелып, киңәшмә оештыралар. Акыллы кешеләр әйттеләр: *«Әгәр Гур безнең артта саклаучы кеше калдырса, безгә авыр булачак. Безнең кешеләребез кяферләр хезмәтендә булачак. Ризалашырга кирәкми, ризалык бирмибез. Аңа Җаек елгасы ягына юлны күрсәтмибез. Аның белән сугышабыз»*.

Икенче көнне билгеләнгән урынга килеп, Гурга юлны күрсәтмәделәр. Барлык мөселманнар җыелып, аңа каршы сугыштылар. Русларның күбесе әсирлеккә алынды, байтагы яраланды. Бу сугыш барганда, ислам гаскәрләре һәрвакыт далада булдылар һәм Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорадылар. Аларның догаларын Аллаһы Тәгалә кабул итте. Сугышкан чакларда да мөселманнар «Аллаһы Тәгалә!» — дип кылычларын чыгардылар. Алар арасында кылыч һәм сөңге тоткан яшьләр дә күп була. Ләкин халык арасында төрле максатлы кешеләр булган. Кайберләре хәтта талау, урлау белән шөгыльләнә башлый. Шушы гөнаһ эшләре өчен мөселманнарга җиңү килмәде. **Талаучыларга Аллаһы Тәгалә җиңү ачкычы бирми.** Шуннан соң Гур яңадан мөселманнар янына килә, ләкин Акайны җибәрми. Ул Ак Идел һәм Нократ елгалары кушылган урынга килеп чыга. Ак Иделнең өске ягына менеп, яңадан мөселманнар белән сугыша.

Мөселманнардан бик күренекле, атаклы кешеләр шунда сугышып, шәһит киттеләр, үлем ачысы татыдылар. Сәлим батыр да шунда, алар кулыннан һәлак була. Мөселманнарны бу файдасыз сугыш бик ялыктыра. Алар нинди дә булса хәйлә корырга уйлыйлар. Сәлим батырның үлеме дә алар өчен авыр була. *«Гур*

[1] Гур — Явыз Иван.

[2] Кинель елгасы (Киң елга) — Оренбург һәм Самара өлкәләре елгасы.

[3] Сазам — Оренбур, Самара өлкәләреннән ага торган елга.

кануннары белән килешергәме соң әллә?» — дигән уйлар да килә алар башына. Алар төркем-төркем булып урманнарда яшиләр. 6 ай буена Гур гаскәрләре аларга төрле яктан һөҗүм итеп тора.

Шулай кыш килә. Мөселманнар, берләшеп, үзләренә һөҗүм иткән русларны җиңәргә омтылалар, аларны үзләре яшәгән җирләрдән куалар. Аллаһы Тәгалә гурларга булышмады. Шуңа да алар кыш көне башка һөҗүмнәр ясамадылар, язга калдырдылар. Шулай итеп, мөселманнар әкренләп кенә төрле якларга таралышалар. Бер-берсенә хатлар язып, сүз бирделәр: *«Әгәр берәр төрле талаулар, һөҗүмнәр булса, шушы вакытта, шушы сәгатьтә фәлән урынга җыелырбыз»*.

Бераз вакыттан соң, алар Канал (Кинал) елгасы[2] буенда очрашалар. Кайсылары: *«Без Ватанны калдырып китәбез, моннан качабыз»*[3], — диләр. Алар арасында чувашлар, башкортлар да була. Шунда чакта Чирмешән якларына китүчеләр күп була. Канал янында Сазам (Сазали, кулъязмада Сазалияңга диелә) елгасы бар иде. Шуннан ерак түгел бер чишмә бар. Исеме — «Бөкешмә кырлыган». Анда бик күп мөселманнар яшәгән, алар арасында күренекле остазлар, галимнәр дә булган. Бу җәмәгатьтә беркем дә беркемгә дә хуҗа булмаган. Ләкин тора-бара алар арасында монафыйклар пәйда була. Алар хыянәт итәләр, монда мөселманнар барлыгын Гурга хәбәр итәләр.

Риваятьчеләр һәм тарихчылар сөйләве буенча, хыянәтче чуваш кешесе Зокрай ашар Корбанай атлы кеше булган. Аның кемлеге билгеле түгел. Мөселманнарның шунда икәнлеген белгәч, таң атканда гурлар аларга һөҗүм итәләр. **Бу вакыт мөселманнар ни эшләргә белмәделәр, аптырап калдылар. Кайсылары суга ыргытыла һәм шунда батып үлә. Бу үзенә бер мәхшәр иде: акырыш-кычкырыш, картларны этне кыйнаган кебек таш һәм агачлар белән кыйнап үтерделәр, балаларны кылыч белән турадылар, бичара хатын-кызларны көчләделәр, мыскыл иттеләр, яшьләрне үтерделәр. Бу мәхшәрдән калган гәүдәләрне төлкеләр, бүреләр атна буена ашап йөрделәр, аларга ризык мул булды. Хәзер дә, анда барсаң, сөякләр табарга була.**

Шушы хәлләрдән исән калган мөселманнарның бер төркеме кем җәяү, кем атта Субуга (Себергә) качтылар. Арыгач, Сәмил елгасы янына туктап, Аллаһка сыендылар. «Аллаһу әкбәр!» — диеп тәкъбирләр әйттеләр.

Озакламый Гур фәрман чыгара: *«Мөселманнар! Әгәр сез минем законнарыма буйсынсагыз, искечә яши аласыз. Мин һәр җирдә күзәтүче калдырам»*. Моны кабул итү мөселманнарга бик авыр була, алар моны начар кабул иттеләр. *«Бу фетнә кайчан бетәр?»* — диеп кайгырыштылар. Курыккан кешеләр моның белән килештеләр. Ләкин күбесе килешмәде, тагын бу яклардан качып киттеләр. Аларга бик авыр булды. Ачлыктан, авырлыклардан аларның күбесе үлде.

Качып китүчеләр, кыш көне алар белән тормыш яхшы булыр диеп, Ак Идел янында бигиҗаннарга кушылдылар, кайсылары кыпчаклар ягына киттеләр. Ләкин барыбер тормыш яхшы

булмый, аларны ачык йөз белән каршы алмыйлар. Алар монда да авырлыклар белән яшәделәр. *«Без кол булырга тиеш түгел, әллә соң без Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләрнең кадерен белмәдекме, шөкер итмәдекме? Шуңа Аллаһы Тәгалә безгә ачуландымы икән? Безнең кавем шулай бетәрме әллә?»* — диеп уйладылар, хаталарын эзләделәр.

Ко[лә]хмәт бине Әүләкәйне эзләп табып, сөйләшеп, дошманнарына һөҗүм итәргә уйлыйлар. Шулай итәләр дә. Кылычлар белән уңга-сулга болгап барып, үч алалар. Булаттан ясалган (корыч) уклар белән һөҗүм итәләр. Бу юлы алар ялгышмыйлар, яхшы көрәшәләр.

Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә тәкәббер кешеләрне яратмый, Аллаһы Тәгалә тәкәбберләргә караганда түбәнчелекле кешеләрне хуплый, ярата. Аларга шулай җиңү килә. Аллаһы Тәгалә бу юлы ярдәменнән ташламый аларны.

Шулай кыш җитә. Мөселманнар киләчәк тормыш турында уйлый башлый, бергәләшеп киңәшләшеп яшәделәр. *«Шулай булсак, бергә булсак, тормышыбыз яхшырыр»*, — дип уйладылар. Юлларны яхшыртып, сәүдә эше ачарга булдылар. (Бу XVI гасырлардыр.) *«Аллаһы Тәгалә, ярдәм бирче бу эшләребездә»*, — дип дога кылдылар.

Ләкин монафыйклык, икейөзле кешеләр алар арасында да була. Шуңа да Аллаһы Тәгалә аларга тагын бер бәла җибәрә. Үзләре арасында яшәгән, алар белән авырлыкларны үткән бер адәм Гурга мөселманнар турында хәбәр итә. Шулай итеп, аларның яхшы тормыш турындагы хыяллары тагын җимерелә. Гур гаскәрәләре аларга тагын һөҗүм итә. **Тагын мәхшәр башлана: малларын урлыйлар, балаларны, картларны үтерәләр, кызларны үзләренә алалар. Бу сугышта күп кеше үлә, кайсылары тагын төрле якка кача.** Төрле яктагы байларга, бәкләргә мөрәҗәгать итәләр, үз хәлләрен сөйлиләр, ләкин аларга ярдәм итүче булмый. Монда гурлар тарафыннан искиткеч явызлыклар эшләнә. **Үлгән кешеләрне, кошлар ашасын дип, агачларга элеп куялар.** Оренбург, Әстерхан якларына качкан мөселманнарны рус гаскәрләре эзләп китә. Бу вакытта Тураханкуча ибне Ко[лә]хмәт тә үлә. Аны шундагы Ташлы авылы янына күмәләр. Бу кеше бик көчле иде, аны беркем дә җиңә алмый иде. Мөселманнар һәрвакыт аңардан ярдәм сораган, ул ярдәм иткән. Бу кешенең үлүен алар бик авыр кичерә.

Тегеннән-моннан куылып йөргән татар халкы казакълар ягына килә. Ләкин тора-бара алар барыбер үз якларына кайтырга уйлыйлар. *«Аллаһ үзе белүче, ярдәм итәр»*, — дип дога кылалар һәм кайтырга чыгалар.

Ә Гур яңадан-яңа указлар чыгарып тора: кем аны тыңламый — кулга алырга, кем начар — җәза бирергә. Икейөзле адәмнәр моңа шатланып торалар. Аларның йөзендә елмаю һәм шатлык пәйда була. Бу Аксара[й] дигән җиргә Казаннан Мөхәммәтшәриф, Надир ибне Ураз дигән кешеләр дә килгән. Алар халыкка гурларга буйсынырга, аларга итагатьле булырга, алар армиясенә хезмәт

итәргә кушарга дип киләләр. Шулай итеп, татарларны тулысы белән аларга тапшыралар.

Бу турыда ишетеп, Сарытау якларыннан коралланган атлы мишәрләр килде. Алар татарларны якладылар. Ләкин Гур гаскәрләре аларны кабул итми, моннан куып җибәрделәр. Мишәрләр башкортлар ягына киттеләр. Ә Гур халыкка яңадан түли алмаслык ясаклар салды. Ясакны тире белән түлиләр, түли алмаган кешегә җәза бирелә. Кяферлектән һәм фетнәлектән Аллаһ сакласын!

Бичара мөселманнарга бу вакытта бик авыр була. Аларны аяк-кулларын богаулап, авыр эшләрдә эшләтәләр. Бу җирләрдән ераграк урыннарга таралып утырган яшьрәк мөселманнар йортлар салып яши башладылар. Шуларны күргәч, гурлар барабаннар кагып килеп, ул йортларны яндыралар. Мөселманнар, хәлләре авыр булса да, сабыр иттеләр. Тәүбә итеп, Аллаһы Тәгаләгә ялваралар. Руслар аларга карата төрле авыр һәм кырыс фәрманнарны чыгарып тордылар, мәҗбүр иттеләр.

Авыр вакытларда мөселманнар үз төбәкләрендәге рус кешеләрен үтерделәр. Аларны моның өчен руслар нык җәзаладылар. Христиан динен кабул итәргә мәҗбүр иттеләр. Халыкка үз диненә хыянәт итү бик авыр була. Төрле фикерләргә килделәр: *«Әллә сугышыргамы, баш күтәрергәме? Дингә хыянәт иткәнче, үлүең яхшырак»*, — диеп тә уйлаганнар. Күпләр качып та киттеләр, ә качкан кешеләрне тотып кыйнадылар. Ләкин барыбер: *«Гурга хезмәт иткәнче үлик, урыныбыз җәннәттә булыр, иншаллаһ. Амин, амин, Аллаһы Тәгалә, кабул ит»*, — диючеләр күп иде.

Олы кешеләр сөйләвенчә, **мөселманнарга караш бик начар була. Аларны төрлечә җәзалаганнар: агачларга бәйләп куеп, үлгәнче шунда тотканнар. Аякларыннан асып куеп үтергәннәр. Үлгәч, гәүдәләрен алырга да рөхсәт итмәгәнәр, кошлар ашасын дип, шунда тотканнар.** Ләкин мөселманнар, шуңа да карамастан, Коръән укыганнар, Аллаһы Тәгаләдән өмет иткәннәр. Хәзер дә аларның сөякләрен, янган өйләрен таба аласыз, ди риваятьче.

Шулай итеп, **явызларча татарлар яшәгән урыннарны тараттылар, малларын куып киттеләр, барлык яшьләрне әсирлеккә алдылар. Сорап килгән туганнарына сатып бирделәр. Картлар әйтәләр иде: һәр йортның диярлек капкаларына аякларыннан кешеләр асылган, аларны этләр, каргалар ашый иде. Су буендагы бинага 40 кешене ябып куйганнар, һәр көнне бер кешене суга ташладылар. Соңыннан унар кешене ташлый башладылар. Судан чыгарга тырышучыларны яңадан батырганнар.** Бу күренешне күз алдына да китерергә авыр. Искә төшергәндә дога кылырга кирәк.

Әле мондагы күп вәхшилекләр ачылып бетмәгән. Бу мөселманнарга Алла тарафыннан тиешле язмыш булган. Ләкин аларның иманнары нык булган. Алар шәһит киткәннәр һәм җәннәткә керәчәкләр. Калганнарны Аллаһ кодрәте белән җәяү Казан ягына куып алып киттеләр. Гур кешеләре атларда, ә болар җәяү баралар. Юлда авырып, бара алмаганнарны кылыч белән үтереп калдырганнар. Кайсыларын Казанга килгәч үтергәннәр, яшьләрне үзләренә файдага алганнар.

Тарихчылар сөйләве буенча, бервакыт Казан ягындагы мөселман авылына Уфа якларыннан Гур гаскәрләре килеп төшә. **Алар халыкны бер өйгә җыеп, ишек-тәрәзәләрне ябып яндыралар. Кешеләр җан ачысы белән елый, ялвара.** Дошманнар явызлык эшләп, бик зур гөнаһ эшлиләр, ә мөселманнар, Аллаһның яраткан бәндәләре булып, шәһит китәләр. Шуннан Гур шушы «бөек эшен» зурлап бәйрәм итә һәм фәрман яза: *«Кем бу эштән котылган, алар казнага налог түләргә тиеш. Кем түләми — шундый җәза булачак»*. Аның максаты, халыкны куркытып акча алу була. Кемнәр башкорт, аларга шулай ук налог түләргә кушыла. Түләмәгән башкортларны аерым дәфтәргә язып барганнар һәм аларны «Ур башкорт, уар башкорт» дип атап мыскыллаганнар, үлем белән куркытканнар. Налог түләсәләр генә башкорт була алганнар алар. **Халык налогны бик авырлык белән булса да, тынычлык өчен түләргә тырышкан.** Тиреләр, бодай биреп булса да, русларны озатканнар, тыштан гына булса да хөрмәт күрсәткәннәр.

Аллага шөкер, бүген аларның хәлләре яхшы, үткән тормышны искә алып, бүгенгесе өчен Аллага рәхмәт әйтәләр, шөкер итәләр. Аларның үз торыр урыннары, йортлары бар. Аларның хәлен, үткәндәге тормышларын язган өчен хикәятчеләргә рәхмәт әйтәләр. Шәһит киткәннәр өчен дога кылалар. Аллаһы Тәгалә рәхмәтеннән ташламасын!

Картлар әйтүе буенча, гурлар белән сугышлар булганда безнең халык кыпчаклар, казакълар ягына да кача. Ә казакълар аларны алдау, хәйлә юлы белән каршы ала. *«Сез рәнҗетелгәннәр, хәлегез авыр. Сусасагыз, су бирәбез, ач булсагыз, ашатабыз, урынсыз булсагыз — урын бирәбез»*, — дип аларны алдап, малларын, хатын-кызларны алалар. Ә карт кешеләрне үтерәләр. Кызларны төрекмәннәргә, каракалпакларга, казакъларга саталар. Кем бу эшкә каршы була, аларны да үтергәннәр. Шуның өчен башкортлар, казакълардан качып, Гур белән кушылалар, аларга баш иеп, үзләрен саклап калалар. Шундый түбәнчелек белән булса да абруйларын күтәрәләр, тормышларын яхшырталар. Бу хәлләрне белүче — бер Аллаһы Тәгалә. Ул — бөек зат! Кемгә бәла язса, ул аны күрәчәк. Язмыштан узмыш юк. **Булган хәлләрне онытмаска кирәк!** Алда Аллаһы Тәгалә ни язганын без белмибез. **Безнең халкыбызга шундый язмыш булган, Аллаһы Тәгалә безгә аны күрсәтте. Безнең ялгышларыбыз күп булганга бәлки Аллаһы Тәгалә шундый язмыш биргәндер.**

Дога: «Раббым Аллаһ! Безне гафу кыл. Хәсрәт чигүче кавем ясама. Безнең халык күп хәсрәт күргән. Бу сугышлар, җәнҗалларны онытмыйк. Кешеләрне, олыларны хөрмәт итеп яшәргә насыйп ит. Үзара бердәмлек белән яшәргә насыйп ит. Ялгышмаска, булган хәлләргә игътибар итеп, тагын ялгышмаска, гафу итә белергә, кичерә белергә насыйп ит. Үз кануннарыбыз белән яшәргә, бу упкыннарга яңадан төшмәскә насыйп ит. Амин!»

Фарсычадан Г.Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ аспиранты ***Алсу Газымова*** *тәрҗемәсе.*

КЕМ УЛ МОРАД МУЛЛА?

Раиф Мәрданов

Татар энциклопедиясендә аның турында мондый мәгълүмат язылган: «Морад мулла (XVIII йөз) – җәмәгать һәм дин эшлеклесе, әдип. 1760 елларда үз шәкерт һәм мөридләре белән халык арасында Болгар дәүләтен яңадан торгызу фикерен таратып йөри. 1769 елда Болгар шәһәре хәрабәләре янында үз фикердәшләреннән берничә мең кеше катнашкан җыен уздыра. Тиздән тарафдарларыннан берничә кеше белән бергә кулга алына, С.-Петербургка озатыла. Әмма берникадәр вакыттан соң «фанатик», «яңа дин эзләүче» дип азат ителә. Кулъязма китабы булганлыгы мәгълүм».

Мәкаләбез Морад мулланың кайсы төбәк кешесе һәм нинди нәселдән булуын ачыклауга багышланды. Шул сәбәпле, аның иseme белән бәйле хәрәкәтнең бөтен нечкәлекләрен тасвирлау максатын куймадык. Ә тарихи шәхес мулла Морад хәрәкәте турында тәфсилле мәгълүматны М.Гайнетдиннең «Мәңге тонықланмас көзгебез» исемле китабыннан, «Гасырлар авазы» журналының 2007 елгы икенче санындагы махсус мәкаләләрдән һәм архив документларыннан укып белергә мөмкин. Журналның ул санында филология фәннәре докторы Мәсгуд Гайнетдиннең «Мулла Мурат» исемле кереш мәкаләсе белән 1771 елда мулла Морадтан алынган язмаларның рус теленә тәрҗемәсе, тарих фәннәре кандидаты Динә Мостафинаның Сенат тарафыннан әлеге шәхескә бәйле яшерен тикшерү эше документларының тасвиры һәм аларга аңлатмалары басылган.

Мулла Морад хакындагы иң әүвәлге хәбәр ил һәм татар тарихындагы зур вакыйгалар (сугышлар, яңа патшаларның тәхеткә утыруы, халык баш күтәрүләре, зур афәтләр һ.б.) теркәп барылган XVIII гасыр тарихи елъязмаларына кертелгән. Мәсәлән, Олы Мәңгәр авылында (хәзерге Татарстанның Әтнә районында) язып барылган елъязмада мондый мәгълүмат теркәлгән: «1771 сәнәдә берсе – мулла Морад, берсе Аит мулла дигән ике кемсәнә вәлилек дәгъвасы берлә чыгып йөрделәр. Ахыр,



Мөхәммәтгариф Морадый язмаларының Морад мулла турындагы бите

тотып, Мәскәү каласына җибәрделәр. Мәҗнүнлек берлә хөкем кылып кайтардылар, һичнәрсә улмады анларга». Икенче елъязмада бу хәбәр бераз башкачарак: «1771 – Морад мулла чыкты, дин хакында мөхтәлиф китаплар чыгарды. Ахыр, тотылып, Оренбурдин Питырбурга алып киттеләр».

Бу елъязмаларны совет чоры галимнәреннән күренекле татар әдибе һәм галиме Гали Рәхим (1892-1943) өйрәнгән һәм Морад мулла турындагы язмалар да беренче булып аның 1930

елда язылган «Новые списки татарских летописей» исемле хезмәтенә теркәлгән. Аннан соң мулла Морадка бәйле архив мәгълүматларын тарихчы Сәлам Алишев өйрәнеп, үз хезмәтләрендә язып килде. Аның 1976 елда чыккан «Каһарман бабайлар» хезмәтендә болай дип язылган: «Милли азатлык көрәше шул вакытның төрле кешеләре аңында төрлечә чагылыш тапкан. Батыршадан соң, 1760 елларда мулла Морад үзенең тәгълиматын таратып, милли азатлык идеологиясе белән чыккан. Аның төп политик лозунгы «Болгарны торгызу вакыты җитә» дигән тезис булган. Ул берничә китап язып тараткан, укучы шәкертләре күп булып, аларны да шул көрәш юлына юнәлткән. Аны кулга алып, кайбер иярченнәре белән Петербургка озатканнар, ләкин озакламый тоткынлыктан азат иткәннәр... Шунысы кызыклы: Батырша юлыннан барган мулла Морадның иярченнәре, мәсәлән, аның белән Петербургтан әйләнеп кайткан Аит Уразмәтов, Пугачёв җитәкчелегендә бөек крестьяннар сугышының актив көрәшчеләре булганнар. Димәк, милли азатлык хәрәкәтенең фикер-уйлары гына түгел, ә бәлки шул фикерләрне үзләрендә йөрткән кешеләр дә гадел крестьяннар сугышына барып җитеп, шуңа катнашканнар». Пугачёв күтәрелеше вакытында Аит Уразмәтев белән аның энесе Тимербулат туплаган отрядта 900 ләп сугышчы булган һәм алар Бөгелмә-Чирмешән тирәләрендәге бәрелешләрдә катнашкан. А.Уразмәтев 1774 елда әсирлеккә төшеп, җәзалап үтерелгән.

Татарстан Милли китапханәсендәге гарәп хәрефләре белән язылган кулъязма истәлекләрне һәм төрле тарихи чыганакларны җентекләп өйрәнгәч, Аллага шөкер, мулла Морадның биографиясен, аның туган җирен һәм кайсы нәселгә нисбәтле булуын ачыклауга ирештек.

Борынгы кулъязмалар туплау максаты белән 1996 елның декабрь аенда Самара өлкәсенең татар авылларына баргач, Похвистнёво районындагы данлыклы Гали авылы тарихына багышланган ике кулъязма юнәлткән идек. Алар хәзер Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

Гали авылының тарихына багышланган **ике кыйммәтле ядкярнең берсе — шул авылның беренче мәхәлләсендә имам булып торган Мөхәммәтгариф мулла Морадыйның 1925-1929 еллардагы язмалары**[1]**. Ә икенчесе — Хәбибулла Алтынбаевның Гали авылы тарихы язылган дәфтәренең күчермәсе**[2]**.** Кызганычка каршы, әлеге кулъязмалардагы мәгълүматлар Гали авылына багышлап 2009 елда нәшер ителгән китапта кулланылмаган (Сохраняя вековые традиции (400 лет по праведному пути) / [авт. и ред. Л.Р.Бурмистрова]).

Мөхәммәтгариф мулланың Морадый (Моратов) дигән фамилиясе бабасының бабасы Морад хәзрәт исеменнән алынган. Мөхәммәтгариф Морадый (1883-1937) туган авылы Гали тарихын һәм күптармаклы нәсел шәҗәрәсен өйрәнгән кызыклы шәхес булган. Ул төзегән шәҗәрәдә буыннар чылбыры бу рәвешле: үзе — Мөхәммәтгариф, аның атасы Мөхәммәтхарис, Мөхәммәтхарисның атасы Мөхәммәтгалим, аның атасы Котлугәхмәт, Котлугәхмәтнең атасы Морад хәзрәт, аның атасы Ишали, Ишалинең атасы Ишмәт (ягъни, Ишмөхәммәт), Ишмәтнең атасы Дүскәй, аның атасы Йосыф, Йосыфның атасы Сөләйман, Сөләйманның атасы Манаш. Шунысын искәртү мөһим: төп ватаны — хәзерге Татарстанның Балык Бистәсе районындагы Күгәрчен авылыннан булган Манаш тархан нәселе вәкилләре XVII гасыр башларында ук хәзерге Самара һәм Оренбург өлкәләре территориясендә шактый киң җир

[1] Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1868т» шифры белән саклана.
[2] Шунда ук «1077т» шифры белән саклана.

биләмәләренә ия булганнар. Бу нәселнең Гали исемле кешесе XVII гасыр ахырында Гали авылын нигезләгән[3].

М.Морадый тарафыннан 1925 елда төзелгән Манаш нәселе шәҗәрәсе М.Әхмәтҗановның китапларында һәм Гали авылы тарихы турындагы җыентыкта да («Сохраняя вековые традиции») басылып чыкты.

Хәбибулла Алтынбаев текстында да Ишалиның улы Морад хәзрәт дип һәм Морадның алты улы булганлыгы әйтелеп, аларның исемнәре язылган. Шулардан Ногман исемлесе Әсәкәйдә һәм Котлугәхмәт исемлесе Гали авылында имам булганлыклары искәртелгән. Морад хәзрәтнең гыйлемлеге белән күп авыруларны тергезүе әйтелгән.

Мөхәммәтгариф мулла язмаларында Морад хәзрәт зур ихтирам белән телгә алынган. Ул Морад мулланың мөриде (шәкерте) Заһидулла Миңлегул улының «Мөхтәрәм остазымыз Морад хәзрәт хакында» дип исемләнгән язмасын да күчереп алган. Язмада исә кызыклы гына хәбәрләр теркәлгән. Мәсәлән, «Морад хәзрәт һәрвакыт китап язган. Артык дәрәҗәдә тырышучан, күп белүчән, изгеләрдән булган. Бервакыт Морад хәзрәтнең өстеннән үзеннән укыган 5 мулла патшага гариза бирәләр. Гаризада «бу кеше һәрвакыт китап яза, күп сүзләр сөйли, хөкүмәткә каршы хәрәкәт ясап, үзен халыкка изге итеп күрсәтә», дигәннәр. Морад хәзрәтне гариза буенча патшага алдыралар... Морад хәзрәтне түрәләр һәркаюсы тәгъзим илән аяк үзәрендә каршы алганнар»[4] дигән мәгълүматлар аеруча әһәмиятле. Чөнки нәкъ шушы язма Гали авылы кешесе Морад хәзрәт тарихта билгеле мулла Морад түгел микән дип, бу мәсьәләне ачыклауга этәргеч бирде.

Гали авылының мәшһүр мулласы Морад хәзрәт турындагы мәгълүмат Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар» исемле биобиблиографик китабында 1903 елда дөнья күргән булган. Анда болай дип язылган: «Морадбакый бине Ишали бине Ишмөхәммәд бине Йосыф бине Сөләйман. Богырослан төбәгендә Гали авылында яшәп вафат булган. Тайсуган авылында Габдрахман бине Туймөхәммәд хозурында гыйлем алгач, Капал тарафларында сәяхәт итеп, Нәҗметдин ишан исемле бер заттан суфыйлыкка өйрәнгән. Кайбер язган хезмәтләрен күрсәм дә, буталчыклардан гыйбарәт. Мөхәммәтҗан мөфти белән кайбер маҗаралары һәм шул мөфти белән казыйлары хакында язган кайбер шигырьләрен күргәнебез булды. Аны гаять инкяр итүчеләр булган кебек, чиксез хөрмәтләүчеләр дә бар. Бөтен гомерләрен аның яхшылыкларын сөйләп кичергән затлар булуын да әйтәләр... Морад хәзрәт гыйлемнәрдә камиллеккә ирешкәнче суфыйлык белән шөгыльләнеп, мавыгып китеп, теленә килгәннәрнең һәммәсен, тыңлаучыларны аерып-нитеп тормыйча, сөйләгән диләр»[5]. (Р.Фәхреддин бу шәхеснең исемен Морад дип түгел, ә Морадбакый рәвешендә язуы турында алдарак сүз булыр).

Хәзерге вакытта Морад хәзрәтнең исеме, данлыклы «Морад бабкай» буларак, Гали авылының бөтен кешесенә һәм, гомумән, бу төбәктә яшәүче милләттәшләребезгә мәгълүм. Морад

---

[3] Гали авылы тарихы / [төз. Р.Мәрданов]. – Казан: «Милли китап» нәшр., 2014. – Б.9-16. – («Татар археографиясе» сериясе; 14 нче китап).

[4] «1868т» шифрлы кульязма. – 11а кәгазь; Гали авылы тарихы... – Б.98-100. *Тәгъзим илән* – олылап, хөрмәт белән; *аяк үзәрендә* – аяк өсте, басып.

[5] Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 1 том. – Казан, 2006. – Б.80. Монда Морад мулланың нәсел буыннары арасында фәкать Дүскәй исемле бабасы гына язылмаган, калганнары М.Морадый төзегән шәҗәрәгә туры килә.

Габдрахман бине Туймөхәммәд 1691 елда дөньяга килгән, тирән белемле затның шәкертләре күп булган. Ул Ризаэддин Фәхреддиннең әнисе ягыннан бабаларыннан берсе (Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 1 том... – Казан, 2006. – Б.44-45). *Капал* – хәзерге Казакъстан территориясендәге шәһәр.

Морад мулла кабере. Гали авылы

бабай исеме Гали авылындагы чишмә белән тыгыз бәйле. Аны «Морад бабкай чишмәсе» яки «Бабкай чишмәсе» дип атыйлар. Бу изге чишмә тимер рәшәткә белән бүлеп алынган, янәшәсендә гыйбадәт йорты төзелгән. Авылның зиратында Морад бабайның кабере дә билгеле, ул чардуган белән бүлеп алынган һәм аның электән калган ташъязмасы да бар. Морад бабайның исеме изгеләштерелеп, тирән хөрмәт белән искә алына. Халык хәтерендә Морад хәзрәткә, аның могҗизаларга ия булуына бәйле төрле риваятьләр сакланган.

Гали авылында 2010 елда үткәрелгән I Бөтенрусия татар авыллары Сабан туеның «Казан» бию ансамбле башкаруында «Морат бабкай могҗизалары» дигән хореографик композиция белән ачылуы да игътибарга лаек. Ул хакта матбугатта «Мәйданга бизәлгән җигүле атта Гали авылының изге карты «Морат бабкай» килеп керде. Шулвакыт азан тавышы бар җиһанны тутырды, җаннарны иркәләп алды...» дигән сүзләр язылды[6]. Бу — әлеге шәхеснең халык хәтерендәге абруен тагын бер кат раслый.

Мулла Морад турындагы матбугатта чыккан мәкаләләрдә аның фамилиясе язылмый килде. Ә менә «Гасырлар авазы» журналының 2007 елгы 2 нче санында басылган Морад муллага бәйле архив документларының берсендә аның «мулла Мурат Ишалов» дип язылганлыгын күрәбез[7]. Шулай итеп «Гасырлар авазы» журналында Морад мулланың фамилиясе (Ишалов) беренче мәртәбә күрсәтелде. Д.Мостафинаның архив документларына карата язган аңлатмасында Моратның әсәр иҗат итүенә мәрхүм, изге шәех Нәҗметдиннең шәкертләре үзләренә остаз булуын сораулары турындагы төш күрүе һәм Морад Ишали улы («Мурат, сын Ишали») дип атавы[8] да әһәмиятле. Чөнки Р.Фәхреддиннең алда әйтеп үтелгән язмасыннан күренгәнчә, Гали авылының Морадбакый Ишали улы Капалга барып Нәҗметдин исемле шәехтән белем алган. Менә шушы һәм түбәндә күрсәтеләчәк торган тагын кайбер фактлар тарихи шәхес мулла Морад белән халык хәтерендә Гали авылының изге карты буларак сакланган Морад бабкайның бер үк кеше булуын ачыкларга ярдәм итте.

Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар» хезмәтендә язылган Морадбакыйның атасы Ишали исемле, шулай ук Мөхәммәтгариф Морадыйның шәҗәрә язмаларында һәм Хәбибулла Алтынбаев текстында да Морад хәзрәтнең әтисе Ишали булганлыгы теркәлгән. Димәк, XVIII гасырда Идел-Урал төбәгендә яшәгән мөселманнарның тарихи үзаңын күтәрергә тырышкан, Болгар дәүләте тирәсенә тупларга омтылган татар каһарманы Морад мулланың төп нәселе Гали авылыныкы булганлыгы раслана.

Морад исемен Р.Фәхреддиннең Морадбакый рәвешендә язганлыгына

[6] Кашапова С.Галидә — Морат бабкай эргәсендә // Мәдәни җомга. — 2010. — 11 июнь.
[7] Мустафина Д. Послесловие к публикации документальных материалов о мулле Мурате // Гасырлар авазы = Эхо веков. — 2007. — №2. — С.95.
[8] Шунда ук. — Б.98.

килсәк, монда зур хикмәт юк. Ул Морад хәзрәтнең тулы исемен үзенә билгеле чыганаклардагыча язган дип аңларга кирәк. Татар кеше исемнәренең ике өлештән (компоненттан) кушып ясалганнары, гадәттә, кыскартылып кына әйтелгән. Мәсәлән, Әхмәтгалим исеме — Галим, Фазлыйәхмәт — Фазлый, Тимербулат — Булат, Миңнегали — Гали, Фәрхетдин — Фәрхи һ.б. Менә шундый үзенчәлек мисалында, тулы исеме Морадбакый булган кешенең кыскача Морад дип кенә йөртелүе һәм тарихка шул рәвешле кереп калуы гаҗәп түгел. Ризаэддин Фәхреддиннең бу шәхесне Морадбакый дип тулы исеме белән атавына аның үз кулъязмалары нигез булганлыгы шик уятмый. Чөнки Р.Фәхреддин, алда әйтеп үтелгәнчә, Морад мулланың кайбер әсәрләрен һәм Мөхәммәтҗан мөфти белән казыйлар турындагы кайбер шигырьләрен күргән.

Ризаэддин Фәхреддиннең Морадбакый дип язуының төп чыганагы мулла Морадның үз язмалары булганлыгын куәтли торган ышанычлы дәлил дә бар. Ул да булса, Морад мулланың язмаларыннан русчага тәрҗемә ителгән архив документларында аның үзен «Моратбакый» дип атаган булуы (русча документта — Мрат-Бакий дип язылган) бер шик-шөбһәгә дә урын калдырмый[9].

Гали авылы зиратында Морад мулла каберенә куелган, без фоторәсемен генә күргән ташның ватылып, ярылганнан калган өлешендә мәрхүмнең исеме һәм нинди дә булса даталар сакланмаган. Әлеге кабер ташын халык Морад бабайныкы буларак хәтерли һәм моның шулай булуында бернинди шик юк. Ташъязманың алгы тарафындагы тугыз юлның беренчесе «лә иләһә иллә Аллаһы…» дип башланган, 3-7 нче юлларында изге шәех-суфыйларның (шулардан 4 нче юлда Морад мулланың остазы «шәех Нәҗметдин») исемнәре уелган. 6 нчы юлда Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали, 7 нче юлда Хәсән һәм Хөсәен, ә 8-9 нчы юлларда дини риваятьләрдә сөйләнгән җиде изге зат — мәгарә ияләре (әсхабе кәһәф) Йәмлиха, Мәксәлмина, Мислина, Мәрнуш, Шәднуш, Кәфәштатыюш һәм Кыйтмир исемнәре язылган.

Кабер ташында Морадның туган һәм вафат булган еллары яки ничә яшендә дөнья куйганлыгы язылган юллар, кызганыч ки, сакланмаган. Шулай да, Морадбакый Ишали улының Мөхәммәтҗан мөфти белән кайбер маҗаралары булган дигәнне исәпкә алганда һәм архив чыганакларыннан билгеле кайбер мәгълүматларны күздә тотканда, бу тарихи шәхеснең яшәгән елларын якынча чамаларга мөмкин. Ягъни, 1771 елда кулга алынганчы китаплар язган мулла Морадның яше ул вакытта якынча 30-35 яшьләрдән дә ким булмаган дип фаразласак, аны 1735-1740 нчы елларда туган кеше дип гөманларга була. Ә мөфтигә бәйле хәлләренә килгәндә, Мөхәммәтҗан Хөсәенов (1756-1824) Россиядәге беренче мөфти итеп 1789 елда билгеләнгән зат һәм ул бу вазифаны вафатына — 1824 елга кадәр башкарган. Шунлыктан, Морад мулланың 1790 нчы елларда исән булганлыгы аңлашыла. Димәк, Морадбакый Ишали улының XVIII гасыр ахырында яисә XIX гасыр башында дөнья куйганлыгын чамалап әйтергә ярый. (Һәрхәлдә, бу даталарны архивларда эзләнеп, Гали авылының халык исәбе алу — ревизия документларыннан төгәл ачыкларга мөмкин.)

Гали авылында гомер сөргән данлыклы Морадбакый Ишали улы — мулла Морадның туган төбәгендә изгеләштерелүе, шулай ук аның турыдан-туры нәсел дәвамчылары хәзерге заманга кадәр дәвам итүе, хәтта аның исемен фамилия итеп йөртүчеләр дә булуы, әлбәттә, бик мөһим факт.

Дәвамы бар ■

[9] Гасырлар авазы = Эхо веков. — 2007. — №2. — Б.93.

№ 3

Казанскiй Мусульманскiй Военно-гарнизонный комитетъ тел. № 18-80.

(ЧИНГИЗ-БАЛАСЫ)

Органъ Казанского мусульманскаго военно-гарнизоннаго комитета.

ТР ҮДТСДА фондыннан

«ЧЫҢГЫЗ БАЛАСЫ» ГАЗЕТАСЫ

Ленар Гобәйдуллин

Татарлар – патша армиясе составында хезмәт итәргә бурычлы булып, уртак Ватан – Россиянең мәгънәсез, канкойгыч сугышларында катнашырга мәҗбүр ителгән милләт. Ватанга тугры хезмәт итүгә, батырлыклар кылуга карамастан, армиядә төп өстенлек титул милләт русларда булып, хәрби җитәкчеләр дә руслар (дөрес, югары хәрби дәрәҗәләргә ирешкән татарлар да булган), гаскәриләр арасында уку-укыту һәм аралашу теле дә русча булган.

Башка милләт солдатлары, аеруча татарлар, «инородец-лар» дип каралып, аларның дини, милли ихтыяҗлары канәгатьләндерелмәгән. Еш кына хәрби бәрелешләр вакытында татарларны алгы сафларга куйганнар, кечкенә генә гөнаһ өчен дә зур җәзалар биргәннәр. Татар солдатын рус телендә сөйләшмәгәне өчен дә, русча җырламаганы, чукынмаганы өчен дә, дуңгыз ите ашарга теләмәгәне өчен дә, гомумән татар, мөселман булганы өчен кыйнаганнар. Армиядә иркенләп үз телендә аралашу, уку, дини һәм милли йолаларны башкару, милли телдә вакытлы матбугат, китаплар уку, аерым милли берләшмәләр төзү аларның хыялында гына булган. Фәкать 1917 елның февралендә патша бәреп төшерелгәннән соң гына армиягә берникадәр хөррият сулышы үтеп керә.

Россия армиясендәге тәүге мөселман оешмаларының берсе — Казан гарнизонының мөселман хәрби комитеты 1917 елның 8 мартында оеша. Аның рәисе — Ильяс Алкин[1]. Комитетның 24 мартта булган гомуми мәҗлесендә «мөселман гаскәриләренә аерым гаскәри фиркаләр», ягъни татар полклары төзергә карар бирелә. Шул ук елда оешманың идея-максатларын һәм тактикасын пропагандалаган ике ки-

[1] Гыйззәтуллин И.Г. Казан гарнизонының мөселман хәрби комитеты / ТЭС. Т.3 — Казан, 2012. — Б.59-60.; Гыйззәтуллин И.Г. Мусульманские военные организации (1917-1921гг.). — Казань: Фән, 2002.

тапчык басылып чыгуы мәгълүм. Аның берсе — «Комитетларны ничек оештырырга?», икенчесе «Татар полклары ни өчен кирәк?» дип атала. Икенче китапчыкта татар полкларының кирәклеге өч төрле сәбәп белән аңлатыла: «1) Ирекле Ватанымызга бөтен бер көч булып хезмәт итәсемез килүдән; 2) Милләтемез ноктаи нәзарыннан (карашыннан); 3) Мөселман гаскәриләре башкалар белән аралашып торганда хөррияте диния (дин иреге) икътизасынча (таләпләре буенча) тора алырга мөмкин булмавыннан». Аеруча, мөселман полкларында милли һәм дини гореф-гадәтләрне саклау, татар телендә укыту-тәрбияләү кирәклеге ассызыклана, тирәнтен анализлана[2]. Сентябрьдә исә Казан хәрби округы буенча мөселман солдатларын аерым полкларга аеру турында боерык игълан ителә. Мөселман полкларының төп максаты мөселман солдатларын берләштерү, аларны агарту, аң-гыйлем дәрәҗәләрен арттыру, дини йолаларны хәрби частьларда башкару мөмкинлеген тудыру булган. Гарнизонның частьларында 10 уку бүлмәсе ачыла, аларны 20гә җиткерү планлаштырыла[3].

1918 нче елны гыйнварның беренче яртысында дөньяга чыга башлаган «Чыңгыз баласы» газетасы да Казан гарнизонының мөселман хәрби комитеты басма органы булып, аның максат-бурычларын гамәлгә ашырыр өчен хезмәт иткән[4]. Әлеге басма турында «Корылтай» газетасында түбәндәге мәгълүмат теркәлгән: «Казан мөселман хәрби комитеты тарафыннан мөселман гаскәриләре өчен атнага бер «Чыңгыз баласы» исемендә газета чыга башлады. Мөндәриҗәсе (эчтәлеге) хәзерге милли хәрәкәтебез рухы белән сугарылганлыгы күренеп шатландырды. Хәзерге мөһим вакыт вә тыйнаксыз әхвәл вә вакыйга эчендә гаскәриләребез арасында милли бөтенлек, милли аң вә тәрбия тарату эшенең зур әһәмиятен вә бик читен булганлыгын билгеләп, шул юлда «Чыңгыз баласы»на муаффәкыять (уңыш) вә тиешле хезмәт телибез». Газета мөхәррияте тарафыннан язылган түбәндәге мәгълүмат та әһәмиятле: «Иптәшләр! Кулыгызда торткан ошбу газетаны фәкать сөекле гаскәриләребез өчен генә чыгарабыз. Һәм аны язучылар да гаскәри хезмәтнең Николай заманында ачысын татыган, соры шинельгә капланган крестьян-эшче гаскәриләр идекен мәгълүм итүебез илә бәрабәр, укыган вакытта өстән генә карап, кайбер җирен генә уку илә, яки бер-ике кеше укыгач та, газетаны юкка чыгармыйча, бәлки кулдан-кулга йөртеп, укый белмәгән иптәшләрегезне дә яныгызга җыеп, бергәләшеп, аңлашып укуыгызны үтенәбез». Казан мөселман хәрби комитетының аңлату-берләштерү шөгъбәсе (бүлеге) наширлегендә дөнья күргән газетаның шигаре исә киңрәк, гаскәриләрне генә түгел, ә бөтен милләтне берләштерү, шуның өстенә азатлык өчен көрәш рухында яңгыраган: «Милләтнең бөтен таркау көчләре берләшегез! Милләтнең якты, киләчәк рәхәт көннәре өчен көрәшегез!»

Күрүебезчә, газета Казан гарнизоны Мөселман хәрби комитетының максатларын гамәлгә ашыруда бер корал булып, басманың нигезендә берләшү идеясе яткан. Бер полкка, бер милләткә берләшү, авыллардагы кадимчеләр белән җәдитчеләрне, Русия җөмһүриятенең төрек-татар штатын («Волга буе һәм җәнүби Урал татарлары һәм башка милләтләрнең аерым штаты») игълан итеп, Идел-Урал буендагы төрки халыкларны берләштерү. Газетаның исеме дә юкка гына «Чыңгыз баласы» дип аталмаган. Чыңгыз хан — төрки халыкларны берләштерүче символ. Биредә тарихи аңны гаскәри берәмлекләр формалаштыруда корал итеп кулланырга теләү омтылышы да бар. Газета, безнең Чыңгыз хан төзегән, зур, гайрәтле гаскәребез булган, ә ни өчен әле андый гаскәр хәзер оешмас-

---

[2] Әлеге китап тарихчы, текстолог Җәүдәт Миңнуллин тарафыннан басмага әзерләнеп, аның кереш сүзе белән «Мирас» журналының 1994 елгы 9 санында (Б.114-117) халыкка кайтарылды.
[3] Гыйззәтуллин И.Г. Күрс. хезм.
[4] Русча: Чингиз-баласы. Орган Казанского мусульманского военно-гарнизонного комитета.

ка тиеш кебегрәк аң, фикер, кузгатып, горурлык хисен тәрбияләргә омтылган. «Чыңгыз баласы» Казан мөселман хәрби комитетының хәбәрләрен бастыру белән бергә, татар гаскәриләрендә әдәп, тарихи, сәяси үзаң, әхлак сыйфатлары тәрбияләү өчен дә хезмәт иткән.

Исмәгыйль Рәмиев истәлекләрендә газета турында: «Атнасына бер тапкыр, гаять тә кечкенә кулда, дүрт битлек булып чыгарылды. Типография техникасы яхшы иде. Аеруча алып әйтерлек каләм ияләре күренми», — дип язылаг[5]. Казан гарнизонының мөселман хәрби комитеты Екатеринская урамында (Г.Тукай) Габидулла Юнысов йортында урнашкан. Мөгаен аның «аңлату-берләштерү шөгъбәсе» һәм «Чыңгыз баласы»ның «һәйәте тәхририя»се (редакциясе) дә шунда урнашкан булгандыр. Газета Казандагы «Милләт» корылтай матбагасында басылган. 1918 елның мартында Мөселман хәрби комитетының эшчәнлеге туктатыла, шул сәбәпле газетаны 3 ай дәвамында чыккан, дип уйларга мөмкин.

«Татар вакытлы матбугаты» дигән библиографик күрсәткечтә «Чыңгыз баласы» газетасының ТР Үзәк дәүләт Тарихи-сәяси документлар архивында һәм БР Милли китапханәсендә фәкать бер саны гына сакланып калуы турында теркәлгән[6]. Бу «Чыңгыз баласы»ның 1918 елда дөнья күргән 19 гыйнвар (№3) саны. Газетаның сакланып калган бердәнбер номерында «Икенче мөселман гаскәриләр съезды тирәсендә», «Милли полкларыбыздагы гаскәри иптәшләргә», «Төрек-татар штаты», «Тәүфыйк», «Өйләренә кайта торган солдат иптәшләргә», «Чыңгыз кем?» (фельетон), «Казанда», «95 нче полк митингысының карарлары» кебек язмалар басылган.

Игътибарыгызга әлеге газета сәхифәләреннән берничә мәкалә тәкъдим итәбез.

МИЛЛИ ПОЛКЛАРДАГЫ ГАСКӘРИ ИПТӘШЛӘРГӘ!

Гаскәри иптәшләр! Һәрберемезгә мәгълүм, бу милли полкымызны алу, бөтен гаскәри көчемезне оештыру өчен, мөселман гаскәренең мөселман халкы өчен генә хезмәт итәргә тиешлелеге өчен без никадәр тартыштык. Бөтен бер милләтнең бер агыздан кычкыруы, соравы соңында нинди зур кара көчләр дә чыдамадылар! Юлымызга аркылы куелган киртәләр дә җимерелергә мәҗбүр булды. «Алсагыз, алыгыз инде, без берлек белән оешкан куәткә каршы тора алмыймыз», — дигән кебек полкларын безнең кулга тапшырдылар. Без, бу эшемезгә берлек аркасында гына ирешкәнемез шикелле, киләчәктә дә бөтен эшләремезне шул берлек белән генә алачакмыз. Бөтен эшләремез вөҗүдкә чыгачак [барлыкка киләчәк]. Без, полкны кулымызга алу белән, бөтен вазифамызны үтәгән кебек булдык. Ләкин юк, без бөтен вазифамызны үтәп бетермәдек, бәлки моннан да зуррак вазифалар өстемезгә йөкләнде. Беренче буларак, милли полкымызны үз тормышымызга муафыйк ислах кылу [туры килгәнчә яраштыру], милли полкымызны кабахәт иске рус казармаларыннан чыгарып, гүзәл тәртипкә кую, милли полк гаскәриләрен башка рус полклары өчен нәмунә [үрнәк] булырдай аңлы, тәртипле, куәтле гаскәри каһарманнар итеп чыгару. Читләр татар гаскәриләрен күргәндә, алардан тәртип, куәт берлеген күреп, гаҗәпкә калырдай гаскәриләр күрсәтү…

Хәзергә полкымызны тәртипкә салу эше акырынлык белән бара. Моның иң зур сәбәбе — бөтен Русияне

[5] Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (1905-1925): альбом. — Казан: Гажур, 1926. — Б.95.

[6] Гайнанов Р.Р., Мәрданов Р.Ф., Шәкүров Ф.Н. Татар вакытлы матбугаты (1905-1924): библиографик күрсәткеч. — Казан: Рухият, 1999. — Б.178-179.

басып барган башбаштаклыкларның без татар гаскәриләре арасына килеп төшкән чаткысыдыр. Шуның аркасында, гаскәриләр арасында башбаштаклык, үземез яхшы дип сайлаган кешеләремезнең биргән әмерләренә буйсынмау кеби гамәлләр эшемезнең алга китүенә киртә булып торалар.

Эш башындагы кешеләремез дә аптыраштa торалар. Бәгъзе бер роталарымыздан гаскәри иптәшләремезнең үз белдекләре белән, һичкемнән сорамый кайтып китүчеләренә вә үзләре сайлаган кешеләргә кырын караучыларга шуны әйтәмез: «Иптәшләр! Сез ник болай кайтып китәсез? Үз халкыгызның, үз милләтегезнең гүзәл, якты тормышын сөймисезме? Теләмисезме?»

Нинди зур тартыш, зур теләк вә өметләр белән алган полкымызны ташласак, эш башындагы кешеләремезгә кырын карасак, үз-үземезгә аяк чалсак, без милли полкымыз булу белән милләтемез өчен нинди файда китерермез икән? Чит милләтләр каршында хурлыкка калмамыз микән?!. Татар солдатының соңгы матур исемен сатмамыз микән? Киләчәк балаларымыз каршында җаваплы булмамыз микән?.. Менә без шуны аңлыйк та бер көч, бер теләк булып, полкымызны уку вә тәрбия йортына әйләндерик. Без, тәрбияне тәкъдир итсәк, бөтен дөньяда татар солдатларының исемен тәкъдир итәчәкмез.

Татар солдаты.

ТӨРЕК-ТАТАР ШТАТЫ

Милләт мәҗлесенең[7] узган ел 29 нчы ноябрьдәге җыелышында, Русиянең хәзерге гомуми сәяси хәлен игътибарга алып, Төрек-татар штаты ясарга беравыздан карар кылынды. Бу штатта күбрәге башкорт, татар, мишәр һәм типтәрләр кеби төрек-татарлар торганлыктан, бу штат Төрек-татар штаты дип атала.

Бу штатны җәнүби Урал илә Урта Идел буе Казан, Оренбург, Уфа, Пермь һәм Вятканың бер кисәге, Самара һәм Сембер вилаятьләре (губерналары) тәшкил итә. Штатның читләре (кырыйлары) тәгаен кылынгач та Милләт мәҗлесе шул вилаятьләрне Русия кушма җөмһүриятенең мөхтәр (ирекле) бер төрек-татар кисәге итеп игълан итәчәк[8].

Әлбәттә, һәрбер ислам нуры илә йөрәге балкыган татар, башкорт, мишәр, типтәрләр (безнең һәркайсымыз мөселман булганлыктан, фәкать үземезнең мөселман дөньясын гына көчәйтү максаты идеген онытмый) һичбер фиркаләргә бүленмичә, фәкать бөтенемез бер җан, бер тән булып, Русия җөмһүриятенең Төрек-татар штаты ясау эшендә тырышырга тиеш.

Шуны да онытмаска кирәк ки, Кавказда йөзгә якын милләт булса да, алардан һәркайсы үз кирәкләрен, үз корсакларын кайгыртмыйча, фәкать гомуми Кавказ хокукын (кирәген) алыр өчен Кавказ милләтләренең бөтен сәяси хезмәткәрләре бер тимер көч булып оешып, Кавказны аердылар.

Үземезнең киләчәк буынымыздан шелтә алмас өчен, без төрек-

[7] Милләт мәҗлесе — төрки-татарларның милли парламенты. 1917 елның 20 ноябреннән 1918 елның 11 гыйнварына кадәр Уфа шәһәрендә эшли. (ТЭС.Т4. — Казан: 2014. — Б.157.)
[8] 1918 елда татар һәм башкортларның милли дәүләтчелек проекты — Идел-Урал штаты гамәлгә ашмый кала.

татар милләтенә дә татарга, башкортка аерылмыйча, Кавказ халкыннан үрнәк алып, залимнәр тырнагыннан мөселманнарны аерып, Төрек-татар штаты ясау кичектерелмәс бурыч. Без шулвакытта гына камил дәрәҗәдә Коръән кушканча гамәл кыла алырмыз. Х.Я.

ЧЫҢГЫЗ КЕМ?

(Фельетон)



– Әхмәдвәли! Чыңгыз да, Чыңгыз, диләр. Җыелышларга барсаң да аның исемен ишетәсең, газеталарда да шуның исеме еш очрый. Өстән генә аңлавыма күрә, аның безнең бабаларымыздан атаклы бер баһадир булуын белсәм дә, кайда булуын, аның ниләр эшләгәнен ачык белә алмыйм. Җае килгәндә син миңа шул Чыңгыз турында кыска гына булса да бераз сөйләп төшендерсәң иде.

— Бик иптәш, бик. Мин аны сиңа шатлык белән сөйлим. Чыңгыз ул, дустым, батырлыгы, гайрәте белән безнең татар тарихының якты бер йолдызы. Моннан алты-җиде йөз еллар элек безнең татар халкы таркау көенчә кабилә-кабилә булып кына яшәгәндер. Үз ыругларыннан кала башкага катышмый, Сибириядә Кытай чигенә якын җирләрдә көн иткәннәр. Алар, төрлеяры чәчелеп бер хөкүмәтсез яшәгәнгә күрә, тирә-яктагы чит халыклардан байтак золым вә авырлыклар да татыганнар. Үзләрендә каршы торырлык оешкан бер көч булмаганлыктан, читләрдән килгән уңайсызлыкларны алар тавыш-тынсыз гына күтәрә килгәннәр. Аларның малларын кытайлар килеп тә талаганнар, Боз диңгезе ягында торучы вәхши халыклар да татарларга җәбер җибәреп торганнар. Татарлар, үзләрен сакларлык көч ясап, боларга каршы тормакчы булсалар да, кинәт кенә оешып җитә алмаганнар. Менә шул вакытларда аларны бергә җыеп, таркау ыруларны укмаштырып куярлык бер каһарман чыга ки, ул да Чыңгыз була. Чыңгыз үзенең тырышлыгы вә сәясәткә осталыгы аркасында көчле бер хөкүмәт төзеп, татарларны дөньяга танытырга ирешә. Аз гына бер вакыт эчендә куәтле татар ханлыгын ясый.

Гаскәри куәтне тергезеп, татар гаскәрен ул вакытның иң куәтлеләреннән вә камилләреннән саналырлык бер дәрәҗәгә җиткерә, тирә-яндагы башка халыкларны да үзенә буйсындыра. Үзе артык гайрәтле, килбәте белән котны очырырлык бер кеше булса да, бүтән халыкларны җәберләргә ирек бирмәгән. Аларга теләгәннәренчә торырга, үз диннәрен тотарга камил ихтыяр биргән. Шунлыктан, ул вакытта золым күреп торган көчсез милләтләр үз ихтыярлары белән Чыңгызга тапшырылып, аның хөкеменә буйсынганнар.

Чыңгыз аларны үз химаясенә (канаты астына) алып, бүтәннәрдән кыерсыттырмаган. Шунлыктан аны кул астында булган бөтен халык сөйгән. Аны сөюләре, аңа буйсынулары кылычыннан бигрәк, үзләрен оештырып башкаларның золым-җәберләреннән саклаучы, изелгән халыкны яклаучы сыйфаты белән булган.

Аның юлдашы — солдат, сөйгән эше — йорт-ил, җир йөзе, теләге — илнең төзеклеге, хезмәте — кул астындагы халыкның тынычлыгы өчен булган. Татар тарихында мәңге онытылмаслык бер урын алып, безнең өчен гомер буе макталырга тиешле бер каһармандыр. Ул үз халкын коллыктан коткарып, бүтәннәргә таныткан. Ул татарларның кулларыннан да уйланмаслык зур эшләр килүен эш белән күрсәткән. Башкалар белән бергә аларның да җир йөзендә хөкем сөрергә хаклары бар икәнен исбат иткән. Шуның өчен без аның белән мактанамыз.

Батыргәрәй.

ТӘҮФЫЙК

Аллаһы Тәгалә — юмарт, юмартлыкны ярата вә күркәм холыкны сөя һәм, киресенчә, начар холыкны сөйми.

(Хәдис)

Без, мөселман балалары, тарихта әхлакымыз белән беренче урынны тотканмыз. Сәбәбе — безнең динемез бик күп начар нәрсәләрдән тыйган. Әмма руслар белән бергә тора башлагач, бигрәк тә русларның казармаларында кара урыс солдатлары белән безнең бик күп әхлакымыз бозылган. Начар йогышлы гадәтләр сырхау кебек безнең арамызга кергән. Инде без, мөселман гаскәриләре, үз башымызга үземез яши башлагач, ашларымызның гына үземезнеке булуына шатланырга җитмидер, бәлки иске төрек-татарларның пакь әхлак вә тәүфыйкларын кайтарырга да бурычлымыз. Әхлагы яхшы булган адәм — ярлы булса да, күңеле бай, киләчәге өметле була. Яшәсен яхшы, әхлаклы тәүфыйклы мөселман гаскәриләре!

Ахун Гатаулла Баһаветдин.

ТӘРТИП ВӘ ЧИСТАЛЫК

Кадерле иптәш солдатлар!

Иске Николай заманында изелгән бер милләт булып яшәгәндә, шул русларның иң кабахәт, иң шакшы эшләрен эшләргә безгә кушалар вә безне көчләп эшләтәләр иде. Гәрчә без авылларымызда алардан чистарак, һәркөн җыенып, бишәр вакыт намазларны укып, йортларымызда тәртипле рәвештә торсак та, шул тышкы яктан караганда чиста вә тәртипле булып күренгән, ләкин эчке яклары иң кабахәт вә нәҗесләргә баткан казармаларга килеп керүемез белән үземезне онытып, шуларның кабахәтләрен без җыярга мәҗбүр буладыр идек. Вә шул эшләрне эшләргә безне көчләп кушалар иде.

Кадерле иптәш солдатлар! Ходайга шөкер булсын, без шундый көчләүләр астыннан чыктык! Безне көчләүчеләрне вә газаплаучыларны аяк астына салып таптадык! Хөр Русиянең бөек гражданнары булдык! Теләгәнемезчә торып, эшләремезне һичберәүдән курыкмый, бәлки вөҗданымыз кушуы буенча эшли башладык.

Менә, иптәшләр, шул иске кортларны агулап үтерергә вә аларның җәелгән тамырларын изгәләп җыеп ташларга вә икенче аларны үсмәслек дәрәҗәдә итәр өчен без ни эшләргә тиеш? Ошбу эшләрне тәртипле рәвештә алып барырга, динемез, Коръәнемез, пәйгамбәремез, вөҗданымыз кушу буенча чисталыкны сакларга тиеш. Без никадәр чисталыкны алдымызда тотсак, шулкадәр милләтемезнең алга баруына вә милләтемезнең сәламәтлегенә ярдәм итәчәкмез. [...]

Фельдшер Габдрахман Даллин.

Текстларны басмага
***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

КЕМНӘР СОҢ БЕЗ – ТАТАРЛАР?

Рабит Батулла

Быел борынгы бабаларыбызның Бөек Һун каһанатын (Хунну) коруына 2105 ел тулды. Ошбу дәүләт Безнең дәвергә (эрага) кадәр 210 елда бүгенге Кытайның төньяк туфрагында барлыкка килгән. Беренче түрәсе шаньюй Туман (Төмән, Томан) атлы булган. Байрагында аждаһа сурәте җилфердәгән.

Ул вакытта «каһан, хан, солтан, падишаһ» атамалары юк әле, ил башлыгын, ыру җитәкчесен «шаньюй» дип атаганнар. **Шаньюй** — кытай сүзе, «Тәңре тарафыннан куелган юлбашчы», «бөек түрә» мәгънәсен аңлата. Андый дәрәҗә тәхет иясенә генә бирелгән.

«Һун (гун, хунн, сөн) каһанлыклары» төшенчәсе күп кабиләләрне берләштергән дәүләтләрне үз эченә ала. Аурупа елъязмачылары аларны «гуннар», «төркләр», «вәхшиләр» («варварлар») дип тә йөртә. Кытайча шул ук бер кавемне төрлечә атау бар: «шунь-вей», «гуйфан», «сюнну». Боларның барысы да төрк телле үзара бик якын кардәш ырулар була. Ләкин күп кенә тарихчылар аларны турыдан-туры «татарлар» дип атый. Бу сүзнең мәгънәсен без дә бер телдә сөйләшә торган берничә кабиләне туплаган халык рәвешендә аңлыйбыз.

Эдуард Паркерның «Татары. История возникновения великого народа» («Тысячелетняя история татар») һәм **Рафаэль Безертиновның** «Татары, тюрки — потрясатели вселенной» исемле китапларындагы кайбер кисемтәләрне искә төшерик.

Шаньюй Туманның ике углы була. Беренчесе — **Баһадур** атлы (кытайлар аны **Маодунь** дип тә, **Модә (Модэ)** дип тә язалар). Хаким атасы Тәңре катына аша калса, йола кушканча, тәхеткә Баһадур утырырга тиеш. Ләкин иң сөекле хатынының котыртуы аркасында Туман, йоланы бозып, тәхеткә әлеге сөекле хатынының углын утыртырга ният кыла, шунлыктан Баһадурны көндәш якка (бүгенге **Голҗа** шәһәре тирәсендә яшәгән юэчҗиләргә[1]) рәһен[2] итеп җибәрә. Канун буенча, тоткындагы варисның атасы ул тарафка яу чапмаска тиеш була, тискәре очракта дошман рәһенне үтерергә хаклы санала. Яшь хатын котыртуы аркасында Туман юэчҗиләргә сугыш ача. Түрә үз углын чит кулдан үтертергә тели. Әмма мәкерле хәйләне сизенеп, Баһадур, юэчҗи илбашының иң яхшы атын урлап, ватанына, атасы янына кайта. Туман дошманнар тоткынынннан исән-сау котылган углына шакката, аның бу батырлыгын хуплый, озаклмый аңа бер төмән (ун мең кешелек) гаскәр бирә, ягъни төмәнбашы (хәзергечә әйтсәк, генерал) дәрәҗәсенә күтәрә.

Тәгин[3] атасының хыянәтен оныт-

[1] Юэчҗи — борынгы кабилә.
[2] Рәһен — ирекле тоткын.
[3] Тәгин — варис, тәхеткә утырачак углан.



Атилла империясе (434-453 еллар)

мый, әлбәттә. Шулай да, әчендә нинди уй яралганын беркемгә дә сиздерми. Сугышчыларын кырыс кагыйдәләргә өйрәтә. Коралын камилләштерә: укларының башагына тишек ясый, зур тизлек белән очканда алар ачы тавыш чыгара, ун мең кеше берьюлы атса, коточкыч куркыныч сызгыру ишетелә, бу аваз дошманнарның йөрәгенә курку сала.

Тәгин нәрсәгә төзәп атса, аның бөтен гаскәре дә шул тарафка ук очырырга тиеш була. Баһадур сугышчылары алдына дөнья бәясе торган иң шәп атын куя, үзе шуңа ук очыра, күп яугире аның гамәлен кабатлый, ат егыла, җан бирә. Тәхет варисы атмый калганнарның башын чаптыра.

Озакламый тәгин яраткан хатынын төмән каршына куя, хәләл җефетенә ук ата, гаскәр дә шулай итә. Булачак түрә боерыкка буйсынмаганнарның башын чаптыра.

Яуга чыгар алдыннан сугышчыларын барлап йөргәндә Баһадур атасы тарафына ук ата, Туманга ук атмаган бер генә яугир дә калмый. Шаньюй тишкәләнеп җиргә ава.

Шулай итеп, гаскәр һич карусыз төмәнбашының әмерләрен үтәргә әзер була. Озакламый Баһадур тәхеткә утыра һәм бик куәтле дәүләт төзи. Яңа шаньюй Хыянәтче хатынны һәм түрәлеккә өмет баглаган көндәшен (энесен) үтертә. Үзе кытайлар тарафыннан яулап алынган җирләрен кире кайтарырга әзерләнә башлый.

Ләкин бу вакытта Һун каһанаты белән дунху (тунгус, монгол) кабиләләре арасында җир өчен низаг чыга. Тегеләре көч туплап өлгергән. Канда сугыш гайрәте кайный. Һуннардагы эчке каршылыклар аларны тик тормаска, хәрәкәт итәргә котырта. Иң әүвәл Баһадурга илче җибәреп, аның иң җитез атын сорый болар. Түрә яраннары белән киңәш-табыш итә.

— Юк! — диләр киңәшчеләр. — Ул ат дөнья бәясе тора! Аргамагыңны дошманнарга бирмә!

— Күрше дәүләттән килгәннәр бит, күрше хакы — Тәңре хакы! — ди Баһадур һәм сөекле атын илчеләргә биреп җибәрә.

Дунхулар, Баһадур бездән шүрләде,

дип янә килеп җитә, һун түрәсенең иң гүзәл хатынын сорыйлар. Яраннары ризалашмаска киңәш итсә дә, шаньюй сөекле җәмәгатен дә дошманга тапшыра.

Дунхулар әдәп кысаларыннан чыгып, һуннардан кеше яшәми торган, уңдырышсыз җир кисәген сорыйлар. Яраннары бу юлы күнәргә тәкъдим итә, ләкин Баһадур аларның башын чаптыра да:

— Атны да, хатынны да күршеләргә бирергә була, әмма җир өләшү — дәүләтне сату ул, — дип дунхуларга каршы сугыш ача һәм аларны җиңә, Кытайлардан яулап алынган океангача туфракны үз мәмләкәтенә куша. Бөек бабабыз Туман углы Баһадур, Һун каһанаты белән 36 ел идарә итеп, Безнең дәвергә кадәр 174 елда, моннан 1841 ел элек Тәңре хозурына барып ирешә. Бөек баһадирның кабере нурлы булсын!

Тайвань галиме Чхао Чху-Чеңнең «О значении этнонима «татары» в китайских источниках...» атамалы мәкаләсенә дә күз ташлыйк («Идел» журналы, 1994, 11-12 саннар, 43 бит): *«Татар» атамасы Кытайда да түгел, Византиядә дә түгел, Монголиядә дә түгел, Орхон җирендә табылган төркчә язмаларда күренә. Мәсәлән, ул сүз 731-732 елларда Күлтәгин шәрәфенә куелган ташка уелган... Бу мәрсиядә*[4] *төркләрнең ике этнонимы аталган — «утыз татар», «тукуз татар». Күрәсең, монда утыз яки тугыз кабиләне үз эченә алган татар хәрби берләшмәсенең атамалары турында язылгандыр».*

«Татар» исеме Кытай язмаларында «та-та» яки «да-да» шәкелендә 862 елда гына күренә башлый (чин телендә «р» хәрефе юк). Ул атама тагын 880 елгы чыганакларда искә алына. Анда баш күтәргән халыкларны бастыруда Кытай династиясенә ярдәм иткән күп санлы татар гаскәре турында сүз бара.

«Җир йөзендә... даны, уларының

«Баһадур». Олег Леонтьев рәсеме

бөеклеге буенча татарны узган халык юк. Бу халык — чын-чынлап дөнья хакиме: гүя башкалар аңа хезмәт итәр өчен генә яратылган. Ул империяләрнең тигез дәрәҗәдә төзүчесе дә, җимерүчесе дә, һәр заманда ул җиһанга үзенең кодрәтен күрсәткән, һәр дәвердә ул Тәңре кылычы булган. Татарлар Кытайны ике тапкыр алган һәм әле дә үзенә буйсындырып тота. Алар Бөек Могол мәмләкәтенә кергән иксез-чиксез мәйданнарда идарә итә. Алар — Фарсы иле хуҗасы. Алар Кир һәм Гистапс тәхетләрендә утыра. Алар Мәскәвияне яулаган. Төрекләр исеме белән алар Аурупа, Азия, Африканың байтак өлешенә басып кергән, нәтиҗәдә, бүген дөньяның өчтән бер өлешендә хакимлек кылалар. Инде ераграк чорларга карасак, Рум империясен тар-мар иткән байтак кавемнәрнең дә нәкъ менә татарлардан чыгуын күрербез. Александр

---

[4] Мәрсия — мәрхүмнең якты истәлегенә багышлап язылган мактау сүзе.

Кыпчак яугире

яулары Чыңгыз хан яуларына якын торырлыкмыни? Бу җиңү белмәс халыкның могҗизалы батырлыкларын данлыклау өчен фәкать тарихчылары гына җитмәгән. Никадәр үлемсез гамәлләр онытылуга дучар ителгән! Тарихка нәмәгълүм күпме дәүләтләр торгызгандыр алар! Бу яугир халык, бүгенге даны белән генә яшәгән һәм һичкайчан җиңелмәсенә инанган хәлдә, үзенең элгәреге казанышларын мәңгеләштереп калдырырга кирәк санамаган», — дип яза Монтескьё «Фарсы хатлары»нда (LXXXI хат).

Билгеле, мондагы «татар»га монголлар да, төрк халыклары да, Алтай, Себер, Амур якларында яшәүче башка кабиләләр дә керә. Аурупа, урыс тарихчылары да яу чапкан һәммә кавемнәрне бер казанга салып болгата, «татар-монгол», «монгол-татар» ди. Аларны укыган кеше бу ике халыкны берүк милләт дип уйларга һәм ялгышырга мөмкин. Югыйсә, Чыңгыз, Җучи, Бату ханнар гаскәрендә бик күп ырулар сугышкан. Аңа да карамастан, урыс шуның бөтенесен «татар яулары», «татар игосы» дип атаган. Инкыйлабка кадәр хәтта азәрбайҗан-әрмәннәрнең дә «татар» исемендә йөрүе мәгълүм.

XIV йөздә (1247-1318) яшәгән фарсы тарихчысы Рәшидеддин язуына караганда, татарларның артык мәшһүр, артык бөеклегенә күрә, башка төрк кавемнәре, тышкы яктан хәтта татарга охшамасалар да, үзләрен «татар» дип йөртә торган булган. Мәсәлән, татарлар берлегенә кергән тутыккылыч, алчы, чаган, тәрат, куин, баркуй кабиләләре 70000 йорт тәшкил иткән. Бер йортта унлап кеше яшәсә дә, 70 000 х 10 = 700 000, бүгенге Монголия җирләрендә урта гасырларда миллионга якын татар утырган булып чыга!

«Татар гаскәренең куәте һәм тәртибе шулкадәр гаҗәеп, искитмәле зур иде ки, ул, һичшиксез, бөтен дөньяны буйсындыра алыр сыман тоелды», — дип яза билгесез Кытай елъязмачысы (XII гасыр).

Баһадур вафатыннан соң Һун каһанаты (Хунну) таркалгач та бабаларыбыз кул кушырып ятмый, яңадан куәт җыярга тотына һәм дәүләт арты дәүләт төзи.

Академик Василий Бартольд: *«Чыңгыз ханга якын кешеләрдән иң беренчеләрдән булып уйгыр укымышлылыгын Шики-Хутху нойон (сабый чагында ук Чыңгыз ханның хатыны тарафыннан уллыкка алынган татар) үзләштергән булса кирәк. Чыңгызхан аңа мәхкәмә эшләрен тапшыра»*, — ди («Сочинения», 1 том, 457 бит).

Ләкин Алтын Урда (Җучи Олысы, Олуг Олыс) кемнеке булган соң? Монголныкы, татарныкы, әллә башка бер халыкныкымы?

Алтын Урданың мәркәзе Идел буенда. Кырымда, Кавказда, Себердә, Оренбург ягында, Идел-Җаек буйларында әле дә булса Алтын Урда дәүләтенә кергән татарлар гомер кичерә. Алар күчеп килгән халык түгел, алар әүвәлдән шунда, үз туфракларында яшәгән, яши. Анда бер генә монгол да юк. Калмыклардан башка. Болары, чыннан да, монгол. («Калмык» — «калмак» дигән сүз. Монголлар үз ватанына чигенгәндә аларның бер өлеше бүгенге Калмыкия республикасы җирләрендә утырып калган.) Олуг Олыста иске татар теле — дәүләт теле булган. Хан ярлыклары татарча язылган. Монголча бер генә документ бар. Анысы да — уйгыр имласында.

Шулай икән, тарихчылар нигә «татар» урынына «монгол», «монгол» урынына «татар» дип яза соң? Аңларга тырышып карыйк.

Тарихчы **Марк Альтшулер** язуына күрә («Военная тайна» журналы, 2014, №1), *«Согласно «Сокровенному сказанию» (китайский перевод генеалогической истории рода Чингизхана), Есугей по дорое был отравлен татарами»*.

Бу вакыйга XII йөзнең башында була.

Чыңгызханның атасы монгол **Ясүгәй** татарларны җиңә һәм аларның тәхет варисын — **Тимучин (Тимерче)** исемле сабыйны әсирлеккә ала, ә үзенең баласы тугач, аңа көндәшенең улы йөрткән исемне куша. Бу язмада ике ыруның аерым халыклар булуы, хәтта аларның үзара дошманлашып яшәве ап-ачык күренеп тора.

Күпмедер вакыттан соң татарлар Ясүгәйне агулап үтерә. Әлеге күренешкә шикләнеп караучылар, «ул тирмәгә кергәнче үк чирле булган, татарларга каршы сугыш ачар өчен генә монголлар «агулау» фаразын уйлап чыгарган», дигән фикердә торучылар бар.

Тимучин, гаскәр туплап, атасының кан үчен ала, коточкыч яуда татарлар янә җиңелә.

Бу сугышны **Фатих Аблак** менә болай сурәтли («Татар тарихына карата берничә сүз» исемле кулъязма мәкаләсеннән): *«Уникенче гасырда Буйр-Нур күле янында гаять куәтле нәсел — татар кабиләсе яшәгән. Аларның янәшәсендә мыңгу (монгол) халкы да гомер кичергән. Татарлар белән монголлар бергәләшеп Кытайга ябырылмасын, дип Кытай императорлары татар белән монголны бер-берсенә гел каршы котыртып, сугыштырып торган.*

1196 елда менә шундый сугышларның берсендә монгол җитәкчесе Тимучин шөһрәт казана, «көндәшләрен» җиңә, әсирләрнең арба чәкүшкәсеннән биегрәкләрен кылычтан уздырырга боера. Татарлар: «Үләргә булгач, үләргә, арба янына барганда һәркем җиң эченә пычак тыгып килсен, ичмасам, дошманнарның гәүдәләреннән түшәлгән түшәккә ятып үлик», — дип сүз куешалар, вакыты җиткәч, шулай итәләр дә. Бу канкоешта ике тараф та күп кырыла. Татарларның җитәкчесе ***Мәңгүч-Сәүлтү*** *һәлак ителә. Әлеге вакыйгага шаһит башка төрк халыклары — аргыннар, буйраклар, карлуклар, кошчылар, осыннар — татарларның батырлыгына сокланып, үзләре дә «татар» исемен йөртә башлый».*

Тарихчыбыз **Камил Аблязов** «Историческая судьба татар» китабында язганча: *«Тарихи чыганакларны дикъкать белән укыганда, шуны күрәсең: Буйр-Нур йортының тар-мар кылынуы, «Изге язмалар»да хәбәр ителгәнчә, татарларның мотлак җимерелүе булмый әле. Татарлар бөтенләй юкка чыкмый. Киресенчә, аларның язмышы кискен борылыш ясый, алар яңадан үрчи, кан кардәшләре белән берләшә һәм тәкъдир аларны яңадан-яңа көрәшләргә ыргылырга өнди».*

Уртак ватаннары таркалганнан

соң аерымланган болгар, хәзәр, авар, кыпчак кебек халыклар XIII гасырда күмәкләшеп Алтын Урда мәмләкәтен төзи. Анда гомер кичергән барлык милләтләрне дә (урыстан гайре) «татар» дип атау гадәткә керә. Түрк булмаган кабиләләр дә татарлаша, татар теллегә әверелә. Күбесе исламга күчә. Калганнары үз динендә кала. **Саба, Балтач, Зәй** якларында әле дә шундый авыллар бар, андагы халык үзләренең чуваш, удмурт, мари токымыннан икәнен яхшы белә, ләкин яңадан үз тамырларына кайтырга теләми инде. Шул рәвешле, ул төбәкләрдә сап-сары, җирән чәчле татарлар яшәп ята.

Октябрь түнтәрелешеннән соң азәриләр, нугайлар, кумыклар, каракалпаклар, балкарлар татарлыктан баш тарта, бары тик бүгенге мишәрләр, типтәрләр, керәшеннәр, кырымлылар гына ахыргача «татар» исеменә тугры кала.

Әле кайчан гына бәгъзеләр «без татар түгел, болгар», «мөселман түгел, тәңрече» дип милләтебезнең башын бутап карады. Ләкин бинибая күпчелек бу коткыга бирелмәде, «татар булып туганбыз, бу дөньядан татар булып кына китәчәкбез», диделәр. Чыннан да, болгар нәселе дә без, чыннан да, тәңречеләр токымы да, ләкин күпме сулар аккан, еллар узган, Җир йөзе үзгәргән — инде яңгыравыклы, мәшһүр «татар» исемен, милләтебез атамасы буларак, һич кыенсынмыйча, һич кимсенмичә, горур күтәрик, дуслар! Үткәнебез оялырлык түгел!

Кара фикерле бәндәләргә каршы торыр, аларның авызын каплар өчен, татар тарихын тирәнтен белергә кирәк! Без мескен халык түгел! Кыенлыкларны, кимсетүләрне кичеп тә, изелеп, суккаланып та үз исемебезне, үз җисемебезне — татарлыкны! — саклап калган батыр халык без!

Татарлыктан татар
һич гарь[5] итәрме,
Кеше үз исмене инкарь итәрме?!
Татарлыкта татар
углы татармын,
Татар түгел димә —
башың ватармын!

Дәрдмәнд

Татар булсаң, татар бул, дошманыңны ватар бул!

Халык мәкале

Татар теленә тел тидергән тилчәтелнең телен телем-телем телгәләп, тагын-тагын тураклап, тегермәндә теткәләп, түбәдән тәгәрәтермен!

Халык әйтеме

Кардәшләрем, татар исемнәреннән качмыйк, Альбертлар, Робертлар, Луизалар, Кларалар матур яңгыраса да, борынгы түрк-татар исемнәре безгә ныграк ятышып тора лабаса! Исемеңнән качу — мескенлекнең башы ул.

Модә баһадир (б.д.к. III йөз), **Аттила баһадир** (V йөз), **Кубрат хан** (VII йөз), **Аспарух хан** (VII йөз), **Алмыш хан** (X йөз), **Кол Гали** (XII йөз), **Үзбәк хан** (XIII йөз), **Чалу бәй** (XIV йөз), **Олуг Мөхәммәт хан** (XV йөз), **Кузычак углан** (XVI йөз), **Сөембикә-ханбикә** (XVI йөз), **Мөхәммәдъяр** (XVI йөз), **Япанча баһадир** (XVI йөз), **Батырша** (XVIII йөз), **Акмулла** (XIX йөз), **Габдулла Тукай** (XX йөз), **Хәсән Туфан** (XX йөз), **Кәрим Тинчурин** (XX йөз), **Муса Җәлил** (XX йөз), **Дмитрий Карбышев** (XX йөз), **Пётр Гаврилов** (XX йөз), **Гази Заһитов** (XX йөз) — каһарманнарыбызның очына чыга алмаслык! Шулай булгач, син ата-бабаларың кылган гамәлләр белән горурлан, башкалар исемен алырга, аларга охшарга тырышма! Юкса, **Ассимиляция Матадоровна Вәлиева** яисә **Венерик Симпатович Гайнетдиновлар** булып күпме яшәргә мөмкин инде?!

Дәвамы бар ■

[5] Гарь — гарьләнү, кимсенү, оялу.

ЗӨБӘРҖӘТ КҮЛЕ

Зөбәрҗәт күле (Изумрудное, Карьер күле). Элек бу күл урынында ком карьеры булган. Карьер, Идел елгасының борынгы үзәнлегенә туры килү сәбәпле, тиз арада су белән тулган. Күлнең өч ягында ылыслы урман, ә бер ягында Юдино посёлогы, ерак түгел балалар тимер юлы урнашкан. ■

ЕГЕТ КЕШЕГӘ ҖИТМЕШ ТӨРЛЕҺӨНӘР ДӘ АЗ, ДИГӘН СҮЗ – РАСТ СҮЗ

Хикәят[1]

Сәмарканд шәһәрендәге мәдрәсә. В.В.Верещагин рәсеме. 1869-1870 еллар

Ахыры. Башы 1 нче санда.

Кибетләрне һәм йортларны сатып, Сәмәркандка сәфәр кылдылар. Сәмәркандка килеп, бер йортка фатирга кerделәр, иртәгесен карасалар: Габдулла бай юлда ук бар акчаларны төшереп калдырган. Нан [икмәк] алырга да акчалары булмады, ул көн янә ач калдылар, икенче көн янә ач, өченче көн янә ач калдылар, чөнки саиллек [теләнчелек, хәерчелек] кылырга да җөрьәтләре юк иде. Бичара Әмин бай скрипка уйнар иде, баглар юк, язу язар иде, хаинлек белмәй, шатранҗ уйнар иде, падишаһзадә кеби гакылы күп адәмнәр юк.

Хәйран булып өч көн ач үткәрделәр, дүртенче көн иртә берлән Әмин бай атасы берлән анасына әйтте:

— Бүген кол базарында, бәне кол дип сатыңыз, ләкин мең алтыннан ким бирмәңез, мин үзем колнамәсен язып кулыңызга бирим, насыйп булса, дөньяда кавышырмыз, әгәр насыйп булмаса, иншаллаһ, кыямәттә кавышырмыз. Сез болай ачлыктан үлмәссез, ачлыктан үлмәк яман эш, — диде.

Ахыр атасы берлә анасы еглагач, күнеп, колнамәсен язып бирде дә, Габдулла бай берлә хатыны Әмин байны кол базарына алып барып коллар катына куйдылар. Шулвакытта Карахтай тарафыннан, Һиндустанның Калькут шәһәреннән бик зур бер бай кәрваны берлән кайтып киләдер икән. Үзенең янында хезмәт кыла торган яшь колы юк икән. Шул бай кол базарына бер арзан кол алыйм, дип килде һәм күзе Әмин байга төште. Бик мәхәббәтле күренде дә, Габдулла байдан сорады:

— Бу ни исемле кол? Бәһасе ничә? Ни һөнәр беләдер? — диде.

Габдулла бай әйтте:

— Исеме — Әмин бай, һөнәре — бик хезмәткәр һәм бик гадел, тугры. Сатмас идек, фәкыйрьлегемез бар, шул сәбәптән сатамыз. Бәһасе — мең алтын, ким бирмәймез, — диде.

Бай бик сәүдәләнде, киметмәде, ахырында мең алтын бирде һәм Әмин байны бер ишәккә менгереп, кәрван берлән киттеләр. Әмин бай шул юлда байга һәм байның барча хезмәткәрләренә шулкадәр хезмәт итеп бара ки, хәйран калдылар хезмәт итүенә. Беренче көн сәфәр кылгач, юлда барганда кәрван адашып, бөтен кәрван сусыз калды. Хәтта дөяләр үлү дәрәҗәсенә ирештеләр. Һәр адәм «аһ» итеп су эзләп йөргәндә, бер ташланган тирән кәкре-бөкре кодок [кое] таптылар. Байга әйттеләр:

— Бер кодок таптык, ләкин һәркаюларымыз сусыздан үлсәк тә, ул кодокка төшәргә разый түгелләрмез. Адәм төшми суны алыр хәл юк, куркамыз — җенләнгәндер, — диделәр.

Бай әйтте:

— Әмин бай, син ни әйтерсең? — диде.

Әмин бай әйтте:

— Тәвәккәл Аллаһка, без хезмәт кыламыз, — диде. Шунда ук чиләк китереп, бау бәйләп, Әмин бай чиләккә утырып, бауга тотынып кодокка төшеп китте дә, чиләккә су тутырып меңгезеп җибәрде. Тартып алдылар, суны эчтеләр, янә чиләкне төшереп, дөяләрне сугарып һәм су савытларын тутырдылар.

Ярты көннән соң кәрван китмәк булды һәм бай үзе кодокка агызны куеп кычкырды:

— Әй, Әмин бай, имде суның хаҗәте юк, үзең чык, — диде.

Әмин бай күрде: кодокта ике ишек бар, берсен ачты, күрде: бер хәҗәрә [таш]

эче тулы һәртөрле асылташ. Шул ташлардан бер чиләк тутырып байга бирде. Бай чиләкне тартып чыгарса, күрде: шулкадәр кыйммәтле асылташ, бер чиләге байның бөтен кәрвандагы малыннан да суммалырак. Янә чиләкне төшерде, янә тутырып бирде. Барлыгы Әмин хуҗага егерме чиләк тутырып бирде дә, кычкырды:

— Әй хуҗа, тәмам, бетте!

Бай әйтте:

— Чык! — диде.

Әмин бай чиләккә утырды. Бай чиләкне тартканда шайтан байга вәсвәсә кылды:

— Бу Әмин бай колның сыналганы юк, ихтимал, шәһәргә кайткач, мин бу кадәр мал табып бирдем, дип падишаһка гарыз кылыр, хәзер чиләк җебенә пычак тигерсәң, эше бетәр, һушсыз булыр, — диде.

Бай, Әмин чыгып җиткәндә генә, бауны кисеп җибәрде. Әмин бай кодок төбенә төшеп китте. Бай кәрванның беренче дөясенә асылташларны төяп юлга китте. Бу эшне хезмәткәрләре ничек икәнне белмәде. Әмин бай, һушы килгәч, бау киселгән җирне карады: өзелгән микән яисә киселгән микән, дип. Киселгәнен күрде һәм хәйран калды: яхшылыкка — яманлык дип, мәзкүр кодоктагы ишекнең икенчесен ачты. Анда бер көрсигә [тәхеткә] утырган гыйфритне күрде. Аның сакалы тезеннән, башы тубал кебек, корсагы сыер корсагы, колагы ат колагы кеби, күзен йомган, ә кулында скрипка. Әмин бай скрипканы күргәч, күпме вакыттан бирле уйнаганым юк, эче һәм бик пошканга, сорады:

— И гыйфрит, мөмкин булса, әмер итсәңез, скрипкаңыз берлән бераз уйнар идем, — диде.

Гыйфрит ишарә кылды, Әмин бай скрипканы алып әллә ничә төрле көй уйнады. Берничә сәгатьтән соң гыйфрит күзен ачып, Әмин байны күрде дә, аның күзләреннән үпте һәм әйтте:

— И Әмин бай! Әгәр син килеп скрипка уйнамасаң, мин үләдер идем, чөнки минем дөньяда Каһкаһа намында [исемле] бер мәхбүб [яраткан] углым бар иде, ул углым хәзрәти Сөләйманга гөнаһ кылып йөрде. Шуның өчен хәзрәти Сөләйман аны үлтергән иде. Шул углым исемә төшеп, эчемдә кату чыкты, син килеп, скрипка уйнап, катуларым таралмаса, мин ярты сәгатьтән тәмам җан бирәдер идем, чөнки җаһилләрнең [наданнарның] хафа катуы уен берлән тараладыр. Инде минем үлми калуыма багыйс [сәбәпче] булдың. Мин синең ни теләгең булса, шуны кыламын, — диде.

Әмин бай әйтте:

— Мине кодоктан чыгарып, баем артыннан җиткез, мин аңар бу кодоктагы асылташларны бирдем, ул мине кодокта калдырып китте, инде мин янә ул байга барып, янә яхшылык кылаем, — диде.

Гыйфрит әйтте:

— Әгәр теләсәң, байны үлтереп бар малы берлән сине Сәмәркандка илтеп куям, — диде.

Әмин бай әйтте:

— Мөрәүвәт [кешелекле] түгел син, мине чыгарып, баема кавыштыр, мин разыймын, — диде.

Гыйфрит хуп дип, Әмин байны кодоктан чыгарды. Әмин бай күрде — ишәге йөри. Әмин бай ишәгенә менде, аннары гыйфрит ишәге берлән бергә күтәреп, кәрван артыннан җиткезде. Берзаман бай артына караса, Әмин бай ишәге берлән киләдер, бай «аһ» итеп хафа булды, ләкин ничә көннәр юлда килсәләр дә, Әмин бай, байга: «Бәне ни өчен кодокта калдырдыңыз? — яисә, — «Бу кадәр асыл-

حکایت
یکت کشی کا یتمش تورلی هونر آز
دیکان سوز راست سوز

بوکتاب باصمه اولنمشدر قزانده دومبراۋسکی ننك
طبع خانه سنده محمدجان وبرادری شریفجان
الکریمی لرننك خراجاتی ایلان ۱۸۹۶ نچی یلده

بوکتاب ننك باصمه سنه رخصت بیرلدی سانکت
پیطربورغده ۱۶ نچی مارطده ۱۸۹۶ نچی یلده *

Дозволено цензурою. С-Петербургъ, 16 Марта 1896 г.
Типографія Б. Л. Домбровскаго, въ Казани.

ташлар чыгарып бирдем», — дип һич әйтмәде, бары әүвәлгечә хезмәт кылды. Әмма бай бик шикләнәдер иде. Байның гадәте һәр сәнә шулай иде: берничә көнлек юл калгач, бер колны атка менгереп, хат биреп җәмәгатенә җибәрә. Исән-сау кайтулары турында хат язды да, мөһерләп, Әмин байның кулына бирде. Ишәктән төшереп яхшы атка менгерде дә әйтте:

— И Әмин бай, фәлән йолдызга карап тугры бар, бер көннән Калькут шәһәренә җитәрсең, Сәфир дигән бай дип сорасаң, өйне күрсәтерләр, шул өйгә баргач бу хатны җәмәгатемә тапшырырсың, сиңа сөенеч өчен ун алтын бирер», — диде.

Әмин бай бик шатланып хатны алып, юлга китте. Калькут күренгәч, Әмин байның хәтеренә төште: тукта, бән мең алтын биреп скрипка бәласеннән котылып, кодоктан чыктым һәм мең алтын биреп язу үгрәндем, ни өчен мин бу хатны укымай барам, дип хатны ачты. Хатта язган: «Гыйззәтле хәләл җефетем Бибикәй! Бик сагынып сәлам! Сөекле кәмаләткә ирешкән Зөләйхаи Саниягә дә күп сәлам үземездән. Сорасаңыз, бары тәндә җаным гына борчу, чөнки бу хат җибәргән Әмин бай атлы колым сәбәпле, бу ел күп зарар күрдем. Имди казыйдан үтенәмен: булса — төн, көн булса — көндез, без кайтканчы башын киссәләр икән, үзем юлда үтертсәм, казый хөкеменнән башка үтертеп гасый [гөнаһлы] булырмын, дип казый хәзрәтләренә ирсал әйләдем [язып җибәрдем]», — дип кул куеп, мөһер баскан. Әмин бай укыгач, хәйран калды һәм хатны кесәсенә салды. Шәһәргә килгәч, бер дөкянгә кереп, кәгазь алып, кара сорап хат язды да, янә Гайни бай кулы кеби итеп мөһер салды. Сәфир бай йорты кайда, дип сорап, йортны табып, бай хатынына хатны бирде. Бай хатыны хатны укыды да, куанып көлде. Кызы әйтте:

— И әни, кычкырып укы әле хатны», — диде.

Бай хатыны кычкырып укый башлады, хатта: «Гыйззәтле, сөекле җәмәгатем Бибикәй! Бик сагынып сәлам һәм сөекле кызым Зөләйхаи Саниягә күп сәлам. Үземездән сорасаңыз, әлхәмделиллаһ, бик шат кайтып киләмез. Бу сәнә күргән файдам: бер падишаһлардан да болай булмас. Бу файданың сәбәбе — ошбу хат биргән колым Әмин бай аркылы булды. Инде бән вәкил кылдым күршемез Баязидны ата булып утырырга, төн булса — төн, көндез булса — көндез, бу Әмин байга кызым Зөләйханы никах кылып бирегез. Мин кайтканда кызым кияү куенында булсын, туйны бән кайткач кылырмыз», — дип язган һәм мөһер басып, кул куйган.

Хатын Баязид берлән мәхәллә имамын алдырып, никах кылып, кыз куенына Әмин байны ябып, кич булгач боларны вәзир хәмамына [мунчасына] җибәрде.

Төн уртасында кыз берлән кияү ике атка менеп мунчадан чыккач, кайтканда Әмин бай күрде: әллә ничә катлы биек бер йортның әллә ничә тәрәзәсендә кандильләргә ут яндырганнар. Кыздан сорады:

— Бу нинди кеше йорты? Һәркем яткан, бер йортта ут юк, бу йортта гына ут бар, — диде.

Кыз әйтте:

— И сөекле киявем! Ул безнең падишаһымызның дворецы. Падишаһымызның бары бер генә кызы бар, бик матур, башка баласы юк, ләкин падишаһымыз үзе шатранҗ уйный, уенга бик остадыр. Падишаһымыз әйткән: кызымны, падишаһлыгымны бирәмен бәне шатранҗ уены берлән откан кешегә дип, әмма падишаһ оста, отылган кешенең башын кисәдер.

Егет әйтте:

— И хәлял җефетем, иртәгә каенатайлар кайталар, мал бушатасы булыр, эш күп булыр, шәһәрне күрә алмам, сине өйгә кайтарыйм да, үзем тиз генә урамнарны тамаша кылаем, — диде.

Кыз:

— Яхшы, — дип, өйгә кереп китте.

Әмин бай тугры дворецка барып, падишаһка хәбәр бирдерде. Падишаһ әмер итте:

— Керсен! — дип.

Әмин бай падишаһ янына кереп, күрешеп утыргач, падишаһ сүзгә башлап:

— И исемең ничек, каю җирлектән буласыз? — диде.

Әмин бай әйтте:

— Җирем — ерак, исемем Әмин бай. Бән ишеттем сез, падишаһ хәзрәтләре, шатранҗ уйнарга һәвәс имеш, һәм бик оста имеш, дип. Шул сәбәптән, таң атканны көтмәстән, хозурыңызга килдем, чөнки мин дә шатранҗ уенына бик оста булып, бик һәвәс. Мин курыктым, таң атканны көтсәм, ихтимал, әҗәл җитеп үләмен дә, сезнең берлән уйный алмай калырмыз, — диде.

Падишаһ, Әмин байдан бу илә сүзләр ишеткәч, бик шат булып әйтте:

— И Әмин бай, шатранҗны өч мәртәбә калдырудан уйнармыз, әгәр бән өч мәртәбә калдырсам, синең башыңны кистерәм, чөнки бәнем гаһедем [килешүем] шулай. Әгәр дә син калдырсаң, бән сиңа кызымны биреп, падишаһ кылырмын. Шул шартка разый булсаң, уйнармыз, — дип әйтсә дә, — и егет, башың китәр, юкка уйнама, — диде.

Әмин бай әйтте:

— Бән уйнамастан тәкать тотар хәлем юк, — диде.

Шарт кәгазен язып, Әмин бай һәм падишаһ кул куеп, шатранҗ уйнарга тотындылар. Бер уенда Әмин байны калдырды. Падишаһ әйтте:

— И Әмин бай, ашыкма, башың китте, шакмакларны акрын тез, — диде.

Әмин бай көлеп, шакмак тезеп, янә уйнадылар ике мәртәбә, икесендә дә Әмин бай отты. Падишаһ әйтте:

— Шарт буенча сез оттыңыз, алай булса да, янә өч мәртәбә уйнаек, — диде.

Янә өч мәртәбә уйнадылар, һәнүз [һаман] Әмин бай отты. Падишаһ мөсәлләм [риза, канәгать] булдым, дип, вәзирләргә әйтте:

— Хәзер никах кылып, кияү кыз куенына керсен һәм, барабаннар кагып, шәһәр халкын уятыңыз, туй булсын — берсе никах туе, икенчесе яңа падишаһ — бәнем киявем, аңар бәйгать бирсеннәр*», — диде, үзенең башыннан таҗны салып Әмин байга китерде.

* Бәйгать бирү — берәүнең хакимиятен тану һәм аңа буйсыну өчен сүз бирү.

Никахтан соң, Әмин, падишаһ булып, кыз куенына кереп китте. Бу тарафта бөтен шәһәр халкы йокыларыннан торып, урамнарга утлар яндырып, шау уйнапкөлеп, ике туй булды дип, таңгача йөрделәр. Иртә булып, кояш күтәрелгәч, Әмин падишаһ вәзирләре берлән тәхетгяһенә [башкала, патша тора торган шәһәр] чыгып әйтте:

— Хәтаи тарафыннан [чит илдән] кәрван кайтып киләдер, Сәфир байның шул кәрваннан, бар малыннан зәкят алынсын!— диде.

Зәкятчеләр чыгып, кәрванны туктатып тәфтиш кылып [тикшереп], зәкят ала башладылар. Сәфир бай бик тиз ат берлән чабып өенә кайтты, хатыны берлән күреште:

— Нәхәл хатын, ни бар? — диде.

Хатыны:

— Әлхәмдулиллаһ, бездә бик зур шатлык: кызымыз кияүне ярата, киявемез кызымызны яратадыр, — диде.

Сәфир бай:

— Сез кем әмере берлән кызымызны бирдеңез? — диде.

Хатыны әйтте:

— Ни өчен ачуланасың, үзең хат яздың: хат биргән Әмин байга кызымызны мин кайтканчы никах кылып бир, дип, менәдер хатыңыз, — дип, байның хатыны хатны китереп бирде.

Бай хатны укыды, хәйран калды: үзенең язуы һәм үзенең мөһере. Шулвакыт вәзир килеп әйтә:

— Яңа падишаһ сине күрергә тели! — диде.

Китте бай падишаһ янына. Баргач, күрде: яңа падишаһ — үзенең колы һәм кияве Әмин бай. Бай күргәч гакылы башыннан чыгып биһуш [һушсыз] булды.

Падишаһ мөфтиләрдән сорады:

— Бер адәм ата-ана ризалыгы өчен кол булып сатылып, баена ничә миллионлык файда китерсә, ул бай шул колны үтерергә хат язып бирсә, ул байга ни җәза тиеш? — дип һәм байның хатын чыгарып бирде.

Мөфтиләр хатны укып әйттеләр:

— Байны кател [үтерергә] тиеш! — диделәр.

Бай, кияве Әмин бай падишаһтан:

— Падишаһлардан мәгъфирәт, гафу кылсагыз, — дип үтенде.

Әмин падишаһ гафу кылып, бай кызын дворецка алып һәм атасы берлән анасын алдырып, күп еллар гомер сөрде.

И УКУЧЫЛАР, ЯШЬ ЕГЕТЛӘР, ЯШЬ ВАКЫТЫҢЫЗНЫ БУШКА ҮТКӘРМӘҢЕЗ, НИЧЕК БУЛСА ДАҺӨНӘР ӨЙРӘНЕГЕЗ. ҺИЧ БУЛМАСА, ЛОМ БЕРЛӘН КОДОК КАЗЫҢЫЗ, СУЫ ЧЫКСЫН. ЭШ КОРАЛЫНДА ТҮГЕЛ, БУЛУЫНДА: КОДОКТАН СУ ЧЫКСА: «ЛОМ БЕРЛӘН КАЗЫГАН СУНЫ ЭЧМӘЙМЕЗ», — ДИМӘСЛӘР ҺӘМ: «НИ БЕРЛӘН КАЗЫДЫҢ?» — ДИП ТӘ СОРАМАСЛАР. СУЫ ЯХШЫ БУЛСЫН, ӘЙТЕРЛӘР: «СУЫ ЯХШЫ!» — ДИП.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

[1] Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр аз дигән сүз — раст сүз. Хикәят / Мөхәммәдҗан вә борадәре Шәрифҗан әл-Кәримиләрнең хәраҗаты илән. — Казан: Домбровский табгыханәсе, 1896.

КӨТЕБЕ СИТТӘ

Ризаэддин Фәхреддин

X

МӘҮДУГ (ЯЛГАН) ХӘДИСЛӘР. ХӘДИС УЙЛАП ЧЫГАРУЧЫЛАР. МӘҮДУГ ХӘДИСЛӘР ХАКЫНДА БАСЫЛГАН ХЕЗМӘТЛӘР

Хәдис галимнәренең көч сарыф итеп хәдисләрне җыюларының, сәнәдләр тикшереп һәрберсен үлчәү аша үткәрүләренең бөек сәбәпләренең берсе — арада мәүдуг (асылсыз) хәдисләрнең йөрүләре һәм дөрес хәдисләр белән аралашып, беркадәр кешеләрнең адашулары булды.

Мәүдуг хәдисләрнең төрләре күп булып, аларны таратучыларның максатлары төрле-төрле иде. Кайберләре ислам диненә шөбһә салу нияте белән, кайберләре үз мәзһәпләрен тарату өчен һәм кайберләре үзләренә күрә бертөрле яхшы ният белән хәдис уйлап чыгарганнар. Хәдис уйлап чыгарып, халык арасында тараткан динсезләр — әүвәлге төркемнән, бидгать әһелләре белән суфи һәм заһидләр — соңгы төркемнән. Динсезләр җөмләсеннән саналган габбасилардан [булган] Мәһди заманында үтерелгән Габделкәрим бине Әбү әл-Гауҗаның берүзе тарафыннан 4000 хәдис уйлап чыгарганлыгы риваять ителә.[1]

Сүрәләр фазыйләтләре хакында (кайбер сүрәләр хакында булган хәдисләр — *искәрмә*) тәфсир китапларында булган хәдисләр, гүя Коръәншәрифне укырга кызыктыру өчен Нух бине Әбү Мәрьям, Мәйсәрә бине Габдераббиһ кебек заһидләр тарафыннан уйлап чыгарылганнар.

Ибне Әбү Яхъя, Вакыйди, Мөкатил һәм Мөхәммәд бине Сәгыйд әл-Мәслуб исемле мәшһүр галимнәр хәдис уйлап чыгару белән билгеле булганлыктан, мөхәддисләр аларга «әл-кәззабун» (ялганчылар) диләр. Фәкать нинди максат белән уйлап чыгарылса да, чыгарылсын, мәүдуг хәдисләр үз әһелләре тарафыннан булган тәнкыйть белән башкалардан аерылганнар.

Соңгы заман авторларыннан берсе мәүдуг хәдисләргә карата шундый мәгълүмат бирә: Кәләби тәфсире[2] белән Мөкатил бине Сөләйман китабы, Вакыйди «Мәгази»се — асылсыз. Әбү Ләйс Сәмәркандиның «Тәнбиһ әл-гафилин» исемле китабында, Газәлинең «Ихья»сында, Хәким Тирмизи хезмәтләрендә, гомумән, тасаввыф (суфичылык) китапларында булган хәдисләргә (әгәр башка юл белән нык булмасалар) ышанып булмый. «Я, Гали!» һәм «Я, Фатыйма!» дип килгән васыятьләр, акыл хакында, Рәҗәб һәм Гашура көннәре фазыйләтләре, шул Гашура көнендә бер төркем пәйгамбәрләргә хөрмәт күрсәтү турында булган хәдисләр — мәүдуг. Котыб, Гавәс, Нөкабәә, Әүтәд, Мәһди хакында булган хәбәрләр ышанычсыз. Багдад, Басра, Куфә, Кыйзвин, Мәру, Насыйбин, Шам, Әнтәкыя, Гаскалан, Искәндәрия, Бохара һәм Мисыр фазыйләтләре турында булган хәдисләр — ялган. Кавын һәм кына (хна), ахак (гакыйк), йөзек кию, итне пычак белән кисүдән тыю хакында булган хәдисләр дөрес түгел. Хәзрәти

Дәвамы. Башы журналның 2014 елгы 9 нчы санында. Журналда китаптан кайбер өзекләр тәкъдим ителә.

Ризаэддин Фәхреддин портреты. Р.Миңнебаев рәсеме

Билалның Шамга барып, хәзрәти Рәсүлнең вафатыннан соң Мәдинәгә кайтуы һәм бу вакытта азан әйтүеннән бөтен Мәдинә халкының агылуы хәбәре, Җабирның бер баласы икенчесен үтереп, соңра, рәсүлуллаһ догасы белән терелүе кыйссасы, хәзрәти Гомәрнең үз улы Әбү Шәхмәгә җәза биреп сугуы, Ибраһим пәйгамбәр хатыны Сараны мәҗбүр итеп, Фиргавен аулак бүлмәгә алып керүе һәм Ибраһим пәйгамбәр суяр өчен дип улы Исмәгыйль муенына пычак куюы, Әюп пәйгамбәрне Иблис котырткач, авыруы һәм шул сәбәпле тәне кортлавы, Давыт пәйгамбәрнең Урия хатынына гашыйк булуы, хөрмәтле рәсүл аягына иярүе сәбәпле, Бәйтел-мәкъдис сахрасының һавада калуы, ярылган ай кисәкләренең рәсүлуллаһның изүеннән кереп, җиңеннән чыгуы, рәсүлуллаһ белән дөяләр, ишәк һәм бүреләр сөйләшүе хакында булган хәбәрләр дөрес түгел. Муса пәйгамбәрнең Йосыф пәйгамбәр табутын Мисырдан алып чыгуы, Гад кавеменең җәннәте, Каф тавының башы зөбәрҗәт булып, бөтен дөньяны яктыртуы, хөрмәтле рәсүл әфәндебездән башка пәйгамбәрләрнең каберләре мәгълүм булмавы турында булган хәдисләр — ышанычсыз.

Бу автор китабыннан сайлап алынган нәрсәләр шулар. Фәкать мәүдуг хәдисләр болар белән чикләнмәгән,

[1] Бу кемсә Мәгыйн бине Заидәнең анасының бертуганы булып, Басра әмире Мөхәммәд бине Сөләйман бине әл-Габбаси тарафыннан 160 нчы елда үтерелде. «Тәүхид Мөфаддал Ибне Гомәр» исемле китапның кереш сүзендә телгә алынган Ибне Әбү әл-Гауҗа — шул зат.

бәлки, гаять күп булып, аларны белдертү өчен хәдис гыйлеме белгечләре тарафыннан хәтта кайбер кагыйдәләр дә уйлап табылган. Монда гына бөтенесен бирү мөмкин булмаганлыктан, [бер җөмлә белән әйткәндә] хәдисләрнең, Коръән-шәриф яки диндә булган катгый мәсьәләләр яисә хискә һәм акылга таянган ышануга каршы булганнары [мәүдуг була].

Мәүдуг икәннәре мәгълүм булган хәдисләрне белә торып сөйләү һәм риваять итү хәрам, дигәннәр.[3] Шуңа күрә элекке заманнарда Казан шәһәрендә бик күп нөсхәләр белән күп мәртәбә басылган «Кырык хәдис», «Әл-лөбаб» исемендәге китапларның зур өлешләре мәүдуг хәдисләрдән гыйбарәт булуы өчен дәреслек итеп балаларга укытырга яраклы булмаса кирәк.

Мәүдуг хәдисләр хакында безгә мәгълүм булган басылган хезмәтләр шулар: 1) Әснә әл-мөталлиби фи әхадис мөхтәлифәт әл-мәратиб», Мөхәммәд әл-Хут хезмәте (1276). 2) «Әл-игътибару фи бәяни ән-насих вә әл-мәнсухый мин әл-әхбар». 3) «Таәвилү мөхтәлиф әл-хәдис», Ибне Көтәйбә əд-Диннури хезмәте (276). 4) «Тәхзир әл-мөслимин мин әл-әхадис әл-мәүдугат», Зафир Мөхәммәд Бәшир әл-Әзһари хезмәте. 5) «Тәзкират әл-мәүдугат», Әбү әл-Фазыл әл-Мәкъдиси хезмәте. 6) «Әт-тәгъкыйбат галә әл-мәүдугат», Сөютый хезмәте (911). 7) «Әл-фәваид әл-мәҗмугатү фи әл-әхадис әл-мәүдугат», Мөхәммәд бине Гали Шәүкяни хезмәте (1250). 8) «Әл-ләали әл-мәүдугатү фи әл-әхадис әл-мәүдугат», Сөютый хезмәте. 9) «Әл-мәүдугат әл-күбра», Гали әл-Кари хезмәте.

Бу китапларның беренчесе Бәйрутта, икенчесе Хәйдәрабад әд-дәкәндә, тугызынчысы Истанбулда, калганнары Мисырда басылган.

XII
ХӘДИС КИТАПЛАРЫ БЕЛӘН ГАМӘЛ КЫЛУ

Бөек дәрәҗәле Коръәннән соң шәригатебезнең асылы сөннәт булса, сөннәттә иң ышанычлы хезмәтләр бу «Көтебе ситтә» («Алты китап») булса, аларда булган хәдис-шәрифләрне һәркем: «Рәсүлуллаһ саллалаһү галәйһи вә сәлләм [шулай] әйткән», — дип сөйли белер. Ачык максаты булу һәм аңларга көче җитү шарты белән бу хезмәтләрдә булган хәдисләр белән гамәл дә кылыр. Имам Шафигый хәзрәтләре: «Башка бер адәм сүзенә туры килмәүгә сылтап, сөннәт белән мәгълүм булган нәрсәне калдырырга юл юк, бу хакта мөсеманнарның иҗмаглары (бердәм карашы) бар», — дигән.[4] Хәдис-шәрифләр һәркем, һәр заман, һәр җир өчен кирәк булып, кайбер заманнар һәм кайбер кавем, шәхесләр белән чикләнмәгән. Кинәт бер хәдис мәгънәсе Коръән-шәриф яки икенче бер хәдис, яки нинди булса да, башка бер куәтле дәлилгә каршы булса, бу вакытта гаделлек, өстенлек, җыю һәм аңлату кагыйдәләре кулланыла. Ләкин мондый рәвештә каршылыклы күренгән хәдисләр уйлаган кадәр күп түгел. Нәтиҗә: хәдисләр белән гәмәл кылудан шәригать исеме белән тыярга һичкемнең хакы юк.

Хәдисләрнең гамәлдән чыккан, эчтәлексез, чикле һәм махсус булу ихтималлары чыгарга, шулай ук кызыктыру өчен булган әмерләрне мәҗбүри дип аңларга яки моның киресен аңларга мөмкин. Ләкин бу нәрсәләрнең, ихтималы гына булганлыктан, зарары юк һәм гамәл кылудан тыймыйлар. Сәләф галимнәре ышанычлы юл белән сөйләнелгән хәдисләр белән гамәл кылыр өчен эшкә керештеләр, аның белән

[2] Ибне Хәзем хәзрәтләренең «Әл-фасыл» исемле хезмәтенә мөрәҗәгать ителә. — Т.2. — Б.93, 94, 96.
[3] Голум әл-хәдис лиибн әс-Салах. — Б.38.
[4] Игълам әл-мөвәккыйгыйн. — Т.1. — Б.7.

фәлән һәм фәләннәрнең гамәл кылу-кылмауларын аңлауларына кадәр туктап тормаганнар.

Хәдис белән гамәл кылуда, никадәр бөек шөһрәтле затлар булсалар, булсыннар, бер өммәттән булган затларның сүзләре исәпкә алынмас; киресе була икән, ул вакытта хәдисләргә, сөннәтләргә хаҗәт калмас, бәлки, хәдис һәм сөннәт белән шөгыльләнәчәк җирдә сүзләре исәпкә алыначак затларның сүзләрен, уйларын, фикерләрен тикшерү һәм шуларга яраклы гамәл кылу тиеш булыр иде. Хәлбуки, шәригать галимнәре тарафыннан бу мәгънәдә сөйләүләре риваять ителми.

Хәдисләрдә булган ихтималлар бермә-бер артыгы белән мөҗтәһидләр һәм фәкыйһләр сүзләрендә дә бар. Моннан башка, мөҗтәһидләрдән риваять ителгән сүзләрнең иснадлары «Көтебе ситтә» иснадлары дәрәҗәсендә ышанычлы түгеллеге инкяр ителмәс. Шуңа күрә дә кулында «Мөваттаә», «Сахих Бохари» һәм «Сахих Мөслим» яки башка бер «Сөнән» китабы булган кемсә шул китапта булган хәдисләр белән гәмәл кыла белер. Хәтта бу китаплардан дәрес алучылар да бу ният белән дәрес алырга тиеш. Чөнки гыйлемнең максаты — гамәл.

Коръән һәм хәдисләр белән гамәл кылу өчен мөҗтәһид булу шарт түгел, бәлки, гарәп телен, насих (гамәлдән чыгаручы хәдисләр) һәм мәнсухны (гамәлдән чыгарылган хәдисләрне) беркадәр белү җитә. Хөрмәтле рәсүл хәзрәтләре ислам динен һәм аның хөкемнәрен аңлата белүдә мөҗтәһидләрдән артык булуында шөбһә юк. Шуның өчен: «Мин рәсүлуллаһ сүзләрен мөҗтәһид авызыннан ишетмәгәнгә аңлый алмыйм», — дип әйтүче кемсә хөрмәтле рәсүл хакында начар уйлаучы булыр.

Гамәл кылу өчен никадәр хәдис булса, һәрберсен урап алып бетерү мәҗбүри түгел. Хәдисләрне тулысы белән урап алып бетерү мәшһүр мәзһәпләрнең башлыкларына да җиңел булмаганлыгы риваять ителә. Шуның өчен үз каршыңда ачык булганнан соң, ихтимал, моңа каршы икенче бер хәдис яки Коръән [аяте] бардыр, фәләнтөгәндер, дип тукталып тору тиешле булмый. Төрле заманнарга һәм төрле вакытларга йөкләргә мөмкин булган хәдисләрнең һәрберсе белән гамәл кылу дөрес була.

Ислам динендә беренче дәрәҗәдә ышанычлы дәлил бөек дәрәҗәле Коръән булып, аннан соң өммәт тарафыннан бердәмлек белән кабул ителгән «сөннәт гамәлия» (пәйгамбәр гамәлләре) һәм аннан соң риваять яки дәлилләрендә каршылыклар булган «сөннәт каулия» (пәйгамбәр сүзләре). Бу нәрсәләрнең аңлатмасы исә моннан башка җирләрдә.

Хәдисләрне аңларга ярдәм бирәчәк нәрсәләр: гарәп телен гүзәл белү, аның куллану үзенчәлекләре белән таныш булу, гарәп шигырьләрен һәм гарәп мәсәлләрен ятлау булыр. Хәзрәти Гомәр радыяллаһү ганһе (Аллаһ аннан риза булсын) Афакта булган хезмәткәрләренә ирештергән фәрманнарында фарызлар һәм сөннәтләр хакында булган нәсыйхәтләре белән бергә гарәпчәне өйрәнү хакында нәсыйхәтләре була иде.[5]

Хәдис гыйлеме һәм сөннәт белән гамәл кылган затлар өчен хөрмәтле сәхабәләр, табигыйннар арасында дин гыйлемен тарату белән шөгыльләнгән затларның тормыш юлларын белү, аларның заманнары, мохитлары белән дә таныш булырга кирәк. Бу турыда гүзәл һәм ышанычлы бер төркем хезмәтләр басылып нәшер ителгән. «Изгеләрне искә төшергәндә рәхмәт иңә».

Текстны басмага ***Айдар Гайнетдинов*** *әзерләде.* ■

[5] Мохтасар җамигый бәян әл-гыйлем. — Б.207.

БАТЫРЛЫКНЫҢ ЙӨЗЕ НИНДИ?

Ләйлә Минһаҗева,
филология фәннәре докторы, КФУ доценты

УЗГАН 2014 ЕЛДА КАЗАН ТӨРКИ ДӨНЬЯНЫҢ МӘДӘНИ БАШКАЛАСЫ ДИП ИГЪЛАН ИТЕЛГӘН ИДЕ. ӘЛЕГЕ ОЛУГ ВАКЫЙГА УҢАЕННАН, БЕЗ МАХСУС СӘХИФӘ ДӘ АЛЫП БАРДЫК. ШУНЫҢ МАНТЫЙКЫЙ ДӘВАМЫ БУЛАРАК, РӘХИМ ИТЕГЕЗ — «ТӨРКИ ДӨНЬЯ» СӘХИФӘСЕ.

Редакциядән





Татар милләтендә бик матур гыйбарә бар: «Дөньяда торсаң, торганыңның эзе калсын», — ди халык. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, тәрҗемәче Фатих Кутлуның да, Төркиянең әдәбият-сәнгате тарихында гына түгел, татар әдәбияты, тәрҗемә тарихында да ныклы, үзенчәлекле эзе калыр кебек. 2015 елны әлеге шәхес тагын зур бер тәрҗемә китабы — «Алтын тиен» («Алтын синҗап», Анкара: «Бәнгү» нәшр., 294 б.) дип исемләнгән, хәзерге татар язучыларының балалар өчен язылган хикәяләр һәм әкиятләре җыентыгы белән каршы алды.

Мәгълүм ки, татар матбугатында тәрҗемә белән бәйле юнәлештә Фатих Кутлу исеме А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» («Бир авуч топрак», 2008) повесте белән бәйле рәвештә беренче тапкыр телгә алынган иде. Шуннан соң бер-бер артлы Р.Батулланың «Алып батыр маҗаралары», 2013) җыентыгы, А.Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән...», 2013) повесте, «Тавышсыз курай» — хәзерге татар язучыларының әсәрләре тупланмасы, мәрхүм язучыларның балалар өчен язылган әсәрләреннән торган «Филдиши чакы» («Сөяк саплы пәке»,



Фатих Кутлу





2013) җыентыклары төрекчә дөнья күрде.

«Алтын тиен» җыентыгы — бүгенге көндә иҗат итүче татар язучылары иҗатыннан сайланган өч әкият, егерме биш хикәяне үз эченә алган. Кече һәм урта яшьтәге мәктәп балаларына адресланган. Китапта тупланган әсәрләрнең, нигездә, уңышлы сайлануын ассызыклап китү урынлы булыр. Алар арасында Г.Гыйльмановның «Батырлыкның йөзе нинди?», Ф.Яхинның «Ак әбиләр догасы», Л.Леронның «Гает бәйрәме», Р.Батулланың «Йолдызлар турында әкият», Л.Гыймадиеваның «Кайсы чын, кайсы — ялган...», Л.Хәмидуллинның «Әхмәт нигә елады?», Р.Зәйдулланың «Кеп-кечкенә бака», Ә.Гаффарның «Әни йөрәге», Г.Рәхимнең «Алмалар», Э.Шәрифуллинаның «Әнкә нарат белән әткә нарат һәм аларның балалары», Р.Галиуллинның «Биш икеле» кебек әсәрләре дә бар. Мәгълүм ки, бу әсәрләрдә татар милләте, аңа гына хас милли характер, яшәү рәвешен ачкан кыйммәтләр тупланган. Әлеге кыйммәтләр исә балаларны тәрбияле итү, кечкенә шәхесне тормыш юлын дөрес сайларга өйрәтү юнәлешенә буйсындырылган. Мондый әсәрләр,

бердән, төрки халыклар белән уртак якларны ачса, охшаш характерларны бирсә, икенчедән, башка милләтләр өчен дә чагыштырма планда бәяләү, нәтиҗәдә, әдипләребезне киңрәк даирәгә таныту мөмкинлекләрен бирә.

Гомумән, татар әдәбиятында бүген тәрҗемә эшчәнлеге турында сөйләшү — көнүзәк мәсьәләләрнең берсе. Чөнки тел, әдәбият тарихы, аның бүгенге торышы белән бәйле актуаль мәсьәләләр соңгы дистә елларда тарих, лингвистика, психология белән бәйле тикшеренүләрнең үзәгендә тора. Һәм ул, турыдан-туры бүгенге җәмгыятьтәге үзгәрешләр, икътисади-сәяси шартлар белән бәйләнә: чор таләп иткәнчә, татар җәмәгатьчелегенә дә бүген әдәбиятара, мәдәниятара бәйләнешләрне киңәйтү лазем.

Җыентыкта В.Нуриевның «Гөмбә оясында», М.Галиевнең «Җиңәсем килде», А.Гыймадиевның «Телефонлы кәҗә», Н.Гыйматдинованың «Урман ниләр сөйләр икән?» кебек хикәяләрнең дә урын алуы уңышлы. Чөнки соңгы еллар татар балалар әдәбиятында эшләүче прозаиклар сабыйлар тормышын әдәби сурәтләүдә һәм яшь буынның эмоциональ яшәешен ачуда бөтен мөмкинлекләрне дә кулланырга омтыла. Нәниләр тормышын тасвирлауда психологизм алгы планга чыкты. Бу — әдипләрнең осталыгы тагын да зуррак үсешкә иреште, дип санарга мөмкинлек бирә. Шуңа күрә Фатих Кутлуның мондый хикәяләргә мөрәҗәгать итүе аңлашыла да.

Җыентыкта урын алган тагын бер кечкенә генә әсәргә тукталып үтәсем килә. Ул — Марат Закирның «Кара төс ни өчен кирәк?» хикәясе. Әсәрдә Дәрдмәнд, Г.Тукай, А.Алиштан килгән традицияне күреп күңел сөенде. Классикларга хас, кыска күләмдә гаҗәеп тирән акыл, фикер бар бу хикәядә. «Әхәзер инде, улым, бөтенесен дә кара төскә буяп чык! — диде аңа әтисе. Айдар көмеш сулы елганы да, ап-ак корабны да, яшел-коңгырт танкларны да — һәммәсен-һәммәсен кара төскә буяп куйган иде дә... Менә сиңа тамаша — аның барча рәсемнәре юк булды. Аптырашта калган малай әтисенә карады. — Сугышның, улым, бер генә төсе бар, — диде әтисе. — Кара төс ул...» Һәр милләтнең олысы-кечесенә дә әйтелергә, күңеленә сеңдерелергә тиешле нинди гыйбрәтле сүзләр!

Мәгълүм ки, тәрҗемә шактый авыр хезмәт. Чөнки этик һәм эстетик таләпкә тел чаралары ярдәмендә ирешелә, әмма эчтәлек, мәгънә шул ук калырга тиеш. Нәтиҗәдә, тәрҗемәченең туган теленең бөтен нечкәлекләрен белүе белән бергә, сүз остасы, чит милләтләр яшәешеннән дә шактый хәбәрдар булуы мәҗбүри. Фатих Кутлуның исә тәрҗемәчелек таланты бүген һичкемдә дә шик уятмый. Сүз уңаеннан шуны да искәртеп китү урынлы булыр, Фатих Кутлу тарафыннан төрекчәгә аударылган «Сөяк саплы пәке» җыентыгы бүгенге көндә албан теленә дә тәрҗемә ителә, тиздән Албаниядә басылып та чыгачак, дип көтелә. Әлеге факт, безнең өчен зур шатлык китерү белән бергә, алда әйтелгән фикергә дәлил дә була ала.

Мәкаләбезне «Батырлыкның йөзе нинди?» дип Г.Гыйльманов әсәренең исеме белән атаган идек. Бу әсәр дә игътибарга лаек. Биредә төп герой Ильяс, гомерен куркыныч астына куеп, Әмирҗанны үлемнән коткара. Әнисе Әкълимә соңрак аның кылган гамәлен бәяләп, «тәртипле, игелекле, батыр йөрәкле», дип горурланып сөйли. Әлеге сүзләрне без бүген тәрҗемәче Фатих Кутлуның үзенә карата да кулланырга хаклыбыз. Тәрбияле, белемле әлеге шәхеснең шундый зур эшкә алынуы татар милләтенә игелекле булуы белән бергә, батыр йөрәкле булуын да ассызыклый. Һәм без, татар әдәбиятын, татар әдипләрен Төркиядә якыннан танытырга алынган Фатих Кутлуга алда да чын күңелдән уңышлар гына телибез. ■

КАРДӘШЛЕККӘ ЧИКЛӘР ЮК!

Төрки яшьләр Корылтае һәм көннәренә моннан 16 ел элек Татарстанда нигез салына. Хәзер исә чара күчмә характерда, ул ике елга бер мәртәбә алдан сайланган аерым бер илдә уздырыла. Чираттагы 16 нчы Корылтай һәм төрки яшьләр көннәре бу юлы 10-14 нче декабрь көннәрендә Төркиянең **Истанбул** шәһәрендә үтте.

Корылтайда 19 дәүләтнең 43 оешмасыннан 150 вәкил катнашты. Бу чарага Республикабызның **«Идел»** яшьләр үзәге дәүләт бюджет оешмасы да чакырулы иде.

Корылтайның төп максаты: аралашу өчен уңайлы мохит тудырып, төрки халыклар арасында дуслыкны ныгыту, борчыган проблемалар буенча фикер алышу, тарихка һәм гореф-гадәтләргә бай булган мәдәни мирас белән танышу, төрки дөньяга кагылышлы мәсьәләләрне хәл итү юлларын эзләү. Дүрт көн дәвамында Корылтайда төрле темаларга караган секция утырышлары узды.

«Төрки дөньяның яшьләре: заманча оешмалар һәм яшьләр платформалары челтәрен булдыру мөһимлеге» секциясендә «Идел» яшьләр үзәге директоры **Ләйсән Сафина** әлеге оешма мисалында Татарстандагы яшьләр сәясәте һәм алар белән эшләү үзенчәлекләре турында чыгыш ясап, тәҗрибәләре белән уртаклашты.

Моннан кала, «Төрки дөньяның, халкының икътисади үсеше һәм алар арасында сәүдә перспективалары», «Төрки халыкларның милли көрәше һәм региональ каршылыкларның тәэсир итүе» кебек секцияләр дә эшләде. Корылтайда, шулай ук, лидерлар, эшмәкәрләр һәм делегация журналистларының киңәшмәсе уздырылды.

Киңәшмәләр һәм конференцияләрдән кала, форумның программасын мәдәни чаралар бизәде. Шул чаралар кысаларында **Якын Көнчыгыш** һәм **Балкан**, **Кавказ** һәм **Төркестан**, **Урал** һәм **Алтай** регионнарының, шулай ук Туран кичәсе узды. Татарстан вәкилләре дә мәдәни чарадан читтә калмады. Милли киемнәр, катнашучыларның ялкынлы чыгышлары, бию, җырлары, бүләк алышулар, истәлеккә фотога төшүләр — болар барысы да бер дус гаилә, төрки дөнья гаиләсе мохите тудырды.

Дөньяның кайсы гына почмагында яшәсәк тә, бергә җыелып, әнә шулай киңәш-табыш итешеп, тәҗрибә уртаклашып, алгарышка омтылыйк! Кардәшлеккә чикләр юк, бердәм булыйк!

Ильмира Камаева.

КАРА ГЕНЕРАЛ

Рәис Зарипов

Партизаннарның көндәлек тормышлары совет киноларыннан караганда гына күңелле, кызыктыргыч: һәр җирдә учаклар яна, экзотик куышлар күренә, шат чырайлы, сакал баскан кораллы кешеләр йөренә. Әмма чынбарлык күпкә кырысрак, аяусызрак шул. Теләсә-кайсы вакытта карательләр һөҗүмен көтеп, бик авыр шартларда да җәен-кышын урманда яшәү бер дә җиңел гамәлләрдән түгел анысы. Мең төрле мәшәкать өстенә адым саен куркыныч, хәвеф, хыянәт сагалый. Бригадага кемнәр килеп кушылуын тикшереп тору мөмкинлеге дә чикле. Әле бит, күнегелгән, гадәти тормыш рәвешеннән аерылган йөзләрчә кеше күңелендә анархия орлыклары шыта башлау ихтималы да юк түгел. Шуңа күрә, усал да булырга туры килә Мурзинга. Телисеңме-теләмисеңме: **Византия императоры Юстинианның** моннан мең ярым ел элек әйтеп калдырган «Җитәкченең йомшак күңеллелеге — ул көчсезлек билгесе», дигәннәре белән санлашмыйча булмый һич тә.

Әле бит бригада составында төрле милләт вәкилләренең күп булуын да исәптән чыгарып бетерергә ярамый. Словакиягә ташлар алдыннан, Украина партизаннары штабы каршындагы махсус мәктәптә өченче мәртәбә күнегүләр үткән чагында мәсьәләнең бу ягына да зур игътибар бирелүен, фатирында гәпләшеп утырганда бер дә юкка гына кат-кат хәтерендә яңартмагандыр данлыклы диверсант. Мисал өчен, ул чакта венгрлар (мадъярлар) белән словаклар арасында гасырлар буе килүче каршылыкларны исәпкә алу кирәклегенә аерата нык басым ясый остазлары. Даян ага шул вакыйгаларны бәян иткәндә, венгр феодалларының, соңрак буржуазиясенең словак халкын изеп торуларын белгәнлеген, әмма ул халыклар күңелендә милли каршылык орлыкларының шулай озак вакытлар саклануына гаҗәпләнүен һәм андый хәлне үзе өчен ачыш буларак кабул итүен дә әйтеп үтте әле.

Партизаннарның әлеге махсус мәктәбе **Киев** янындагы **Святошино** дип аталган курорт биләмәләрендә урнашкан була. Теге чакта Мурзинның Молдавиягә ташлаган диверсантлар төркеменә, разведка башлыгы сыйфатында кертелгән **Павел Куделя** да аның белән. Румын генералының адъютанты булган һәм **Сталинград** янындагы кыйралышта совет ягына чыккан бу молдаван егете үткерлеге, ачык күңелле булуы белән башкалардан нык аерылып тора. Ә мәктәптә аның кебекләр бихисап. Дошман тылында диверсияләр оештыру серләренә

Дәвамы. Башы 2015 елның 1 нче санында.

Мурзин бригадасы Всетин каласына керә. Злин крае. 1945 ел

Злин, Всетин, Пршеров һәм Голешов калаларыннан Чехия башкаласына кадәр ара 200-250 чакрымнан еракрак. Ә инде сугыш тәмамлануга барган көннәрдә Даян Мурзин үз партизаннарын бер тирәгә туплый һәм дошманга каршы зур һөҗүмнәр оештыра башлый.

Советлар Союзы гражданнарыннан тыш, Кызыл Армиягә әсир төшкән полякларны, болгарларны, алманнарны, венгрларны, чехларны, словакларны һәм румыннарны да өйрәтәләр. Куделя тиз арада чехлар һәм словаклар белән дуслашып ала, аларга үз командирының батырлыклары турында сөйли. Аның әңгәмәләре эзсез үтми: дүрт көннән Мурзинны Украина КП(б) ҮКнең җаваплы хезмәткәре **Леонид Дрожжин** үз янына чакырта һәм словак белән чехларның аны үз төркемнәрендә күрергә теләүләрен ирештерә. Даян Мурзинга чехословак вәкилләрен СССРда ясалган кораллардан атарга һәм совет миналары белән эш итәргә өйрәтү бурычы куела. Төркемдәге башка милләт кешеләренә исә, үз чиратларында, «ипилек-тоз-

лык» кына булса да чех һәм словак телләренә өйрәнү мөмкинлеге туа. Моннан тыш, ул илнең географиясен, халыкларының гореф-гадәтләрен, эчке сәяси вазгыятьне, дини мөнәсәбәтләрне белү дә мәслихәт.

Төркемне Словакиягә ташлар алдыннан, булачак отрядка хәрби киңәшче вазифасында билгеләнгән Даян Мурзин генерал-лейтенант **Тимофей Строкач** белән очраша. Украина партизаннар хәрәкәте штабы башлыгы, **Ян Ушьякның** зур хәрби төркемнәр белән командалык итү тәҗрибәсе булмавын һәм шул сәбәпле нәкъ менә аңа, бөтен хәрби мәшәкатьләрне үз җилкәсендә күтәрергә туры киләчәгенә игътибарны юнәлтә. 22 десантчы арасында Мурзиннан гайре тагын бер татар — чыгышы белән **Чакмагыш** районыннан булган хәрби фельдшер **Миргалим Латыйпов** та була. Радистларының **Кучинский** фамилиясен йөртүе дә шактый кызыклы.

Очучы хата белән 8-10 чакрымга читкәрәк ташлап киткәнлектән, өч сәгатьтән артыграк күктән төрле җиргә төшкән капчыкларын эзләп мәш килгәч кенә, парашютчылар зур **Склабино** авылына килеп җитә. Алдан килешенгәнчә, Ян Ушьякның **«Ли-2» (Дуглас ДС-3)** самолёты китергән диверсантлар отрядын Склабино авылы чиркәве янында зур халык төркеме көтеп тора, Милли каршылык комитеты рәисе **Ян Мазур** да — алар арасында. Митингтан соң авылның 200 кешесе һәм Европа илләре армияләренең берничә дистә элекке хәрби әсире яңа оешкан отрядка языла. Яңа туган отрядка **Ян Жижка** исемен бирүгә каршылар табылмый. Бу хәлләргә аерата отряд командиры Ян Ушьяк бик нык сөенә. Ул Мурзинның янтыгына төрткәләп ала һәм көр тавыш белән:

— Словаклар бер булып бошларга (словаклар алманнарны шулай атый) каршы күтәреләчәк әле, дип әйткән идем бит мин сиңа, Юра! Әнә, Величко, төшү белән **Мартинны** алу өчен сугышлар башлап җибәрде. Ә ул зур кала! Зурлыгы буенча Словакиянең бишенче каласы, — ди.

Аңлашылмаучанлыклар килеп чыкмасын өчен, Словакиягә алардан алдарак ташланган майор **Пётр Величко** отрядының да Ян Жижка исемен йөртүен искәртү мөһимдер. Капитан Мурзин баштагы мәлләрне күршеләренә бик нык ярдәм итә, Мартин каласыннан дошманны кысрыклап чыгарганда да гел алгы сафта сугыша. Капитанның тәвәккәллеген Величко да бик тиз чамалап ала: Мурзинны үз отрядына күчәргә кодалый башлый. Моңа, билгеле, үз отрядындагы офицерларының бик еш сафтан чыгып торуы да сәбәп биргәндер. Әмма кем Ян Ушьяк отрядын, бер үк вакытта комиссар һәм командир урынбасары вазифаларын да башкарган хәрби киңәшчедән мәхрүм итәргә рөхсәт бирсен? Бу бит хәрби тәҗрибәсе җитеп бетмәгән командирны ике кулсыз калдыруга тиң гамәл булыр иде. Үз кул астындагыларны гел җәһәннәм уртасына ташлап, куркыныч янамаган урыннардан гына боерыклар биреп утырырга күнекмәгән Даян Мурзин үзе дә моны теләми. Ә менә яхшы күршеләр булып калу, дошманга каршы бергәләп, үзара килешеп хәрәкәт итү иң кулай юл дип табыла. Тик вазгыять үзгәреп киткәнлектән, ике отрядка иңгә-иң торып көрәшү насыйп булмый: Украина партизаннар хәрәкәте штабы, Словакиядәге баш күтәрүчеләргә каршы сугышучы дошман гаскәрләре көчләренең бер өлешен читкә юнәлтү ихтыяҗыннан чыгып, Ян Ушьяк отрядын **Моравиягә** кертергә карар итә.

Партизаннар штабы башлыгы генерал Тимофей Строкач боерыгы белән, 1944 елның ноябреннән (хәрби билетында октябрь ае күрсәтелә) бригада командиры итеп расланган Даян Мурзинның бөтен командирлык осталыгы тулысынча шул чорда ачыла да инде. Ул Моравия белән Чехиядә зур партизаннар бригадасы туплауга ирешә һәм дошманга китергән зыяны белән

Германиянең пропаганда министры Йозеф Геббельс янында. Сулдан уңга: генерал-лейтенантлар Андрей Власов белән Георгий Жиленков һәм обер-фюрер Эрхард Крёгер. Берлин, 1944 ел

Адольф Гитлерның шәхси дошманына әйләнә, ә аның «башы» 2 миллион алман маркасы белән бәяләнә. Болар үзе генә дә Мурзин шәхесенең бөеклегенә лаеклы бәя буларак яңгырый. Егерме дүрте дә тулмаган көе, үзеннән шактый өлкән яшьтәгеләр белән командалык итүнең шактый четерекле булуын исәпкә алып һәм олпатрак күренер өчен кара сакал үстереп җибәрүе дә ярап куя. Аннан соң яшьлеге әллә ни күзгә ташланмый инде, ә менә тәвәккәллеге, кискен хәлләр килеп чыкканда кырыс, усал була белүе һәм хәлиткеч мизгелләрдә төпле карар кабул итә алуы, өч мәртәбә махсус партизаннар мәктәбендә күнегүләр үткәндә туплаган тәҗрибәсе ул «кимчелеге»н бөтенләй күмеп китә, юкка чыгара. Шуңа да, олы бер бригада белән майор чинындагы кешенең командалык итүенә гитлерчылар ышанмый, диверсант Отто Скорцениның җиңел кулы белән «генерал булырга тиеш» дигән фараз өстен чыга. Моннан соң Даян

Ул Моравия белән Чехиядә зур партизаннар бригадасы туплауга ирешә һәм дошманга китергән зыяны белән Адольф Гитлерның шәхси дошманына әйләнә, ә аның «башы» 2 миллион алман маркасы белән бәяләнә.

Мурзин дошманнар өчен Кара генералга әйләнә. Хәер, аның биографиясенең кайбер этапларын алман контрразведкасы ачыкламый калмагандыр, мөгаен. Чөнки бөтен Чехия территориясендә аңа ау оештырыла, аның фотографиясе күп гестапо агентларының кесәләрендә йөри. Гестапо агентлары белән генә дә чикләнми әле «андый танышлык».

Фриштак каласындагы полиция участогын тар-мар иткәннән соң, үз штабына кайтышлый, Мурзин көрәштәшләре белән урманчы **Свачина** йортында ялга туктый. Биредә аны көтеп торган җирле гимназия укытучысы **Плойгер**, **Голешов** каласында ае-

Даян Мурзин

руча мөһим объектларны саклаучы батальон штабы урнашкан булуын хәбәр итә. Укытучы сөйләгәннәрдән, әлеге батальон командиры майор **Йозеф Хюбнерның** коммунистлар хәрәкәтенә теләктәшлек белдерүе, ә шәхси шофёры **Ганс Кохның** алман коммунисты, антифашист булуы ачыклана. Комбригны нәкъ менә шушылар кызыксындыра да инде һәм ул Свачинага Хюбнер белән очрашуны оештыру бурычы куя. Аңарчы үзе дә майор турында шактый мәгълүмат туплап өлгерә:

«Чиста ариец, 1932 елдан — нацистлар партиясендә. Туган теленнән тыш, француз, поляк, чех телләрендә иркен аралаша. Хатыны поляк коммунисты кызы булгангамы, хәрби карьерасы мактанырлык түгел: 1922 елда — капитан, тагын 17 елдан майор званиесенә үрләтелә».

Мурзин кунакларны **Лугочавицы** авылында каршылый. Хюбнер **«Опель»** машинасыннан төшеп Мурзин янына килә, честь бирә һәм чех телендә:

— Мин сезне шунда ук таныдым, пан майор. Сезнең фотографиягез минем урынбасарым, **СС капитаны Бузның** эш өстәлендә ята, — ди.

Өйгә кергәч, майор планшетыннан картасын чыгара һәм сөйләшүне шуннан башларга тәкъдим итә. Чехия һәм Моравия территориясендәге барлык алман гаскәрләре урнашкан урыннар теркәлгән картаны җәеп салуга ук, Мурзин аның әһәмиятен бик тиз абайлап ала, сөйләшүне беразга бүлеп, гаять кыйммәтле мәгълүматларны фронт штабына җибәрергә куша. Йозеф Хюбнер исә соңыннан да Мурзин бригадасын ярдәменнән ташламый: партизаннарга каршы оештырылучы операцияләр турында алдан җиткереп кенә калмый, корал һәм сугыш кирәк-яраклары, медикаментлар белән дә тәэмин итеп тора. Мәгәр Мурзинның партизаннар ягына чыгу тәкъдимен кире кага. Ә менә аның шофёры Ганс Кохны Рубиконны кичү куркытмый, ул партизаннар арасында тәмам үз кешегә әйләнә.

Даян Мурзин алман дустын соңгы тапкыр, сугыш тәмамланып, 22 ел узгач күрә. Австриянең **Заксенхаузен** каласыннан ерак түгел, **Альп** таулары итәгендә туристлар өчен кечкенә ресторан тотучы Ганс Кох бервакыт Көнбатыш Алмания радиосыннан: *«Бүген иртә белән Мәскәүдән Чехословакиягә чех партизаннары командиры, алман халкының палачы Юрий Мурзин килде»*, — дигән хәбәр ишетә. Сугышчан дустын күрәсе килү теләге көчле булгандыр, күрәсең, тиз арада виза алуга ирешә, бернинди куркытуларга һәм янауларга карамыйча,

Мурзин белән очрашуга ашыга. ЧССР-ның **Гощалково** авылында, көрәштәш дусты белән саубуллашканда: «Башкача күрешә алмаячагыбызны сизенәм», — дигән сүзләре, кызганыч ки, хак чыга…

Бер ай узуга, Кох утырган кечкенә йөк автомобилен зур үзбушаткыч машина сыта…

«Алман халкының палачы» дигән радиохәбәргә килгәндә исә, Мурзин андый гаепләүләрне кире кага. Менә аның үзе тарафыннан ташка басып калдырган сүзләре:

«Мин ачыклык кертергә телим. Беркайчан да кайсыдыр халыкның, шул исәптән, алманнарның да палачы булмадым. Мин, солдат буларак, фашизмга һәм фашистларга каршы көрәштем. Әле дә ул көрәшемне дәвам итәргә әзермен».

***

Күп язма чыганаклар белән танышып анализ ясаганнан соң, хәрбиләрнең Власовны Мурзин партизаннарыннан алып китүләре хакыйкатькә якынрак торуына ышаныч арта. Дөрес, Прага тирәсендә хәрәкәт иткән **Ольга Франтишкова** җитәкчелегендәге отрядны исәпкә алмаганда, Ян Жижка исемендәге партизаннар бригадасы, нигездә, Моравия территориясенең көнчыгыш өлешендә сугыша. Мисал өчен, **Злин**, **Всетин**, **Пршеров** һәм **Голешов** калаларыннан Чехия башкаласына кадәр ара 200-250 чакрымнан ераграк. Ә инде сугыш тәмамлануга барган көннәрдә Даян Мурзин үз партизаннарын бер тирәгә туплый һәм дошманга каршы зур һөҗүмнәр оештыра башлый. Бу җәһәттән комбригның үз истәлекләреннән өзек китерик:

«Әйе, апрель аенда без башкача хәрәкәт итә башладык. Инде бригаданы бер йодрык итеп туплау һәм мөмкин булганча һәркайда дошман оборонасын «дөмбәсләү» ихтыяҗы туды.

Менә инде, **Пётр Москаленко** һәм **Будько** отрядлары безнең тарафка, **Фриштак** каласына таба кузгалды».

Әлеге ике отряд партизаннары юл уңаеннан Визовицы каласын азат итәләр. Бригаданың төп көчләре дә кул кушырып утырмый: Мурзин командалыгында партизаннар Голешов каласын ала. Даян ага үзе, адъютанты Михаил Журавлёв белән кала урамнарына атка атланып килеп кергәнгәме, Прагадан Берлинга: *«Зур банда көтмәгәндә Голешовка бәреп керде. Болар, мөгаен, фронт линиясен өзгән рус кавалеристларыдыр,* — дигән радиохәбәр китә.

Җиңү сәгате якынлашу мизгелләреннән илһамланган Даян Мурзин Фриштак каласын басып алырга һәм Прагага чигенүче алман гаскәрләренең юлын кисәргә карар кыла. Операциянең шактый ук катлаулы булачагын истә тотып, Злин каласы янында аның разведчиклары генерал **Людвиг Свобода** корпусы разведчиклары белән очраша. Очрашу барышында, калага бергәләп һөҗүм итәргә килешенә. Артиллерия әзерлегеннән башка гына, искәрмәстән оештырылган һөҗүмгә алман гаскәрләре әзер булмый һәм алар, әллә ни каршылык күрсәтеп тормыйча, Злинга чигенә. Кала халкы исә Мурзин партизаннары белән Свобода корпусы сугышчыларын чәчәкләр белән каршылый. Фриштактан корпус — Прагага, ә партизаннар бригадасы Злинга таба кузгала. Биредә аларга моңарчы Югославиядә партизаннар белән көрәш алып барган СС гаскәрләренең тау частьлары каршы тора. Мурзин партизаннары кала тирәсенә 2 нче Украина фронтының 40 нчы армиясе составындагы Советлар Союзы Герое генерал-майор **Терентий Уманский** командалык иткән 240 нчы укчы дивизия сугышчылары белән бервакытта килеп җитә һәм уртак көч белән май башына Злин дошманнан азат ителә. Әнә шулай итеп, бер елга якын дошман тылында көрәшкән Ян Жижка исемендәге партизаннар бригадасы совет гаскәрләренә килеп кушыла.

Совет гаскәрләре белән кушылганнан соң, Мурзин үз көрәштәшләрен көнбатышка — Прагага алып китә. Бу легендар разведчикның **«Ватандаш»** журналында чыккан рәхмәт хатында да өлешчә раслана:

«Мин үзем Чехословакия Республикасының — Алтын Тәресе, соңрак Чехословакия Совет Социалистик Республикасының Алтын Йолдызы белән бүләкләндем, Чехословакиянең Милли Герое булдым. Күп чехословак калаларында мине — майор Мурзинны — үзләренең мактаулы гражданы дип игълан иттеләр. Злин, Брно, Годонин, Пршеров, Ческе Будеёвице (Ческе-Будеёвице. — Р.З.), Острава (элекке Моравска-Острава. — Р.З.), Пльзень, Градеце Карлове (Градец-Кралове. — Р.З.), Пардубице һ.б. калалардагы урамнар һәм мәйданнар әлегә кадәр минем исемне йөртә».

Димәк, исеме әнә шулай мәңгеләштерелгән икән, әлеге калаларны азат итүгә яисә шул төбәкләр белән бәйле тарихи яктан әһәмиятле хәрби вакыйгаларга Даян Мурзинның һәм аның партизаннарының турыдан-туры катнашы бар. Картадан караганда, бу калаларның көнчыгыштан көнбатышка — Злиннан алып Прагага таба урнашкан булулары ярылып ята. Илнең башкаласына иң якыннары — **Ческе-Будеёвице**, **Пардувице**, **Градец-Кралове** һәм **Пльзень**. Соңгысы Прагадан көньяк- көнбатышта урнашкан һәм күпчелек авторлар Власовны кулга төшергән урын буларак нәкъ менә Пльзень каласы тирәсен күрсәтә. Димәк, тарихи гаделлек ягыннан чыгып караганда, америка гаскәрләре азат иткән әлеге калада Даян Мурзинның исемен мәңгеләштерү шикелле мөһим фактны берничек тә игътибарсыз калдырырга ярамый. Пльзень каласының Власовны кулга төшерү белән бәйле төбәк буларак еш телгә алынуы исә җитди нәтиҗәләр чыгару өчен саллы этәргеч бирә. Шуларның иң мөһиме: әлеге калада партизаннар бригадасы командиры Даян Мурзинга карата күрсәтелгән хөрмәтнең нәкъ менә 130 меңнән артыграк коллаборационистны берләштерүче КОНР Короллы көчләре командующие генерал-лейтенант Власовны кулга төшерү вакыйгасына турыдан-туры бәйле булуы ихтимал.

Ахырдан, Даян Мурзин шәхесе белән бәйле кайбер кызыклы һәм гыйбрәтле хәл-вакыйгаларны бәян итү һич тә артык тоелмас. Әүвәл аның Уфада нәшер ителгән энциклопедиядәге кыскача биографиясен бәян итик:

«Мурзин Даян Баянович 1921 елның 20 декабрендә Уфа губернасының Бәләбәй өязе Бакалы волостена керүче Иске Балыклы авылында (хәзер — БРның Бакалы районы) туа. Бөек Ватан сугышында һәм Каршылык хәрәкәтендә катнаша. РСФСРның атказанган юристы (1972). Рига хәрби училищесын (1941), Мәскәүдә Бөтенсоюз читтән торып юристлар әзерләү институтын (1955) тәмамлый. Бөек Ватан сугышы башланган беренче көннәрдә Балтыйк буе хәрби округы составында дошманга каршы көрәшә. 1942 елның гыйнварыннан Украинада, Белоруссиядә, Молдавиядә партизаннар отрядлары оештыручы һәм аларның җитәкчеләренең берсе. Чехословакиядәге Ян Жижка исемендәге партизаннар бригадасының штаб башлыгы (авг. — окт. 1944), командиры (1944 елның октябре — 1945 елның мае). 1948-1969 елларда БАССРның прокуратура органнарында (1962 елда — республика эчке эшләр министры урынбасары) эшли. 1969-1985 елларда — Баш. адвокатлар коллегиясе рәисе. Кызыл Байрак (1942), Кызыл Йолдыз (1943), I дәрәҗә Ватан сугышы (1955) орденнары һәм 13 медаль, шул исәптән I нче дәрәҗә «Бөек Ватан сугышы партизаны» (1945) медале белән бүләкләнә. Ул шулай ук Чехословакиянең I нче дәрәҗә «Хәрби тәре» (1945), ЧССР азатлыгы өчен Алтын Йолдыз (1968),

Күпмилләтле партизаннар бригадасы. 1944 ел

Кызыл Байрак (1969), Кызыл Йолдыз (1954), I нче һәм II нче дәрәҗә сугыш Партизаны (1944) орденнарына һәм 13 медаленә лаек була. Злин (Моравия) кала советы Мурзинга көмеш кылыч һәм исемле ату коралы тапшыра (1945). Ул — Моравия белән Чехиядәге 15 каланың мактаулы гражданы, Злинда майор Мурзин исемен йөртүче урам бар».

Шушы кыска гына өземтәгә байтак мәгълүмат сыйган. Шуларның кайберләренә игътибарны юнәлтик. Беренчесе. Баш редактордан гайре тагын 24 галимне берләштергән редакция коллегиясе тарафыннан нәшер ителгән хезмәттәге бары тик бер шәхескә багышланган белешмәдә кайбер мөһим фактларның «онытылуы» күңелсез хәл һәм аны күрмәмешкә салышу мөмкин түгел. Авторы «Г.Т.Хөсәенова» дип бирелгән белешмәдә Мурзинның Мәскәүдә юридик институт тәмамлавы күрсәтелә. Ә аннан алда ике ел Казанда юридик мәктәптә укуы турында сүз юк. Даян Мурзинның дусты һәм хезмәттәше, юрист, язучы, Бөек Ватан сугышы ветераны **Мәгъсүм Насыйбуллин** үзенең Казанда нәшер ителгән **«Без капчыкта ятмый»** дигән китабындагы **«Көмеш кылыч»** язмасында ул турыда анык мәгълүмат бирә:

Пльзень каласының Власовны кулга төшерү белән бәйле төбәк буларак еш телгә алынуы исә җитди нәтиҗәләр чыгару өчен саллы этәргеч бирә.

«Җырларда җырланган ямьле Ык (Сөн — Р.З.) елгасы буенда Балыклы (Иске Балыклы — Р.З.) дигән татар авылы урнашкан. Шул авылда 1921 елда ярлы крестьян гаиләсендә туган, Казанда юридик мәктәп һәм институт бетергән зур тәҗрибәле юрист Даян Мурзин — нәкъ менә <...> гаҗәп язмышлы кешеләрнең берсе».

Икенчесе. Даян Мурзинның туган көнен төрлечә күрсәтүгә аерым тукталу мөһим. Нигездә барлык чыганакларда да ул көн дип 1921 елның 20 гыйнва-

ры атала. Тик бу алай түгел. Дөресе — энциклопедиядә күрсәтелгәнчә. Моның хикмәте Мурзинның дөньяга карашына, хыял-омтылышларына да бәйле... 1939 елның салкын декабре. СССРның **Финляндиягә** басып керүе аркасында хәрби конфликт башланган мәл. **Кушнаренко** татар педагогия училищесын тәмамлап, **Бакалы** районындагы **Тактагол** авылының тулы булмаган урта мәктәбендә эшләп йөргән егет үз теләге белән сугышка китәргә карар кыла. Әти-әниләренә әйтеп тормыйча гына, армиядән кайткан иптәше белән ат җигеп юлга чыгалар һәм Чакмагышта кич кунып, комиссия үтәсе Кушнаренкога барып җитәләр. Монда инде Мурзинның 18 яше тулмавы ачыклана. Әмма 40 градус салкында Бакалы, Чакмагыш, Кушнаренко районнары буйлап шулкадәр ара үтеп килгән һәм патриотик хисе ташып торган егетнең фидакярьлегенә таң калган комиссия рәисе, Башкортстанның Сәламәтлек халык комиссары мондый «вак-төяк»кә күз йома һәм аның яшен төгәл 11 айга өлкәнәйтеп күрсәтәләр. Хәрби әзерлек үткәч, март башларында Мурзин фронтка эләгә, әмма беренче хәрби чыныгу алуга, СССР белән Финляндия арасында килешү төзелә һәм ул **Рига** хәрби училищесына укырга керә. 1941 елның маенда хәрби һөнәр алып чыккан яшь офицер Балтыйк буе хәрби округына керүче 10 нчы укчы дивизиядә взвод командиры вазифасында хезмәт итә башлый. Сугышның беренче көненнән — алгы сызыкта. Чик буенда дошманның тәүге һөҗүменә дучар булган дивизия сугышчылары белән бергә, Даян Мурзин да Ригага кадәр чигенә. Латвия башкаласы янындагы кул сугышында яралана һәм дошман тылында бүленеп кала. Зур авырлыклар белән Латвия һәм Белоруссия территорияләре аша дистәләрчә-йөзләрчә чакрым юл үтеп, Украинадагы, әле ул чакта **Ковпак** берләшмәсе составына кермәгән, «Ватан өчен!» исеме астында хәрәкәт итүче партизаннар отрядына килеп кушыла, разведка взводы һәм разведка ротасы белән командалык итә.

Ә менә энциклопедиядә аның Белоруссия партизаннары хәрәкәтендә катнашуы турында дөрес күрсәтелмәгән. Алай раслау хакыйкатькә туры килми. Мурзинга Чехия белән Моравиядәге 15 каланың мактаулы гражданы исеме бирелгән дип күрсәтү, шулай ук кайбер сораулар туага сәбәп бирә. Бәлки ул исемлеккә Словакиядәге торак пунктлар да керә торгандыр. Әйтүе кыен. Чөнки данлыклы партизанны якыннан белгән Мәгъсүм Насыйбуллин башка төрле сан китерә. Ягъни аныңча, **«Чехословакиянең сигез шәһәре совет халкының батыр улын үзенең мактаулы гражданы дип игълан итте».**

Без Генрих Гофман китабында да шуны ук күрәбез:

«Ул хәзер сигез чехословак каласының мактаулы гражданы».

Әлбәттә, монда кайсыдыр якны хата җибәрүдә гаепләү дөрес булмас иде. Ни дисәң дә, Насыйбуллин белән Гофман китаплары кайчан чыккан да, энциклопедия кайчан дөнья күргән? Чирек гасыр эчендә ни генә үзгәрмәс! Шуны ук, Злин каласының бер урамына Мурзин исемен бирүгә карата да әйтергә мөмкин. Энциклопедиядә акка кара белән: **«Злинда майор Мурзин исемен йөртүче урам бар»**, — дип язылган. Язучы Насыйбуллин хезмәтендә дә шул ук фикер яңгыраш ала. Ә инде Гофман белән Мурзин хезмәтләрендә сүз кала мәйданы турында бара.

Хатамы болар? Юктыр! Мөгаен, төгәлсезлектер. Хәер, инде **Готвальдов** кабат Злин итеп үзгәртелде, калада Мурзин исемен йөртүче урам да юк хәзер. Еллар узган саен идеология үзгәрә, күпләр инанган рухи байлыклар башка төсмер ала. Шуңа да, Даян Мурзин исемен Злин урамы йөрткәнме, әллә инде каланың төп мәйданы шулай аталганмы — мөһим

түгел. *Иң мөһиме — тарихи хакыйкать, ягъни Моравиядә һәм Богемиядә иң зур партизаннар бригадасы белән командалык иткән майор Мурзинга карата мөнәсәбәт.* Энциклопедиядән күренгәнчә, милләттәшебез Чехословакиянең 6 орденына лаек булган. Әмма 1939 елда Икенче Бөтендөнья сугышында катнашучы хәрбиләрне бүләкләү өчен булдырылган Хәрби тәре орденнар категориясенә кертелмәгән. Ул хәрби билге буларак аталып йөри. Тәгаен, шуннан чыгып караганда, Насыйбуллинның, Чехословакия хөкүмәте Даян Мурзинны 5 орден белән бүләкләгән, дип раславы дөреслеккә якынрактыр. Тагын бер мизгелгә ачыклык кертик. Күп хезмәтләрдә Мурзинның «ЧССР азатлыгы өчен Алтын Йолдыз» ордены белән бүләкләнүе күрсәтелә. Монда бераз төгәлсезлек күзгә ташлана. Чынлыкта ул — «Азатлык өчен» дип аталучы чехословак хәрби ордены. Орден ил хөкүмәте карары белән 1946 елның 2 апрелендә гамәлгә куела һәм ул 3 дәрәҗәдә йөри. Даян Баян улында аның I нче дәрәҗәдә йөргәне — «Азатлык өчен» чехословак орденының («Чехословакия яисә ЧССР азатлыгы өчен» түгел) Алтын Йолдызы. Тагын бер кечкенә төгәлсезлек: Чехословакия хөкүмәте карары белән 1955 елда Кызыл Йолдыз һәм Кызыл Байрак орденнары булдырыла. Тик, ни сәбәпледер, Мурзинның чехословак Кызыл Йолдыз ордены белән 1954 елда бүләкләнүе күрсәтелә.

Мәгәр максат Мурзин бүләкләнгән чехословак орденнары белән бәйле кайбер төгәлсезлекләрне ачыклау түгел. Максат — сәер бер вазгыяткә игътибарны юнәлтү. Никадәр генә гаҗәп тоелмасын, совет ягы тарафыннан тапшырылган орденнарны күздән кичерүгә үк, СССР хөкүмәте данлыклы диверсантның батырлыкларын тиешенчә бәяләмәгән, дигән тәэсир кала. Әйтик, Даян Мурзинга 1942 елда Кызыл Байрак, ә 1943 елда Кызыл Йолдыз орденнары тапшыралар. Гаҗәп тә түгел. Аның Украинада партизаннар отрядында кылган батырлыклары һәм Төркестан легионын таркатуга керткән өлеше әнә шулай югары бәяләнә. Шуның белән вәссәлам. Молдавиядә, Словакиядә, Богемиядә һәм Моравиядә дошман тылында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булырлык диверсияләр оештырган, генерал **Дитрих фон Мюллерны** эләктергән, «Олы җир»гә кыйммәтле мәгълүматлар җиткереп торган, шул территорияләрдә азатлык көрәшен җәелдерүгә саллы өлеш керткән комбриг Даян Баян улы Мурзин фәкать **Сталин** үлеме һәм **Берияне** атарга хөкем итү карары җиренә җиткерелү шаукымы басыла төшкәч кенә, I нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены (1955) белән бүләкләнә. Мондый аңлашылмый торган үтә сәер, тискәре мөнәсәбәтнең, мөгаен, үз сере, үз хикмәте бардыр. Бәлки әле бу генерал Власовны эләктерүгә турыдантуры бәйледер. Чөнки Даян Мурзин тарафыннан 1944-1945 елларда кылынган батырлыклар олы хөкүмәт бүләкләренә лаек булырлык. Бу яктан бернинди дә шик-шөбһә юк. Ә менә ни өчен алай эшләнмәвен аңлатуы һәм ачыклавы бик читен.

Андый чакта күптомлы **«Татар энциклопедиясе»**нә мөрәҗәгать итү байтак нәрсәләрне төшенергә ярдәм итәр иде, бәлки. Әмма бу бөтенләй урынсыз гамәл. Чөнки татар шәхесләре һәм милләт белән бәйле мөһим вакыйгалар җентекләп яктыртылырга тиешле ул хезмәттә бөтен дөньяга мәгълүм шәхес — Даян Баян улы Мурзин турында белешмә бөтенләй юк.

Ахыры бар ■

ӘТКӘМ СУРӘТЕ

Фоат Галимуллин

Мин әниемнең сеңлесе Гайшә апам (1915 елгы) белән сөйләшеп утырам. Аңардан әтием турында сорашам. Мин әти турында кайбер нәрсәләрне беләм дә кебек. 1911 елда туган. 1941 елның 14 августында сугышка алынган. 14 нче аерым армия составына җибәрелгән... Әйе, болары билгеле. Әмма кеше буларак, ир, ата буларак, башкаларга мөнәсәбәттә ниндиерәк булган соң ул? Боларны мин, әлбәттә, белеп бетермим. Белсәм дә, кемнәрнеңдер сөйләве, искә алуы аркасында гына.

Гайшә апам әкрен генә сөйләп китә:

— Әтиең миңа җизни була инде. Бик хәрәкәтчән, шат күңелле кеше иде, мәрхүм. Кирәк икән, җир җимертеп эшли, уен-көлкедә дә кимен куймый. Ярдәмчел. Бервакытта да тик тормас, нәрсәдер эшләр, бер дә булмаса гармун уйнар. Безне — әниеңнең сеңелләрен дә үз итте. Берәр җиргә барса, Гайшәгә, Нәсимәгә, Зәйтүнәгә дип аерым-аерым бүләкләр алып кайтыр иде. Түбән очтагы әти-әнисенә, туганнарына да җылы карашлы булды. Әй-й, нинди кешеләрне харап итте бу сугыш!

Җизни сәвитне бер дә яратмады. Сәвитне чыгаручылар ярлы-ябагайны яклыйбыз, дип шапырындылар. Әтиең берниндн яклауны да кирәксенмәде. Ник дисәң, ул үз тормышын үзе алып барырлык егет булды. Һөнәре дә бик әйбәт иде — тимерче. Әтисе Сәмигулла кода аны, Югары Өшенбаш дигән ар (удмурт) авылына җибәреп, атаклы тимерче Әләкчәйгә (Алексейга) һөнәрче итеп бирде. Берничә елдан егет аннан менә дигән тимерче булып кайтты. Атасы белән бергә су буенда алачык корып җибәрделәр. Элгәре заманнарда татарлардан тимерче булмаган. Патша безнең кавемнең корал ясавыннан курыккан. Галимулла җизни — авылыбызның беренче тимерчесе. Әүвәле ат дагалатырга, сукатырма төзәттерергә, комган-табак кебек нәрсәләрне яматырга кирәксә, әнә шул биш чакрымдагы Югары Өшенбашка йөргәннәр. Галимулла җизни тимерче булгач, халык рәхәткә тиенде. Якынтирә авыллардан да аңа килергә гадәтләнделәр. Шулай итеп, ул тирәякта бик кирәкле затка әйләнде.

Әтиеңнең тагын шуңа ачуы килде: колхозлашу башлангач, аңа алачыгын ябарга, колхоз тимерчелеген оештырып эшләргә куштылар. Ул көн буе бушлай чүкеч сугарга тиеш булды. Ачуың да килмәгәе, эшләгән өчен хезмәт көне дигән нәрсә генә яза башладылар. Ә ул хезмәт көне дигәненә ничә йөз грамм икмәк бирәселәре билгеле түгел, әллә бирәләр, әллә юк. Менә шуның өчен ул яңа хөкүмәтне гел сүгә торган булып китте. Теге утыз җиденче елларда аны ничек исән-имин калдырганнардыр. Сүз сыярдай кешеләр янында гына сүккәндер шул.

Сугыш чыккач, Галимулланы озак тотмадылар, берәр ай үттеме икән, кулына военкоматка барырга язу тоттырдылар. Аңа шул көннәрдә генә утыз яшь тулган иде. Ул елларда бездә туган көннәр уздыру дигән гадәт юк иде. Удмуртларда булгандыр шул, шуннан күреп кайткандыр.Бүген минем туган көн дип, үзе кушып аш-су әзерләтте. Ул вакытта хәмер дигән нәрсәнең өйгә кергәне юк иде. Дус-ишләре белән бергә чәй эчеп күңелле итеп утырдылар. Әтиең ул вакытта, ата-анасы йор-



«Әни белән икесенең рәсемен янәшә куеп карагач, ничектер, күңелгә рәхәтлек иңә. Әйтерсең лә алар гомер юлын ахырына кадәр бергә үткәннәрдер кебек».

тыннан аерылып чыгып, Югары очка — безнең йортка күчкән иде. Безнең әти үлгәннән соң, йортта ир-ат кулы кирәккәч, шулай иткәндер инде. Түбән очтагы үз йортларында әле Дәүләтша, Габдрахман исемле туганнары бар иде. Кодабыз Сәмигулла үзе дә исән-сау. Өй тулы ир-ат. Галимулла җизни, өч баласы да булгач, әниең Нурхәят тәтә белән безнең өйдә тора башлады. Өй иркен, ике катлы. Абзар-кура әйбәт. И безнең җиләк-җимеш бакчасы! Яршәпкә урысларында гына була торган иде андый мул уңышлы алма агачлары.

И балаларын ярата да иде җизни. Абыйларың Мәлик белән Хәкимулланы, икесен ике кулына утыртып, ишегалды буйлап йөгереп йөрер иде. Әле син бишек баласы гына. Нибары ике-өч айлык. Сине тартып йөрер өчен өсте ябулы бишек-арба ясады. Аны алма, чәчәк бизәкләре төшереп, бик матур итеп бизәде. Иртәгә сугышка китәсе дигән кичне, сине шул арба белән тартып, Кырмачтагы Гали чишмәсенә чаклы барган. Син ими сорап елый башлагач, тиз генә кире кайткан.

Күңеле сизенде. Бу балаларны бүтән күрә алмам инде, диде. Сәке өстенә өчегезне дә тезеп утыртып (сине яткырып), берьюлы бик озак итеп карап утырды. Бу сугыш башлануына Сталин гаепле, диде. Моны ишетеп, Сәрбиҗамал әбиеңнең коты очты. Безгә карап, кисәтеп әйтеп куйды:

— Бу сүзне кешегә әйтә күрмәгез берүк!

«Кеше» дигәннең үзебезнекеләрдән башкалар икәнен бик яхшы аңлый идек.

И аның кич белән капка төбенә чыгып өздереп гармун уйнаулары! Бөтен югары оч җыелды. Бер көйдән икенчесенә күчә-күчә озак уйнады. Сугышка бергә китәсе иптәшләре дә килде. Алар, гармунга кушылып, җырлап та алды. Хатын-кызлар елашты. Без сеңлем Нәсимә белән, күңелебез тулып, кочаклашып үкседек. Майтәтә (синең әниең Нурхәят тәтәне без шулай дип йөртә идек) урамга чыкмады. Юлга хәстәрләүдән арына алмагандыр инде.

...Иртәгәсен аларны бөтен авыл белән озатып калдык. Әниең, яшь бала

белән булгач, Кукмарага кадәр озатып бара алмады, зират янышнан кире борылды. Мин Кукмарага кадәр бардым. Военкомат капкасыннан кереп китәр алдыннан җизни, мине читкәрәк алып китеп, болай диде:

— Немец бик хәтәр килә икән. Кайта алырбызмы, юкмы? Әйтеп булмый. Монда кадәр җибәрмәбез җибәрүен. Балаларны, зинһар, карагыз. Кайта калсам, онытмам. Апагыз бик йомшак, башка туганнары кебек кыю, тәвәккәл түгел. Өч бала белән кала бит. Кайта алмасам, бәхил булыгыз.

Аларны Кукмарада берничә көн тоттылар. Идрис Габделхагы белән Гайфи Нуриәхмәте чыгып та йөри алды. Безнең җизнине ниндидер командир итеп куйганнар. Шуңа күрә ул чыгып күренә алмады.

Мин, аның белән елап аерылышкач, турыдан гына (Манзарас, Киндер Күле аркылы) тау башыннан авылга кайттым. Син ул көнне бик көйсезләндең. Әни белән икебез төн буе алма бакчасында күтәреп йөрдек. Ник дисәң, әниең, түзә алмыйча, тагын бер күреп калыйм дип, Кукмарага йөгергән. Әмма барыбер очрата алмаган. Таң атканда гына кайтты. Имезгәч, тынычланып йоклап киттең.

Җизнинең командасын Казанга шуннан соң ике көн үткәч кенә җибәрделәр әле. Анысында инде әниең сине шул матур арбаң белән тартып барды. Бу юлы чуен юл станцасында очраша алганнар. Әтиең, сине үбеп, күзләреннән яшь коя-коя, кузгалып баручы вагонга сикереп менеп китеп барган.

Җизни сугышка, кемнәрдер кебек иске-москы белән түгел, ару киемнәрен киеп китте. Җае чыгып, ул аларны кире җибәрә дә алган. Ак капчыкка тутырган да, адрес язып, почтага тапшырган. Бу киемнәр көзгә генә килеп җитте. Бишмәтенең кесәсендә хаты да бар иде. Беребезне дә калдырмыйча, сәламнәр язган, сагынуын әйткән. Балаларны каравыбызны кат-кат сораган. Хаты кайтты, үзе кайта алмады шул. Биш-алты көн саен хаты килеп торды. Яңа ел алдыннан килмәс булды. Бигрәкләр дә салкын кыш булды ул елны. Нихәл түзмәк кирәк. Шул суыклар гына харап итмәдеме икән, диештек.

Гайшә апам боларны 1997 елның 26 декабрендә, үзе яшәгән Әсән Елга авылына кайткач сөйләгән иде миңа. Өлгергән кадәрен язып алганмын. Өстәп әйтәсе килгәннәрем шул: әйе, бу сугыш безнең кебек күпме балаларны ятим итте, күпме күз яшьләрен түктерде. Мин әтиемнең төс-кыяфәтен дә белмим. Хәтта аның фотосы да калмаган. Хәер... Сиксәненче елларда, түбәләре череп-тузып беткәч, без авылдагы таш йортны колхозга бирдек. Ташы булса да берәр нәрсәгә ярар, дидек. Менә шул йортны сүткәндә, чорманың бер урыныннан иске китаплар бәйләмен тапканнар. Аларны киндер тукымага төреп, күздән ераграк җиргә урнаштырып куйганнар икән. Авылдашлар төргәкне миңа бирде. Казанга алып кайтып, китапларның һәр битен берәмтекләп карап утырганда, араларыннан бер паспорт килеп чыкты. Әтинең паспорты! (Ул Өшенбаш авылында тимерче һөнәренә өйрәнгәндә, әлеге дә баягы рәхмәт төшкере Алексей оста ярдәмендә, Тәкәнештән паспорт ала алган икән. Безнең авыл кешеләренә ул елларда паспорт бирмәгәннәр әле). Паспорт булгач, анда әлеге документ иясенең фотосы да була, билгеле. Әтинеке дә бар. Саргаеп, төсе уңып беткән. Мин, инде тәмам олыгайгач, әтинең рәсемен беренче тапкыр әнә шулай күрдем. Дөресрәге, сурәтнең ниндидер эзләре генә иде ул. Фотографияләр белән эш итүче бер оста аны күпмедер дәрәҗәдә күрерлек итте. Шушы фотоны сезгә дә күрсәтергә булдым. Әни белән икесенең рәсемен янәшә куеп карагач, ничектер, күңелгә рәхәтлек иңә. Әйтерсең лә алар гомер юлын ахырына кадәр бергә үткәннәрдер кебек. Аһ, шулай булган булсачы... ■

«Минем шәҗәрәдә – Бөек Ватан сугышы еллары» конкурсы нигезнамәсе

I. Гомуми нигез

«Минем шәҗәрәдә — Бөек Ватан сугышы еллары» конкурсы тарих фәннәре докторы, профессор Фәйзелхак Ислаев инициативасы белән «Безнең мирас» журналы һәм «ТАТМЕДИА» ААҖе белән берлектә үткәрелә.

II. Конкурсның максаты һәм бурычлары

Максат:

1. Шәҗәрәләр аша Бөек Ватан сугышы тарихында татар милләтенең урынын билгеләү, тарихи үзаңын формалаштыруга өлеш кертү.

Бурычлар:

1. Нәсел тарихы нигезендә Бөек Ватан сугышында һәм тылда катнашучыларны барлау.
2. Нәсел шәҗәрәсен төрле форматта, зәвыклы, башкаларга үрнәк булырлык итеп башкару күнекмәсен формалаштыру.
3. Гаилә тарихында гына сакланган шәхесләрне татар дөньясына чыгару.
4. Туган як тарихын өйрәнүгә кызыксындыру уяту һәм татар теленә мәхәббәт тәрбияләү.
5. Укучыларда ватанпәрвәрлек һәм әхлакый идеаллар тәрбияләү.

III. Конкурсны оештыру һәм үткәрү

2014 елның июленнән — 2015 елның маена кадәр.

Катнашучыларның яше чикләнми.

Йомгак 2015 елның 22 июнендә, Бөек Ватан сугышы башланган көнне ясала.

IV. Материалларны кабул итү тәртибе

Тапшырылырга тиешле материаллар:

— Төрле ысулда эшләнгән гаилә шәҗәрәсе, А4 форматында, 1 бит.

— Сугышта яисә тылда катнашучы турында бер битлек инша (14 нче шрифт, интервал — 1, формат А4). Өстәмә материал — шәхеснең фотосурәте.

— Материалларны әзерләүче турында белешмә: исем, фамилия, әтисе исеме тулысынча; туган елы, эшләгән яисә укыган урыны; элемтәгә керү өчен телефон яисә электрон почта адресы булу зарур.

— Материаллар yanamiras@mail.ru почтасына яки редакциягә (Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 йорт) җибәрелә.

— Һәр конкурсант 2015 елның икенче ярты еллыгына «Безнең мирас» журналына язылган квитанциянең күчермәсен тәкъдим итә.

V. Бәя бирү шартлары

1. Шәҗәрәнең башкарылу үзенчәлеге (иҗади якын килү).
2. Башкарылу зәвыклылыгы, затлылыгы.
3. Шәҗәрәдә урнаштырылган буыннар саны.
4. Инша эчтәлегенең Бөек Ватан сугышы елларында булган гыйбрәтле вакыйганы чагылдыруы.
5. Иншаның язма сөйләм таләпләренә туры килүе.

VI. Йомгаклау һәм бәяләү

«Минем шәҗәрәдә — Бөек Ватан сугышы еллары» бәйгесенә нәтиҗә жюриның йомгаклау утырышы карары беркетмәсе нигезендә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире боерыгы белән рәсмиләштерелә. Катнашкан барлык авторларга сертификатлар, җиңү яулаган авторларга редакциянең дипломнары һәм истәлекле бүләкләр тапшырыла. Шәҗәрәләрне аерым китапка туплап чыгару ихтималы да бар.

Редакциядән: Конкурска язмалар күп килә башлау сәбәпле, алга таба аларны **www.beznenmiras.ru** сайтына гына урнаштырачакбыз.

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор **РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВ**ның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Ни ди, ишет, әнә чал башлы ирләр,
(Дөньяны картайткан[1] күп яшьле ирләр):

Гыйлем-һөнәр өйрән, кыйммәт бел аны,
Күтәрелер шуннан абруең-даның.

Белем ал, укыгыл, йөремә зая,
Ай кебек балкырсың шуннан берзаман.

Бер сүздән соң илбик әйтте: – Ни шатлык!
Күрәм – үзең ушлы, нәселең затлы.

Шәп әйттең кешелек, чынлык турында,
Нишләргә икәнне вафа юлында.

Халык өстендә мин ирекле булдым,
Хөкем итте сүзем һәм озын кулым.

Мин инде шатланмыйм бийлек хәлемә,
Ирешсәм дә, гүя, үз теләгемә.

Теләгем шул хәзер – миңа килүче
Миннән баеп китсен һәм артсын көче.

Бийлегем шатлыгы – изге исемем,
Рухыма дога һәм, якты өметем.

Җыелган ошбу мал, алтын-көмешне
Яугирләргә бирәм, дип мин тырыштым.

Малымны өләшәм изге ат өчен,
Миңа дога гына чын кыйммәт, димен.

Теләгем шул гына – ярдәмем илән
Баеп китсен һәрбер миннән соң килгән.

Белем ал, укыгыл, йөремә зая,
Ай кебек балкырсың шуннан берзаман.

Үзем китсәм, илем рәнҗемәс миңа,
Тик ул дога кылсын иде рухыма.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ФИКЕРЕ

Җавапта Үгделмеш әйтте: – И, илбик,
Бу эштә дә кирәк акыл һәм белек.

Үләсе кешегә нәрсә иң кыйммәт?
Илгә җәелсә дан һәм дә изге ат.

Бу дөньяда кирәк акча куллану,
Ахирәт дөньясы өчен шулай ук.

Алтын-көмешеңне белеп сарыф кыл–
Каю ил теләсәң, шуны алырсың.

Ни ди бер чичән бий – акылдар, ишет:
«Сәмән таләп итә бу бийлек эше».

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
[1] Дөньяны картайткан – «чиктән тыш озак яшәүче» мәгънәсендә борынгы фразеологизм.

Алтын-көмешеңне белеп сарыф кыл –
Каю ил теләсәң, шуны алырсың.

Бий гаскәр җыярга күп сарыф кыла.
Илен саклый ала тик шулай гына.

Хәзинә күп кирәк, гаскәр чук[2] булсын.
Бийгә байлык нигә? Халык тук булсын.

Сүве булса бийнең, иксемәс иле,
Югыйсә, билекнең азагы килер.

Чирү риза булса, кинәнсә бийдән,
Бий хәраҗ алала теләгән илдән.

Юмарт булса бийләр, киң ачса кулын,
Ике дөньяда да биләр түр урын.

Ни ди, ишет, әнә белекле белкә:
«Саранлык белән бий баш булмас илгә.

Ике капма-каршы ягышмас, качар,
Саранга юл куймас, юмартны кочар.

Сараннан кача бар юньле ир-атлар,
Кеше җыеп хөкем йөртә юмартлар».

Саранлыктан бийгә дошман күп була,
Саранлыктан чыга низаг һәм бола.

Ике нәрсәгә ил тотынып тора:
Аның берсе — алтын һәм берсе — корал.

Юмарт булса бийе, ныгыныр билек,
Юмарт була белгән бий, илбик, бөек.

Яшендәй кылычын уйнатыр алпар,
Азаулы ирәннәр кан-сүле агар,

Ләкин алтын илә кул сонса бийләр,
Кылычсыз – тел илә яуланыр илләр.

Төзек итә илне әлеге ике[3],
Шулар белән бөек булыр бий, илбик.

Бөкрәйгән кешене алтын турайтыр,
Бозылган эшеңне алтын төзәйтер.

Кылыч кайда орса, көмеш шунда ул –
Көмеш кайда булса, кылыч тота юл.

И, көмеш чәчле бий, җый шәп ирләрне:
Таралган көмешне кылыч өядер.

Көмешләрне саклау – кылычлы ирдән,
Җыелган алтыннар кылычка корбан.

Саран бий елларча хәзинә җыя,
Юмарт бий кылычлап ала да куя.

Җиһан кануны шул һәрбер чакта да:
Саран сүгелә һәм юмарт мактала.

Көмешләрне саклау — кылычлы ирдән,
Җыелган алтыннар кылычка корбан.

Шулай дип, Үгделмеш чүкте, җир үпте.
Бер Алланы мактап, зурлап илбикне.

Бу сүзләрне тыңлап илбик шат булды,
Кулларны күтәреп, бер дога кылды.

Әйтте: – И, ярдәмле, кот кылган иям,
Сыгылган көнемдә сыгынган иям.

Синнән бүтән юктыр өмет-терәгем,
Синең шәфкатеңә баглы теләгем.

Нинди генә ярдәм кылмадың миңа.
Азмы бәхет, шатлык юлладың миңа.

Догам – сүземнән тыш ничек табыныйм?
И, мәңге зарсыз зат, мин бер зарлымын.

Сорыйм синнән генә ярдәм, көч-куәт,
Туры юл өстендә тот мине, өйрәт.

Бар изгелекләрдән янә артыгы
Бу Үгделмеш инде, күңлем туклыгы.

[2] Чук – «ишле, күп».
[3] Ягъни, алтын һәм кылыч. Татар мәкале: Барысын да сатып алам, диде алтын, барысын да тартып алам, диде кылыч.

«Кемең белән дәүләт ярашса килеп,
Башын күккә тигерер, югары кылып».

Аны бирдең миңа бүләк итәрәк,
Шөкер итәм шуңа мин йөз мең кәррә.

Жанын-тәнен фида кыла эшемдә.
Дога өсти үтеп барган яшемә.

Көч бир инде миңа – бер үтим хакын,
Сөенсен, миңа булсын күңле якын.

Янә әйтте илбик: – «И, Үгделмешем,
Сине мактый һәрбер белдекле кеше.

Акыл дисәң, синең акылың тәгәл,
Гыйлем дисәң, синдә иң биек кимәл.

Кешелекле, йомшак һәм ипле булдың,
Ышанычлы булып эш итә белдең.

Эшең һәрчак артык булды әҗердән;
Бетереп эшләдең эшне һәр җирдә.

Тиеш инде миннән түләк һәм бүләк,
Әле исән чакта бирергә кирәк.

Никадәр сөенсә синнән күңелем,
Ходай сөендерсен шулкадәр, углым.

Сүзен кисте илбик, уйланып тынды.
Хезмәткәр җир үпте һәм үрә торды.

Чыгып китте шуннан гаять шат булып,
Атын менде, өйгә кайтты чаптырып.

… Вә хезмәттә булды көндез вә кичә,
Бәхеттә яшәде кайгы белмичә.

Тирәнәйде акыл һәм артты белем,
Фәләк көлеп бакты, көчәйде кулы.

Ни ди, ишет, илдә танылган кеше,
Бәхет-коты белән дан алган кеше:

*«Кемең белән дәүләт ярашса килеп,
Башын күккә тигерер, югары кылып».*

Килә бирсә дәүләт, артса мал-туар,
Кеше күңле үсә, йөз якты була.

Шуңа охшаш чал чәчле бер ир
(Аны яхшы тыңла, и, яшь баһадир):

«Кемнең байлыгы зур, кулы да озын,
Сүзе дә акыллы, тискәресе уң.

Ни шәп фәйләсуфлар, булсалар малсыз,
Ни телдәр булса да, калалар телсез».

Бу дөнья кануны шуннан гыйбарәт;
Данлыңны күтәрә эш түгел, дәүләт.

Мал юньсезгә тисә, ул абруй алыр,
Кечкенәгә тисә, ул олыланыр.

Мал ямьсезгә тисә, шуны матурлый.
Кәрләне бай булса, баһадир зурлый.

Мал килсә, үтәлә бар теләкләрең,
Югары күренә түбәнлекләрең.

Ни шәп фәйләсуфлар, булсалар малсыз,
Ни телдәр булса да, калалар телсез».

Әгәр инде китсә, ала барсын да,
Кара җиргә карар текә башың[4] да.

И, акыллы, уяу, изге зат, зинһар,
Сөймә дөньяны, ул башыңны җуяр.

Нигә синә төндәй кара бу урын?
Саф дөньяга ашык пычранмас борын.

Кабак ич бу дөнья, кит тизрәк, тор да,
Идез урда[5] кайда, шуңа юл сора.

Ни ди, ишет, әнә күңле саф бер зат
(Ни кылса да күңле керлектән азат):

И, һиммәт иясе, бар котлы урын,
Шуны сорар асыл ир үлмәс борын.

Дөньяң кичәр, кара ахирәтеңне,
Дөньяны куймасаң, ул куяр сине.

[4] Текә баш — «горур баш» (татар телендә дә бар).
[5] Урда – монда «җир астындагы бина». Идез урда — борынгы монастырь кебек урын.

Җәберче дөньяның үзен җәберлә,
Шуннан соң ул сине үзенә тиңләр.

И, адашкан, башы әйләнгән токым!
Сөймәгез дөньяны, ул төпсез упкын.

Упкынга карасаң, ул сиңа карар.
Төшәрсең, тапмассың тынгылык, карар.

Тизрәк тартыл төпсез упкын яныннан,
Ходайдан ялварып коткар җаныңны.

Кайт кире, Үз тәңре[6] коткарсын үзе,
Тәүбә кыл әйткәчтен, кала бит сүзең».

Шуннан соң илбик, күр, күңлен төзәтте,
Халыкка изгелек эшен күбәйтте.

Илдә иркенчелек. Арык симерде.
Дус-иш саны артты, дошман кимеде.

Көннәрен уздырды бәхет-шатлыкта.
Җәелде яхшы дан аның хакында.

Шул рәвешчә узды шактый гомере.
Бүре һәм бәрән дус булып йөреде.

ИЛБИКНЕҢ ҮГДЕЛМЕШКӘ СОРАВЫ

Утырып, илбик беркөн Үгделмешне
Чакырды, сорады бүгенге эшен.

– Ничек үтә көннәр, Үгделмеш дускай,
Илебездә күпме ярлы, күпме бай?

Ил эчендә бармы яраксыз, явыз.
Халык хәлен күрсәт миңа чаршаусыз.

Ил безне мактыймы яки сүгәме?
Сөйлә ил телендә булган сүзләрне:

Начарлыгыммы күп, яхшы ягыммы?
Барчасын әйт, тыңлап, чара табыйм мин.

Өч сәбәптән, илбик, золым ирешә:
Беренче – бий гафил булса, иренсә.

Икенче – кыланса ир-ат бик әкрен,
Өченче – ашаса ачлык ил бәгърен.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Үгделмеш әйтте: – И, илбик,
Теләгебез инде кул бирде килеп.

Синең дәүләтеңдә, дөнья төзәлеп,
Сагыш булды кыска, сөенечләр – күп.

Халык баеды һәм күңел җилкетеп,
Авыллар, шәһәрләр үсә гөл бетеп.

Рәхәтлектә үтә халаек көне,
Сөенечле хәзер дөнья көтүе.

Кемнәр телле – сине мактыйлар бар да,
Кем сулышлы[7] – сиңа хәер-догада.

Гаделлек — су, дидек, золым — ут инде,
Син килдең дә золым утын сүндердең.

Тәртип куйдың, тыныч тормыш төзелде,
Хәзер көчләүчелек күренми инде.

Өч сәбәптән, илбик, золым ирешә:
Беренче — бий гафил булса, иренсә.

Икенче – кыланса ир-ат бик әкрен,
Өченче – ашаса ачлык ил бәгърен.

Болардан илеңдә һичберсе дә юк.
Каян килсен безгә көчлек, явызлык.

И, изге кануннлы, ару-саф бийем!
Ходай бирмеш сиңа акыл һәм белем.

Син тәүфикъ иясе булгачтын инде
Ил ашка тиенде, кием киенде.

Шөкер ит, гыйбадәт кыл һәм уйланып
Иркен яшәүдә бул, миннән ял алып[8].

---

[6] Үз тәңре – Лакшми, индуизм динендә бәхет алиһәсе, Вишнуның җефете. XII гасырда төркиләрнең кайберләре буддист булганнар. ДТС.
[7] Сулышлы — «җанлы, үзенең җаны бар».
[8] Үгделмеш баш вәзирлектән китмәкче була.

Миңа тисә азап, тияр ләззәт тә,
Ләззәт белән азап йөри янәшә.

Мин әгәр эшләсәм бер ялгыш-язык,
Һичшиксез төзәтәм – мин кол шунда ук.

Шөкер итте илбик, бик тә шат булды,
Һәм, фатиха итеп, күтәрде кулын.

Әйтте: – Әй, рәхимле иям, олугсың,
Илдә данлы иттең данлы колны син.

Тигердең син миңа шундый игелек,
Шөкерем муйныма була инде йөк.

Бу шөкерне ничек күтәрим инде,
Үзең генә гафу итәрсең инде.

ИЛБИКНЕҢ ҮГДЕЛМЕШКӘ СОРАВЫ

Янә Илбик әйтте: – И, Үгделмешем,
Алланың рәхмәте сине белмешем.

Сәбәпче булдың син бар игелеккә,
Көчләүне тыюга, тәртипчелеккә.

Ходай кылды миңа бик күп игелек.
Шулардан берүзең артык ун өлеш.

Ничек тырышса да илбик берүзе,
Ярдәмче булмаса, тоталмас сүзен.

Бий эчтән, кол тыштан күз-колак була,
Тугры кол бийдән дә яхшырак була.

Күземсең, телемсең, колымсың минем,
Изге атны миңа, егет, син бирдең.

Ни ди, ишет инде, борынгы хакан
(Ул бөтен дөньяны яулаган булган):

«Озак эзләп тапкан тугры колын бий
Алтынга күмсә дә күп булмас, бәлки.

Тугры ярдәмче – кол табылса бийләр
Уңышка ирешә һәм бәхетлеләр.

Хезмәтченең тугры була яхшысы,
Ләкин андый коллар сирәк, ахрысы».

Дөньяда булмаса иде тугрылык,
Ничек яшәр иде кешелек, халык.

Исәрләнмә инде, и, Үгделмешем,
Атаңнан миңа бер генә калмышсың.

Синең кебек берәү булганда тагы,
Ярашыр идегез сез аллы-артлы.

Бер генә миңа син, и, холкы тугры,
Югалтсам, синдәй үк бүтән кем булыр?

Бердәнбер булгач син, авырдыр инде,
Тагы берәү булса ярдәмгә, димен.

Тимәсен иде күп михнәтләр сиңа,
Кабул булсын иде бу хәер-дога.

Эзләп кара – бармы карендәшләрдән
Сиңа охшаш берәү, итәргә ярдәм?

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Юньле ярдәмчеләр илдә күп булса,
Бийне ирештерә алар уңышка.

Җавап биреп: – Илбик, – диде Үгделмеш, –
Исән булсаң, кулга кавыша ул эш.

Тынычлансын илбик, рәхәттә булсын,
Вакытында тапсын теләк-арзусын.

Минем имгәнүгә, илбик алтыны[9]
Борчылмасын, күңле булсын тып-тыныч.

Миңа тисә азап, тияр ләззәт тә,
Ләззәт белән азап йөри янәшә.

Әгәр эшкә файда китерер кемсә,
Кирәк булса, табам, аласың килсә.

Ишет, данлы бер ил башы ни дигән
(Акылдарларга да ул акыл биргән):

[9] Хәзергечә бу сүзләр илбиккә карата ироник аһәңдә яңгырый. Үгделмеш тә шул аһәңдә әйткән булса, аның минәзе-образы тирәнрәк булып чыга!

Идарәдә ярдәм итүчеләр күп
Булса, эшләр һәйбәт, бий ятыр көлеп.

Юньле ярдәмчеләр илдә күп булса,
Бийне ирештерә алар уңышка.

Карендәшләремнән бар шундый берәү –
Кулыннан эш килә, күп нәрсә белә.

Ирдәме күп аның: уяу һәм уйчан,
Алынган һәр эшен ул булдыручан.

Кыланышта тугры, аты Уйгырмыш,
Һәр кыен эшкә дә егет кул ормыш.

Ләкин ул дөньядан чөерде йөзен,
Таулар арасында яши ялгызын.

Ходага табынып үзен имгәтә,
Дога белән язык чирен имләтә.

Миннән йөз өстендер аның ирдәме,
Халыкка билгеле егетлек даны.

Бергә эшләсәк бер эшне, ул кардәш
Һәрчак миннән өстен булды, миңа баш.

Булыр илбик тыныч, күңеле бөтен,
Яшәр ул шатлыкта хакимлек итеп.

Илбик әйтте: – Арзу-теләгем будыр,
Аны тапсак әгәр, күңелем булыр.

Ничек тә булса тап бу эшкә юлын,
Миңа якынлаштыр аны, елгырым.

Әйт миңа – без аны ничек чакырыйк,
Кайсы юлчабарны аңар чаптырыйк?

Бетекме кирәк, йә телдән генәме
Чакыру яхшырак, тап бер әмәлен.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавап бирде – әйтте сүзен Үгделмеш:
– Соравында, илбик, җавап бирелмеш.

Кардәшем барлыгын сөйләдем бүген.
Килерне-килмәсне – бу ачык түгел.

**Белем алса гына кеше – кешедер,
Калганнары исә елкы төследер.**

Килсә, кыйммәтледер аңар синең сүз,
Килмәсә, фәрманың буладыр очсыз.

Газапланмас микән илбик алтыны?
Гаепләмәс микән әле ул мине?

Илбик әйтте: – Мин тик сорап белештем,
Белгәнеңне үзең син мәгълүм иттең.

Чакыр, килсә килер, әгәр килмәсә,
Сиңа ник үпкәлим, ул теләмәсә.

Син фазыйләтләрен аның мактадың,
Шулар өчен менә чакырам аны.

Белекле һәм зирәк дигәнең өчен
Аны күрергә бик теләгем көчле.

Белем алса гына кеше — кешедер,
Калганнары исә елкы төследер.

Эш юнен белә тик укыган кеше,
Укыганнар эшли, эшләсә, эшне.

Шуңар охшаш тагын билгеле сүз бар
(Ишет, данлы егет, һәм ит игътибар):

«Аңласаң, чишелә һәрбер чи төен,
Белем ал – яшәүнең белерсең көен.

Белемеңне куллан һәм тагын өйрән,
Өйрәнүне куйма – көн дә шөгыльлән».

Миңа гына кирәкмени ярдәме?
Сиңа да җиңеллек итәр кардәшең.

Кардәшле булу шәп, кирәк ул шунсы,
Кардәшең булмаса, якын дус булсын.

Ни шәп әйткән бер ил башы (ул белгән):
Кардәшсез көчсезрәктер кардәшледән.

Кардәшле кешенең дөньясы киңдер,
Кардәшлеге аша аты беленер. ■

«МИҢА ТИГӘН ЗӘҺӘР ҖИЛЛӘР...»

Тел галиме Җәвад Алмазның тормыш юлы, фәнни мирасы

Марсель Әхмәтҗанов

Татар филологиясен үстерүгә зур өлеш керткән ошбу галим вә шәхеснең мирасы бүгенге рухи дөньябызда онытылып бара дисәк, һич тә ялгышмабыз. Чөнки аның каләме тудырган фәнни хезмәтләрнең бик азы гына бүгенге фән әһелләребезгә мәгълүм.

Җәвад Алмазның татар телен, диалектологиясен, борынгы әдәби ядкярләрне анализлауга багышланган күп әсәрләре фәкать кульязма сәхифәләрдә генә саклана. Язма мирасының бу хәлгә төшүендә галимнең фаҗигале язмышы да сәбәпчедер, әлбәттә.

Зур галимебез болганчык, кара чорда туып үскән. Аның гомере теләсә кайчан репрессия корбаннары сафын тулыландырырга мөмкин булган. Шунлыктан, без гыйлем иясенең тормыш юлын җентекләбрәк күзәтүне кирәк саныйбыз.

Җәвад Ногман улы[1] Алмаз 1916 елда хәзерге Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районының Чертуш авылында мулла гаиләсендә туган[2]. Аның бабалары Ханкирмән (Касыйм) шәһәре мәдрәсәсендә белем алгач, башка якташлары белән бергә, Кама аръягындагы буш җирләргә килеп урнашкан. Нәселе бик укымышлы саналган. Өстәвенә, шагыйрь җанлы кешеләр булып, мөнәҗәтләр дә язган алар.

Җәвад Алмазның әти-әниләре 1930 еллар тирәсенә кадәр Чертушта яши. Шулвакытта муллаларны эзәрлекли башлыйлар. Хакимият агрессив сул элементлардан саналган затларны җәзага тартырга дип исемлек төзи. Ул исемлеккә Ногман бине Габделманигъ та кертелә. Әлеге мәсьәлә хәл ителгән җыелышта катнашкан дусты, кич кереп, бу хакта хәзрәткә хәбәр кыла. Хәзрәт тиз-тиз җыена да, иң кирәкле әйберләрен алып, атын җигеп, гаиләсе белән Келәүле станциясенә чыгып китә. Аннан Ташкентка юл тоталар. Хәзрәт, бик укымышлы, галим зат буларак, монда да тиз арада дан-шөһрәткә ирешә.

Җәвад Алмаз. Казан. 1960

[1] Безгә Җәвад Алмазның туганнары шулай дип сөйләгән иде. Гәрчә барлык белешмәлекләрдә, сүзлекләрдә ул Диндар улы булып йөри. Безнеңчә, галим репрессия давылына эләкмәс өчен, атасының исемен махсус үзгәртеп язган булырга тиеш.
[2] Чыганаклар бүгенге көндә Татарстан Республикасының Берләштерелгән музеена тапшырылган, аңарчы галимнең туганнары кулында, Ташкент шәһәрендә сакланган шәхси архивы документларына таянып алынды.

Соңыннан Җәвад Алмаз, җәмгыяви-сәяси сәбәпләр аркасында, чыгышын-тумышын яшереп, тормыш юлын уйдырма фактлар белән «баетырга» мәҗбүр була. Мисал өчен, автобиографиясенә игътибар итик: *«1916 елда Куйбышев өлкәсенең Чельно-Вершинск районы Благодаровка авылында тудым. Атам беренче империалистик сугышта фронтта югалды, анам 1921 елгы ачлыкта һәлак булды. Мин 1926 елга кадәр туганнарымда тәрбияләндем, шул елны Чистай кантоны Мөслим волосте Кутлушкино авылындагы интернатка тапшырылдым. Кутлушкинодан Чистай ятимнәр йортына күчерелдем. Бу ятимнәр йортыннан качып, Казандагы туганнарым янына килдем. Ләкин алар бик ярлы булганлыктан, миңа ярдәм итә алмадылар. Казанда мин тәрбиячеләре булмаган балалар төркеменә ияреп киттем. Күп шәһәрләр гиздем. 1930 елның җәендә мине Ташкент вокзалында тотып алдылар һәм ятим балаларны урнаштыру комиссиясе укырга юллады. Мине стенографистлар курсына керттеләр».*

Әлеге курсларда белем туплагач, Җәвад Алмаз Сәмәрканд университетында укып чыга. Аннары Смоленск педагогика институтының филология бүлеген тәмамлый. Алман, француз телләрен өйрәнә. Гарәп, фарсы, Урта Азия халыклары, татар, урыс, Көнбатыш Аурупа телләрен кушып санаганда, унлап телдә сөйләшә-аңлаша алган.

1939 елда Җәвад Алмазны Ташкент шәһәрендәге Укытучыларның белемен күтәрү институтына эшләргә җибәрәләр. Галим 1942 елга хәтле шунда урыс телен укыта. Бер үк вакытта, Ташкентта төрки, фарсы, гарәп телләрендәге борынгы кулъязмаларны өйрәнү институтында укый. Анысын да тәмамлап, борынгы кулъязмаларны өйрәнүче фәнни хезмәткәр квалификациясен ала.

Алга таба Үзбәкстан Мәгариф министрлыгы системасындагы методик бюро директоры вазифасында эшли, Ташкент финанс-икътисад техникумы директоры булып тора. Берьюлы Ташкент юридик мәктәбендә укый, аны бетергәч, Сәмәрканд педагогика институтында үзбәк төркемнәрендә урыс теле дәресләре бирә. 1948 елда Үзбәк дәүләт университетына (Сәмәрканд) күчә, анда гарәп, фарсы, төрки телләр, тюркология буенча гыйлем тарата. 1954 елның февраленнән Хәрәзм педагогика институтында иске үзбәк теле һәм үзбәк әдәби теле тарихы буенча мөгаллимлек итә.

Җәвад Алмаз 1955 елда Казанга килеп, университет каршындагы аспирантурага укырга керә. Татар теле тарихына кагылышлы тема буенча диссертация яза. Соңрак Казан университетының татар теле кафедрасына эшкә калдырыла, анда 1961 елга кадәр эшли, борынгы төрки телләрне, әдәбият тарихы укыта.

Җәвад Алмаз 1960 елда КПССның Үзәк комитетына татар теленең мескен хәлгә төшүе хакында хат юллый. Мәскәүдән комиссия килеп проблеманы тикшерә, ләкин бер чара да күрелми. Шуннан соң дәүләт иминлеге органнары Җәвад Алмазга каршы провокация оештыра, нәтиҗәдә, 1961 елның 10 апрелендә университет ректоры М.Нужин һәм партком сәркатибе Б.Лебедев галимне төрле ялганнар, уйдырмалар белән әхлаксызлыкта гаепләп сыйфатнамә язалар (Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Мирасханәсе, 117 ф., 1 тасвир, 23 эш, 4 бит). Махсус оешма аны бер урынга да эшкә алмаска, дигән яшерен күрсәтмә бирә. Җәвад Алмаз Ленинград, Мәскәү, Дагыстан, Баку, Ташкент кебек җирләрдә эш эзләп карый, ләкин һәр тарафта теләгәненә каршы төшәләр. Ул Ташкентта яшәүче апасы Мөгаззәмә белән җизнәсе Мәсгуть Гатауллиннар гаиләсендә генә сыеныр урын таба. Яшәү чыганагы итеп фотограф хезмәтен файдалана: үзбәк кышлакларына йөреп, рәсемгә төшереп, тамак ялгый. Шулай ук, фәнни хезмәткә баш-аягы белән чума: тюркология, татар әдәбияты тарихына кагылышлы бай

Мөгаззәмә һәм Мәсгуть Гатауллиннар. Ташкент. 1930 ел

китапханә туплый, татар әдәбиятының тарихи ядкярләренә кагылышлы һәм скифларның төркилеге турында тирән тикшеренүләр алып бара.

Җәвад Алмаз интенсив рәвештә иҗатка керешә. Аның архивында дистәләгән шигырь дәфтәре саклана. Аларда утызынчы елларның хәтәр сәяси вәзгыяте бик образлы итеп тасвирланган:

ЗӘҺӘР ҖИЛЛӘР

Тирә-якны дошманнарым чормаганнар!
Дус кешеләр тирән йоклый — тормаганнар.
Миңа тигән зәһәр җилләр туганнарның
Битен чеметеп, колакларын бормаганнар.

ОРАТОР

Болгый-болгый кулларыңны
Бер оратор булдың лабаса.
«Юлбашчылык» чире узып киткән
Вөҗданың — менә тамаша.
«Юлбашчылык». Нинди матур исем,
Куа-куа шуның артыннан,
Күпме айлар, күпме еллар үтте —
Үтәлмәдең «канун» шартыннан.
Күзләреңә — «вөҗдан» билгесенә
Нинди каннар эзе урнашкан?!
Җә, әйт!
Ахры, сатлык көннәр эзе
Мәче булып күңлең тырнашкан?!

Галимнең шигъри мирасы, билгеле, моның белән генә чикләнми. Исән калган беренче шигыре 1930 елга карый. Аларның җәмгыяви яңгырашы ул чор татар поэзиясендәге сталинизмны мактаган әсәрләрдән аерылып тора. Унбиш яшьлек егет социализм җәмгыятендәге авторитаризм, тоталитаризм күренешләрен, сатлык җанлылык кебек тискәре күренешләрне дөрес тоеп алган. Җәвад Алмаз архивында үзе язган хикәяләр, публицистик язмалар, тәрҗемә әсәрләре һ.б. бар.

Казан университетында эшләгән дәверендә ул археография, диалектология, «Кыйссаи Йосыф» дастаны текстологиясе проблемалары белән шөгыльләнә. Аның журналларда, фәнни җыентыкларда бу темаларга кагылышлы мәкаләләре басыла.

Ташкентта вакытта Җәвад Алмаз, Кол Гали әсәреннән тыш, Алтын Урда дәвере әдәбиятын да өйрәнә, XIII-XIV йөзләрдә татар телендә иҗат ителгән әсәрләрнең сүзлекчәләрен төзи. Мисал өчен, Хисам Кятиб тарафыннан язылган «Дастаны Җөмҗөмә» — шуларның берсе. Бу тәрҗемә текстны без, Җәвад Алмаз хезмәте икәнен күрсәтеп, Мөгаззәмә

апа рөхсәте белән, 1996 елда «Әдәби мирас» җыентыгында бастырып чыгардык. Ләкин татар фәненә кереп оялаган кайбер карак докторлар хезмәтебезне, эшебезне танырга теләмичә, аны үз табышлары итеп күрсәтеп, матбугатта әлегәчә «карта» уйныйлар...

Тәрҗемә искиткеч уңышлы башкарылган, аның шигъри матурлыгы, үткенлеге, образлылыгы оригиналдан һич тә калышмый.

Җәвад Алмазның зур көч куеп, күп еллар буе башкарылган икенче бер хезмәте — скиф-саклар теленә багышланган искиткеч кыйммәткә ия филологик монографиясе. Бу әсәрнең кульязма күчермәдән алынган нөсхәсе галимнең архивында саклана.

Әлеге эшне Җәвад Алмаз Казан һәм Ташкент шәһәрләрендә 1959-1977 елларда урыс телендә башкарган. Күләме — дүрт басма табак чамасы. Хезмәт «скифлар — иранлылардан килгән кавем» дигән фикергә кискен каршы чыгу белән башлана.

Моннан соң галим сакланып калган скиф сүзләренең лексик мәгънәләренә туктала. Ул бу мәсьәләдә дә төрле илтараф галимнәренең фаразын җөпләп кенә калмый, ә үз тикшеренү методикасын да эшли. Мәсәлән, аның карашынча, алман галимнәре тәкъдим иткән фаразлар скиф-сак сүзләренең мәгънәләрен ачуга файдалы нигез була алмый...

Скифларның иран теллелеген исбатлау исә, Җәвад Алмаз фикеренчә, Көнбатыш империалистларының «Кытайга хәтле скиф-сак экспансиясе булган, шунлыктан, бүгенге Кытайгача җирләр — һинд-аурупа халыкларының биләмәсе» дигән агрессив дәгъваларына юл ачу булыр иде, дип бәяләнә.

Җәвад Алмаз җитмешенче елларда Казакъстан Фәннәр Академиясе үтенече буенча Каспий диңгезе буендагы Маңгышлак өлкәсендә сакланган

Җәвад Алмаз. 1978 ел

нугай-мангытлардан калган эпитафик һәйкәлләрне өйрәнүгә дә зур көч куя. Әмма аның бу хезмәте әлегәчә бәяләнмәгән.

Җәвад Алмазның бу язмалары татар теленең кыйммәтен ача торган материал булып тора. Әлеге хезмәтне кичекмичә матбугатта игълан итү зарур, чөнки ул — «Биармия»[4] кебек нигезсез уйдырмалардан күп мәртәбә ышанычлырак һәм мантыйк белән язылган эш.

Җәвад Алмаз фәнни иҗатының гөрләп үсәр чагында — 1979 елның 23 мартында Ташкент шәһәрендә, рәсми хакимият тарафыннан нигезсез каһәрләнеп, яшәү чыганагыннан мәхрүм ителгән килеш бакый дөньяга күчә. Юкса, тагын да тирәнрәк, колачлырак фәнни уңышларга ирешер өчен гайрәте дә, гыйлеме дә бар иде әле аның.

Редакциядән: *Заманында Җәвад Алмаз «Кыйссаи Йосыф» китабының сүзлеген төзегән булган. Әлеге ядкәрне табып, «Безнең мирас» сәхифәләре аша халыкка кайтарасы иде.* ■

[4] Биармия — борынгы скандинав халыкларының шигъри риваятьләре аша мәгълүм тарихи төбәк. Хәзерге Карелия, Мурманск һәм Архангельск өлкәләре җирләрендә урнашкан булган дип фаразлана.

ФАЗЫЛ ТУЙКИН
ШИГЫРЬЛӘРЕ ҺӘМ ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ

Әнвәр Шәрипов,
филология фәннәре докторы, профессор

Әхмәтфазыл Әхмәткәрим улы Туйкин (1887-1938) – XX гасырның беренче яртысында армый-талмый киң колачлы эшчәнлек алып барган, янып иҗат иткән күренекле язучы, халык авыз иҗаты әсәрләрен җыючы, тарихчы, мәгърифәтче-педагог, шагыйрь һәм драматург. Ул 1937 елның 1 гыйварында «Атласов эше»нә бәйле рәвештә кулга алынып, 1938 елның 15 февралендә «халык дошманы» дип атып үтерелә. Бары тик 1958 елның 27 маенда гына «Атласов эше» яңадан каралып, «гаепсезгә кулга алынып хөкем ителгәннәр» дигән карар чыгарылып, аклана.

Шундый фаҗигале тормыш кичерүенә дә карамастан, Фазыл Туйкин үзеннән соң зур һәм күпкырлы иҗади мирас калдырган. Аның мирасын өйрәнү, мәгълүм сәбәпләр аркасында, бары әдип аклагангач кына башланып китте. Бу өлкәдә, билгеле булганча, Э.Шәрифуллина, Ж.Миңнуллин, Д.Гарифуллин, С.Насыйбуллина, Э.Ханнанова, әдипнең кызы Бүләк Ибәтуллина һәм башкалар шактый зур тырышлык күрсәтте. Фазыл Туйкинның күпкырлы иҗатын

тирәнтен өйрәнеп, киң планда анализлаган иң беренче зур монографик хезмәтне Эльмера Ханнанова-Галимҗанова язды: 2004 елда ул «Фазыл Туйкинның иҗади мирасы (иҗат методы һәм мотивлар)» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклады һәм 2007 елда үзе җыйган материалларны туплап, Казанда 592 битле «Бертуган Туйкиннар. Тарихи-документаль җыентык» дигән хезмәтен бастырып чыгарды. Бу чын мәгънәсендә Фазыл һәм Кәбир Туйкиннар иҗади мирасының халкыбызга яңадан әйләнеп кайтуы булды. Шул ук 2007 елда башкорт галиме, филология фәннәре кандидаты Миңлегали Нәзерголов Уфада Фазыл Туйкин әсәрләренең «Ватан каһарманлары» дигән 200 битле җыентыгын бастырды.

Фазыл Туйкинның күпкырлы иҗат мирасында аның шигырьләре зур һәм мөһим урынны алып тора. Ул язган барлык шигырьләрнең саны күпме? Әдипнең иҗаты инде шактый өйрәнелгән булса да, бу сорауга беркем дә төгәл җавап бирә алмый. Чөнки аның иҗат мирасының шактый өлеше юкка чыгарылган яки төрле сәбәпләр аркасында югалган, безгә килеп җитмәгән. Әдипнең кызы Бүләк Ибәтуллина үзенең истәлекләрендә: *«Әтиемнең хезмәте дә үзе кебек үк фаҗигале язмышка тап булды. Кульъязмаларның бер өлеше 1934 елгы янгын вакытында янып юкка чыкты. Икенче өлешен 1937 елны әтине кулга алганда алып киттеләр дә эзсез югалттылар»*, — дип яза [1: Б.120]. Әдипнең күп кенә әсәрләре элегрәк тә, 1921-1927 елларда да, Э.Ханнанова-Галимҗанова күрсәткәнчә: *«Төрле сәбәпләр аркасында басылмый, кульъязма хәлендә кала, югала»* [1: Б.35].

Бүгенге көнгә фәндә Фазыл Туйкин шигырьләренең иң тулы тупланмалары булып **Э.Ханнанова-Галимҗанова** әзерләп чыгарган **«Бертуган Туйкиннар»** һәм **М.Нәзерголов** чыгарган **Фазыл Туйкин. «Ватан каһарманлары»** җыентыклары санала. М.Нәзерголов, мәсәлән, үз китабына язган кереш мәкаләсендә: *«Хәзерге көндә Ф.Туйкиндың 80гә якын поэтик әсәре билдәле»*, — дип яза һәм әлеге җыентыкта аның 17 шигырь, 76 җыр һәм бер поэма текстын китерә [3: Б.9]. Ә Э.Ханнанова-Галимҗанова китабында исә әдипнең 21 шигыре һәм бер поэмасы тексты теркәлгән. Шагыйрьнең шушы ике җыентыкка тупланган шигырьләрен карап китик.

Казан басмасында Ф.Туйкинның тезмә белән язылган барлык әсәрләре дә «Шигырьләр» дигән бүлектә бирелгән. Алар 1906 белән 1937 еллар аралыгында иҗат ителгән (җыентыкта һәр әсәрнең кайсы елда язылуы күрсәтеп барыла). Ф.Туйкин аеруча 1911-1914 елларда Уфада, **«Хакимия» мәдрәсәсендә** укыткан чорда актив иҗат иткән. Җыентыкта 1912 елда язылган 12 шигырь китерелә. Октябрь инкыйлабыннан соң аның поэзиясе, Э.Ханнанова-Галимҗанова күрсәтүенчә, *«күләме һәм тематикасы ягыннан әллә ни бай түгел. Революциядән соң аның шигырьләре матбугатта бик аз күренә. Ә кайберләре бары тик гаилә архивында гына сакланып калган»* [1: Б.53]. Әлеге җыентыкта да авторның 1918-1937 елларда язылган сигез генә шигыре китерелә.

Билгеле булганча, Фазыл Туйкин гомере буе татар һәм башкорт халык җырларына, курай моңына, туган ягының һәм Башкортстанның гүзәл табигатенә гашыйк булып яши. Э.Ханнанова-Галимҗанова бу турыда: *«Ул — җаны-тәне белән җырга, шигъриятькә, музыкага бирелгән кеше. Үзе дә моңлы тавышлы булып, скрипка, гармун һәм мандолинада уйный»*, — дип күрсәтә [1: Б.43]. Шуның белән бергә, әдип гомере буе бар күңелен биреп, халык җырларын җыйган, аларны бер системага салып, җыентыклар итеп халыкның үзенә кайтарып бирергә тырышкан. Аның үзе туплаган халык җырларыннан торган

«Җырлар әхтәрисе» («Җырлар йолдызлыгы») исемле җыентыгы Казанда **«Сабах»** нәшриятында ике тапкыр — 1912 һәм 1918 елларда басылып чыккан. Шулай ук үзе халык арасыннан эзләп табып, әзерләп, китап итеп бастырып чыгарырга дип Казанга җибәргән **«Ил әдәбияты»**, **«Озын көйләргә халык җырлары»** һәм зур күләмле (4 табак чамасы, 11 бүлектән торган) **«Халык әдәбиятын гыйльми, әдәби яктан тикшерү»** дигән җыентыклары да булган (соңгы җыентыкка язган рецензиясендә Хәсән Гали бу кулъязма китапка зур бәя биргән, аны бастырып чыгаруны куәтләгән). Әмма алар кайдадыр югалып калганнар.

Э.Ханнанова-Галимҗанова: *«Ул шулкадәр җырга гашыйк кеше була ки, хәтта үз шигырьләрен дә «җырлап» яза. Аларга халык җырлары һәм көйләре исемнәрен бирә. Кайбер галимнәр аны «Җырчы шагыйрь» дип атыйлар. Чөнки аның мәгълүм бер халык көенә туры китереп язылмаган бер генә шигыре дә юк бугай»*, — дип күрсәтә [1: Б.47].

Фазыл Туйкинның халык җырларына ияреп язуы аның әсәрләренең эчтәлегендә дә, шигырь формаларында да чагылыш таба. Күп кенә шигырьләренең исемнәреннән соң ул җәя эченә бу шигырьнең кайсы халык җыры көен күздә тотып язылганлыгын теркәп куя (мисал өчен, **«Алтынчәч» көенә**, **«Салкын чишмә» көенә** һ.б.) һәм шушы әсәргә эпиграф итеп әлеге җырдан бер өзек китерә. Мәсәлән:

САБАНЧЫ КАРТ
(«БАШМАК» КӨЕНӘ)

Башмагымның башы башка,
Басмас идем, һай, вак ташка,
Алданамын башым яшькә,
Бирче, зинһар, башмагымны.

Бу — эпиграф булды.

Җырлыйм әле сузып-сузып,
Моңлы көйләр белән өзеп,
Һай, гомерем китте узып,
Яшь чагымда уйламыйча.
Карт булсам да мин, һаман да
Җырлап җибәрәм сабанда,
Түзми күңелем бу заманда
Җырламыйча, моңланмыйча.

Бусы — Ф.Туйкинның үз шигыре.

Шулай итеп, шагыйрь халык җыры белән үз әсәренең эчке рухы һәм моңының бердәй яки охшаш икәнлеген ассызыклый. Ул *«үз шигырьләрен халык җырлары ритмикасы һәм көйләренә салып иҗат итә, аларны халык җырлары традицияләре белән аерылгысыз бербөтен итеп бирергә тырыша»* [1: Б.48].

Халык җырларына ияреп язылган әсәрләренең шигъри формаларына тукталыйк. Биредә шактый кызыклы күренеш ачыла: шагыйрь урта гасырларда классик гарәп һәм фарсы поэзиясендә киң таралган күп кенә шигъри жанр формаларын, шул исәптән шактый катлаулыларын да яхшы белгән һәм аларны үз иҗатында иркен файдаланган. Мәсәлән, **мөрәббәгъ, мосаддас, мөсәммән, мостазад** кебекләре. Хәзер шул шигырь формаларын карап китик.

Әле генә телгә алган **«Сабанчы карт»** шигыре, мәсәлән, мөрәббәгъ формасында иҗат ителгән. Мөрәббәгъ — «дүртьюллык» дигән сүз, аның строфалары а-а-а-б, в-в-в-б, г-г-г-б рәвешендә рифмалаша. Халык җырларында бу форма еш кулланылган.

Фазыл Туйкин иҗатында үзенең туган ягы табигатенә сокланып, аны поэтик югарылыкка күтәреп, мәдхия җырлаган искиткеч лирик **«Ямьле җәй» («Зиләйлүк» көенә)** шигыре бар. Шунысы әһәмиятле, Галимҗан Ибраһимов та аңа зур бәя биргән: 1914 елда Ф.Туйкинның әлеге «Сабанчы карт» һәм «Ямьле җәй» шигырьләрен үзенең **«Яңа әдәбият»** исемле хрестоматиясенә керткән, ә хрестоматиянең икенче бүлеген шушы «Ямьле җәй» шигыре белән башлап

җибәргән. Бу шигырьләр турында **Г.Ибраһимов** болай яза: «Аның хрестоматиягә кергән «Сабанчы карт» һәм «Җәе» сыйныфта шәкерт кулына бирер өчен шундый гүзәл нәрсәләр ки, болар тузан арасында калган булса, мәшәкатенә карамый, эзләп алынырга тиешләр иде. Тукайның «Авыл»ы шәкерт кулына ничек рәхәтләнеп бирелсә, Туйкинның бу ике мәнзумәсе дә шул дәрәҗәдә сакланып, дәреслеккә кертерлектер» [2: Б.177]. Күренә ки, Г.Ибраһимов биредә Фазыл Туйкин шигырьләрен Тукай шигыре белән бер рәткә куеп чагыштыра, Тукай шигыре югарылыгындагы әсәр дип бәя бирә.

«Ямьле җәй» шигыренең эпиграфы дүртьюллык белән язылса да, а-б-б-б рифмасы кулланылган:

Биек кенә тауның итәгендә
Утыртып үстергән талым бар.
Кеше ярларында ни гамем бар,
Сандугачтан артык ярым бар.

Ә Фазыл Туйкин исә бу шигырьнең беренче ике строфасында а-а-а-б рифмасын куллана да, аннан соңгы строфаларны гадәти дүртьюллыклардагыча а-б-в-б рифмасы белән иҗат итә. Мәсәлән:

Идел буйларында киң болында,
Елкыларым утлый чабында,
Оҗмахларың торсын бер ягыңда,
Шул болында йөргән чагында.
Шунда инде менә төрле кошлар
Өзеп-өзеп кенә сайрыйлар.
Су өстендә йөзгән аккошлар да
Моңлы тавыш белән шаулыйлар.

Фазыл Туйкинның **«Урал тавына» («Ишан» көенә)** дигән шигыре дә мөрәббәгъ формасында язылган, анда а-а-б-а рифмасы кулланылган.

Ә менә **«Туган ил» («Күгәрчен» көенә)** шигырендә Ф.Туйкин Шәрыкның классик поэзиясендә шактый киң таралган мостазад формасының бер вариантын кулланган. Шигырьгә



эпиграф итеп түбәндәге халык җыры китерелә:

Сайрый ла сандугач баласы,
Сайрый алмый талсыз ла далада,
күгәрчен,
Үтә гомерләрең лә, сизәмсең?
Минем дә газиз яшь гомерем
Үтәр микән шулай ла заяга,
күгәрчен,
Үтә гомерләрең лә, сизәмсең?

Күренә ки, монда халкыбыз дүртьюллык шигырьнең икенче һәм дүртенче юлыннан соң **«Үтә гомерләрең лә, сизәмсең?»** дигән юлны кабатлап бара, ягъни рефрен куллана, шуның белән шигырьнең строфасын алты юллык ясый. Аңа икенче һәм бишенче юлларда **«күгәрчен»** рефрены да өстәлә.

Хәзер Фазыл Туйкинны тыңлап карыйк:

Сагынам туган-үскән илемне,
Әллә кай төшләре бик ямьле иде,
сөям дә,
Шул илемне уйлыймын да, көям дә.

Яшел болыннардан шаулап аккан
Сулары ла татлы һәм тәмле иде
бигрәк тә,
Шул су буйлары әле дә йөрәктә.

Күрәбез, Фазыл Туйкин да, халык иҗатындагыча, алты юллык строфалар белән яза. Ә ул алтыюллык ике өчьюллыктан тора, һәр өчьюллыкның икенче һәм өченче юллары үзара рифмалаша, беренче һәм дүртенче юллар рифмалашмый.

Бәян ителгән күзәтүләр безгә шагыйрьнең күп гасырлык халык җырлары, шигырь жанрлары һәм формалары өлкәсендә тирән белемле, рухи яктан бай булуын күрсәтеп тора.

Әле карап кителгән мисаллар Э.Ханнанова-Галимҗанова төзеп бастырган «Бертуган Туйкиннар» китабыннан алынды. Башкорт телендә М.Нәзерголов әзерләп чыгарган «Фазыл Туйкин. Ватан каһармандары» китабында шагыйрьнең шигърият өлкәсендәге мирасы тулырак бирелгән. Ф.Туйкинның шигъри әсәрләрен М.Нәзерголов «Шигырьләр» һәм «Җырлар» дигән ике бүлеккә туплап бирә. Бу китаптагы «Шигырьләр» бүлегендә Казан басмасында булмаган тагын унбер шигырь китерелә. Алар арасында шагыйрьнең кызы Бүләк Ибәтуллинадан алынган **«Мин — Фазыл»**, **«Кәрванчы»**, **«Ел әйләнәсе унике ай»**, **«Төзелер матур тормыш»** һәм Ф.Туйкинның 1920 елларда төзегән **«Җырлар җыентыгы»** дигән кульязма җыентыгыннан алынган **«Сәгать чылбыры»**, **«Ямьле Зәй»**, **«Зиндан»**, **«Әдип диләр»** һәм башка шигырьләре бар.

М.Нәзерголов китабындагы «Җырлар» бүлегендәге әсәрләргә махсус тукталырга кирәк. Анда барлыгы 76 җыр тексты китерелә. Әлеге китапка язган кереш сүзендә М.Нәзерголов: *«Үткәннәрне сагынып җырлаган чагында Ф.Туйкин үзенең замандаш каләмдәшләре С.Яхшыголов, Ф.Сөләйманов, Г.Исәнбирдиннәргә охшый башлый, аларның кайсыбер әсәрләрен искә төшерә. Аның аерым шигырьләре бигрәк тә Ф.Сөләйманов иҗат җимешләре белән аваздаш яңгырый. Хәтта юлга-юл, сүзгә-сүз тап килгән очраклар да бар»*, — дип күрсәтә һәм *«Әлбәттә, монда кемдер тарафыннан плагиатлык кылынган, дип уйларга ярамый. Замандаш әдипләр үз әсәрләрендә халкыбыз иҗатының бер үк үрнәкләрен файдаланганнар»*, — дип аңлатып китә [3: Б.10-11].

«Җырлар» бүлегендәге ун җыр тексты Казан басмасындагы кебек үк. Әмма калганнарының бер өлеше (7 текст) Ф.Туйкинның 1915 елда Уфада басылган **«Нардуган»** җыентыгыннан һәм күпчелек өлеше (54 текст) Ф.Туйкинның 1920 елларда төзеп калдырган «Җырлар җыентыгы» дигән кульязма китабыннан алынган. Атрибуция мәсьәләсенә аерым тукталып тормыйча (ул үзе бер зур тема), бары шушы соңгы 54 җыр тексты белән танышып чыкканнан соң туган иң беренче фикерләрем белән генә уртаклашам. Безнеңчә, бу текстларның барысын да Ф.Туйкин язмагандыр. Ул аларны халык арасыннан җыйган һәм бер җыентыкка туплап куйган булса кирәк. Ә халыкта бер үк көйгә җырлана торган текстның берничә варианты барлыкка килгән (халык авыз иҗатында бу — гадәти күренеш). Ф.Туйкин монда үзенә очраган нөсхәне теркәгән булырга тиеш. Биредә кителгән җыр текстларын 1972 елда Татарстан китап нәшриятында басылган **«Җырлар китабы»**ндагы (төзүчесе — **И.Надиров**) җыр текстлары белән чагыштырып чыкканда түбәндәге күзгә ташлана: бер үк җырны-көйне татар кавеме бертөрле сүзләр белән, ә башкорт кавеме, дала шартларында, икенче сүзләр белән җырлаган. Ә көй — бер булган! (Татар белән башкорт халкының бертуганлыгы нәкъ менә шушында күренә түгелме?!) Мисаллар китерик. **«Әллүки»**, **«Тәфтиләү»**,

«Зиләйлүк» җырлары, мәсәлән, безнең татарларда Г.Тукай сүзләренә җырланып йөри (1972 елгы «Җырлар китабы»нда Тукай сүзләре китерелә), ә башкортларда башка сүзләр белән җырлана («Ватан каһармандары» китабы, 56-57, 60, 64-65 битләр). Шулай ук **«Агыйдел»**, **«Таштугай»**, **«Уел»**, **«Мәдинәкәй»**, **«Күгәрчен»**, **«Сакмар»**, **«Эскадрон»**, **«Салкын чишмә»**, **«Сандугач»**, **«Таһир-Зөһрә»**, **«Зәңгәр шәл»**, **«Мәрфуга»**, **«Галиябану»**, **«Асылъяр»**, **«Тәзкирә»**, **«Саҗидә»**, **«Күбәләгем»** безнең татарларда бер төрле сүзләр белән җырланып йөрсә, Ф.Туйкинның 1920 еллардагы кулъязма «Җырлар җыентыгы»нда башка төрле сүзләр китерелә. Тагын: башкортлардагы **«Хафизәкәй»** җырының бер-ике юлы бездәге **«Хафизәләм иркәм»** җырына туры килә, ә калган өлешләре бөтенләй башка. Башкортлардагы **«Кара урман»** җыры нигездә безнең **«Иске кара урман»** җырына туры килә, әмма андагы текстта да үзгәрешләр бар. Шуңа күрә, «егерменче елларда төзеп калдырылган «Җырлар җыентыгы»ндагы текстларны Ф.Туйкин үзе язганмы, әллә халык арасыннан җыйганмы?» дигән сорауга «әлбәттә, ул аларны халыктан язып алган булырга тиеш» дип җавап кайтарырга тулы нигез бар.

Югарыда әйтелгәннәргә шуны да өстик: Г.Тукай да халык җырларын җыйган һәм 1910 елда Казанда **«Халык моңнары»** дигән китап бастырган. Ф.Туйкин да үзенең **«Җырлар әхтәрисе»** җыентыгын 1912 елда Казанда нәшер иткән. Икесе дә бер үк вакытта халык җәүһәрләрен җыйганнар һәм икесе дә китапларын **«Сабах»** нәшриятында бер үк елларда бастырганнар. Шушы фактка беренчеләрдән булып шагыйрә **Эльмира Шәрифуллина** игътибар итә. Ул болай яза: *«Г.Тукайның «Халык моңнары» дигән китабында басылган кайбер җырларның үзгә вариантлары Ф.Туйкин җыентыгына да кергән:*

Агыйделгә төшә яздым
Вак-вак кына таш өчен.
Хәйран башлар вәйран була
Кызның кыйгач кашы өчен.
(Г.Тукайда)

Ак Иделгә төшә яздым
Кул кисәге таш өчен.
Хәйран башым вәйран булды
Сез дусларым хакы өчен.
(Ф.Туйкинда)

«Җырлар әхтәрисе»ндә шулай ук Г.Тукай игътибар иткән, заманында ул җыйган җырлар да очрый. Димәк, халык җырларын туплау мәсьәләләрендә аларның карашлары бертөрлерәк булган, дип уйлый алабыз» [4: Б.168].

Инде нәтиҗә ясарга вакыт. Фазыл Туйкин гомер буе татар һәм башкорт җырларына гашыйк булып яшәгән, аларны яратып җыйган, туган халкына кайтарып бирергә дип җыентыклар төзегән. Һәм ул үзенең шигырьләрен, җыр текстларын да халык җырларыннан үрнәк алып, алардан азыкланып-кан алышып, шулар мисалында иҗат итәргә тырышкан. Шуңа күрә аның шигырьләре искиткеч халыкчан, ә җыр текстлары искиткеч моңлы һәм сагышлы — аларны халык җырларыннан аерып карап булмый. Халык җырлары аңа һәрвакыт илһам һәм оптимистик рух биреп торган. Аның җыр текстлары кендеге белән үк халык җырларына, милләт рухиятенә береккән.

Әдәбият

1. Бертуган Туйкиннар. Тарихи-документаль җыентык. / Төзүче-автор Эльмера Ханнанова-Галимҗанова. — Казан: Рухият, Җыен, 2007. — 592 б. — («Шәхесләребез» сериясе).
2. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. 5 том. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. — 177 бит.
3. Фазыл Туйкин. Ватан каһармандары. Шигырзар, йырзар, поэма, хикәйә һәм пьесалар./ Текстологик эштәрзе башкарыусы, төзөүсе, баш һүз языусы, аңлатмалар биреүсе филология фәндәре кандидаты Миңлегәли Нәзерголов — Өфө: Китап, 2007. — 200 б.
4. Шәрифуллина Э. Илебез — кадерле җиребез...// Казан утлары, 1977, №6. — 163-169 битләр.



«ҖАНДА УЛ БЕЗНЕҢ, ЙӨРӘКТӘ, БӘГЫРЬДӘ...»

Рифә Рахман

Татар теленең сагы күгендә мәңге сүнмәс йолдызлык бар. Анда Кол Галиләр, Кандалыйлар, Акмуллалар, Тукайлар, Такташлар янәшәсендә көч-куәте аларныкыннан һич кенә дә ким булмаган Хәсән Туфан атлы йолдыз да балкый. Ул, буыннардан-буыннарга күчеп килгән телебез сафлыгын, матурлыгын без дә сакларга тырыштык, инде милләтне яшәтү, сәнгатен үстерү, Тукайлар иҗат иткән ана телен югалтмау – сезнең бурыч, дип әйтә һәм шуның юлларын да яктырта сыман.

Хәсән Туфан тәхәллүсе белән әдәбият сәхифәләренә теркәлгән Хисбулла Фәхри улы Хәзрәтев – татар поэзиясенең классигы, журналист, педагог, репрессияләнгән каләм әһеле. Аны без, беренче чиратта, Такташ мәктәбенә, берара шулай ук аңа охшаш язган Нәҗмиләргә, Кутуйларга, Җәлилләргә дә якын тора дип саныйбыз. Такташ белән ике арада булган дуслыгына сокланабыз, Җәлилгә булган мөнәсәбәтен үрнәккә куябыз. Шул ук вакытта, киләчәктә бихисап шәкертләр тәрбияләгән Хәсән Туфанның шигырь мәктәбе иясе дәрәҗәсен йөртергә дә хакы барлыгын таныйбыз.

Яшь Туфан... Зур әдәби мәйданга кыю адымнар белән атлап кергән талантлы Туфан. Иҗат лабораториясендә төрле экспериментлар белән мавыккан, Такташлар, Маяковскийлар шигъриятенә мөкиббән Туфан. Мин яраткан, еш укыган шагыйрь ул.

Кызганыч, аның егерменче еллар иҗатын укучы аз белә, азрак укый, соңгы вакытта сәхнәләрдән ул әсәрләр бөтенләй яңгырамый. Язганнарының күләмлелеге дә тискәре эшен эшли торгандыр. Ләкин икенче сәбәп тә бар. Репрессияләнгән Туфан иҗаты ныграк пропагандалана. Укучы әсәрне авторның тормыш юлы белән бәйләргә күнеккәнне дә онытмыйк. Аны «корбанга китерелгән» кешенең авыр шартларда үзен ничек тотуы, югалтуларга ничек түзүе, кичерешләренең иҗатында ничек чагылуы күбрәк кызыксындыра. Ул кызганырга, лирик «мин» белән бергә яшь түгәргә ярата. Бу вакытта шагыйрь белән дә ныграк якыная сыман.

Кайбер татар галимнәре, Хәсән Туфан утызынчы еллар башыннан шигъриятендә лиризмны көчәйтә бара, халык җыр традицияләренә таба борыла, дип белдерсәләр дә, килешмим. Традицион калыпларны күпмедер куллануына карамастан, шигырьләренең рухы егерменче еллардагы әсәрләрдән әллә ни аерылмый әле. Хәсән Туфан шигъриятендә традициялелек, асылда, кырыгынчы еллар башыннан ныгый һәм Тукай мәктәбе чалымнары инде күзгә ташланырлык күләмдә күренә башлый. Хәсән Туфан үзенең рухына туры килгән һәм заман фикерен ирештерергә зуррак мөмкинлек биргән иркле үлчәмнәрдә язудан да туктамый.

Хәсән Туфан һәм Габдулла Тукай иҗаты арасындагы якынлык теге яки бу фикерне чагылдыру өчен сайланган калыпларда түгел, аны образлар мәйданының тәңгәллеге, кисешүе дип тә билгеләп булмый. Хәсән Туфан шигъриятенә дә, Тукайныкына да, композиция бөтенлеге һәм эчтәлек тирәнлеге, идея ачыклыгы, актив гражданлык позициясе хас. Ахыр чиктә, Туфанның Тукайны үзенә үрнәккә куюы бу бәйләнешләрне раслый.

Әле әйдаман каләмдәшләре кебек, Маяковскийлар юл салган поэзия сукмакларыннан атлаган чакта да Хәсән Туфан Тукайны олылыклавын, аны укуын, аннан фикерләр алуын укучыга ирештерү юлларын таба. 1935 елны иҗат ителгән «Ант» поэмасының «Син басып торасың» бүлекчәсен Тукайның «...Ни сәбәптән җир йөзендә / Тәңгә — мунча, җанга — юк» дигән юлларын эпиграфка куеп башлый. Аның Сталин сүзләре («...Дөнья борынборыннан шулай төзелеп килде...») белән ачылган бүлеккә урнаштырылуы чорның ике шәхесе арасында диалог тудыруга хезмәт итә, авторның Тукайны әлегә үзе иң табынган кеше — Сталин янәшәсендә торырлык зат итеп тануын да күрсәтә.

Сүз уңаеннан шуны да әйтим: беренче курста укыганда, Хәсән Туфан архивын тәртипкә китерә башла әле дип, мине аның мирасы сакланган йортка җибәргәннәр иде. Шулчакта сөргендә ятканда да төсле кара белән саргайган кәгазь кисәкләренә шигырь сырлап, Сталинга дан җырлаган Туфан мине таң калдырды. Кульязмаларда укыган шигырьләремнең барысы да әле бүгенгә кадәр чыккан китапларда күренмәде шикелле, һәрхәлдә ул әсәрләрнең минем күзгә чалынганы юк. Гаҗәпләнеп булмый. Архив белән күпләр шөгыльләнде. Бу эш башланды да ташланды. Башланды да ташланды. Беренче курс студентына хуҗабикә бик ышанып карамагандыр инде, мине яңадан чакырмады.

Хәсән Туфан сугышкача язылган икенче бер күләмле әсәрендә — «Тукайның туганы»нда да рухи остазы темасына кагылып уза. Сугыштан соң да бу затлы исем шигырьләрендә әледән-әле күренгәли. Бигрәк тә туган тел, аның бүгенге язмышы хакында язганда, ул аны искә төшермичә кала алмый.

Хәсән Туфан совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары (1970, 1980), ә «Сайланма әсәрләр»е өчен (1964) 1966 елда Татарстан Республикасының



Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнә. Хәсән Туфанның бу мәртәбәле бүләкне йөртергә хаклылыгын иҗатында Тукай темасы зур урын алып тору да күрсәтә. Шагыйрьнең аңа карата бәясе һәрчак зур, ул йөрәгендә Тукайны йөртүе турында башкаларга да ишеттерергә тели, аны «алтын» дип атый:

Түшемдә генәмени ул —
Мәңгелек өлкән Тукай?!
Җанда ул безнең, йөрәктә,
Бәгырьдә — алтын Тукай!
(«Түшемдә Тукай»)

Хәсән Туфанның Тукай турындагы әсәрләреннән халыкка иң билгелесе, мәктәп программасына да кертелгәне — «Чәчәкләр китерегез Тукайга». Шигырьне Фоат Галимуллин укуында «Шигърият бакчасында» фонохрестоматиясеннән һәм 5-11 сыйныфлар өчен чыккан «Татар әдәбияты дәресләренә фонохрестоматия»нең икенче дискыннан тыңларга мөмкин. Әлеге әсәрдә автор Тукайга «туган ил ихтирамын» һәйкәленә китерелгән гөлләр аша чагылдырырга чакыра, бу мөнәсәбәтнең ел әйләнә булуын тели:

Без чәчәкләр аша тапшырырга
Тиеш тә бит сиңа сәламне...
Ел буена тик бер генә тапкыр
Күрәсең син, Тукай, аларны.

«Тукайга һәйкәл...»дә лирик «мин» чәчәкләрне Тукайның Зәйтүнәсе исеменнән китерә:

...Синең күк нәфис
Чәчкәне бирдем.
Чәчкәне биреп
Әйттем эчемнән:
«Зәйтүнәң кебек
Гүзәл сеңелдән!..»

Тукайның «Бар иде ялгыз калып җырлап утырган чакларым...» юлларына нигезләнеп язылган «Тукай тавышын эзләгәндә» әсәрендә, асылда, шагыйрь илнең чын талантларга, сәнгать әсәрләренә карата гаделсез мөнәсәбәтенә, чор җәүһәрләрен киләчәк буыннарга тапшыру эшенә салкын каравына борчыла. Шул ук вакытта ул тудырган лирик герой Тукай исеменең халык күңелендә мәңге

сакланачагына да ышана:

«Халык гомере — мәңгелек», —
диләр,
Бу — сыналган, тугры сүз бугай.
Килер гасырларның аръягын да
Илең белән бергә уз, Тукай!
(«Һаман шулай, даһи егет
хәлдә...»)

«Без һаман бергә» шигырендә дә шушы фикер башкачарак кабатлана:

Халык гомере мәңгелек, диләр,
Ә син, Тукай, халык куенында;
Илең белән мәңге бергә син
Мәңгелекнең олы юлында!

Вафатыннан соң басылган «Гүзәл гамь» китабы Хәсән Туфанның Тукай турындагы шигырьләре янына яңаларын өстәде. Бу җыентыкта Тукай исеме бигрәк тә сәяси темаларны («Гасыр үтәр, бәлки, чорлар үтәр...») ачканда килеп керә. Әлбәттә, аларда милләт фаҗигасе, әдәбият югалтулары янәшәсендә, шәхси трагедия дә бар («Тукай залы»). Хәсән Туфанның совет чорында басылмаган әсәрләренең шактыена, шул исәптән, Тукай турындагыларына да («Тукайлар, Бабичлар, Такташлар, Мусалар...») фикерне асмәгънә рәвешендә җиткерү хас. Мәсәлән, «Тукай» (1949) дүртьюллыгы:

Яшь иде: утыз җиденче
Елларда әле бары
Илле бер яшьтә генә ил
Каршылар иде аны...

Без текстттан милләт өчен янган Шагыйрь утызынчы еллар репрессияләренә барыбер эләгер иде, чөнки әле актив тормыш алып барган ир булыр иде, дигән мәгънә аңлыйбыз. Шул ук вакытта Хәсән Туфан, бәлки, утыз җиденче ел аның гомеренә барыбер чик куяр иде, ди кебек.

Югарыда аталган әсәргә аваздаш 1934 елны язган «Исән булсаң...»да Тукайның ил сайлаган юлдан канәгать булачагына шулай ук асмәгънә, күпнокта белән шик белдергән була. Бу вакытта башка шигырьләрендә Хәсән Туфан ил сәясәтенә дан җырлый, аның ирешкәннәре белән горурлана югыйсә! Без инде канлы елларда Тукайның да фикерен ым, керфек кагып кына ирештерә алачагын күрәбез.

Туфан Тукайны үзенә якын булган Такташ янәшәсендә еш искә ала. Шуннан чыгып, күңеле белән Тукайны да ни дәрәҗәдә рухи дусты, остазы санаганлыгын аңларга мөмкин. «Гүзәл гамь» җыентыгындагы «Син үзең әйт»тә «бер карт» «исән улларыннан» — «мәрхүм»нәренә (Тукайга, Такташка) гөлләр илтә. «Матәм»дәге лирик «мин» Тукайны ил картының «олы улы» дип атый. Монда сүз гомумиләштерелгән «ил уллары» һәм шул көрәшчеләрдән булган шагыйрьләргә халык мәхәббәте турында бара.

Хәсән Туфан кайберәүләрнең милләт язмышына, ана теле язмышына («Тукай абый туган телне...», «Алмаз») битарафлыгын тәнкыйтьләгәндә, шул телне яшәтергә тиешле каләмдәшләрен дә шигырь белән кәсеп итүне алга куйганнары өчен чеметеп узганда («Дене өчен генә яши торган...», «Кемгә дә, тиенгә дә...»), гыйльми сукырлыкны, битарафлыкны фаш иткәндә («Альенделар үтерелгән көндә») Тукай сүзләрен, аның яшәү мәсләген искә төшерә.

Шагыйрь шигъри сүзнең ана телебез сагында торуына, үзенең иҗатта уникум булуына гомер бакый ышана. Юкка гына болай дип язмый:

Тукайлар, Ямашевларның
Дәвамы итеп санап,
Тик шундый иман нурында
Яшәве безгә ансат.

Безне дә халык яратыр,
Сөйгәндәй Ямашларын,
Кимендә теле, сүзе бар,
Үзлеге бар ич аның. ■



АЧЫ ТӘҖРИБӘ АВАЗЫ

Габдулла Тукай

III

● Валлаһи, җандай күрәм мин искеләрнең җырларын, күкрәгемдә саклыйм әйтерсең рәсүлнең тырнагын.

● Халык җырлары — безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр. Әйе, бу — кадерле мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмур[46] Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады. Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә... Халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен дә, аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска иҗтиһат итәргә кирәк.

● Белергә кирәк ки, халык җырлары — халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер. Бу — бер төрле сихерле көзгедер. Чөнки халыкның бер генә җыруын тотып нечкәләсәң, шөбһәсез, аның халәте рухиясен, нәрсә уйлаганын вә ни хакында нинди фикердә икәнен белеп буладыр.

● Халык җырларына әһәмият бирергә кирәк, дип кат-кат әйтелде инде. Ни өчен әһәмият бирергә кирәк? Шуның өчен ки, чын халык телен, чын халык рухын безгә тик халык җыруларыннан гына табып була.

● Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем. Мәдрәсәдә хәлфәләр, кече атна кичләрдә, бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә дә мине онытмыйлар иде. Мин, самавыр артына гына утырып, алар кушкан көйләрне җырлап бирә идем, шул җырлавым бәрабәренә хәлфәләрдән берәр уч симәнкә һәдия[47] кыйлына иде... Мәдрәсәдүк мине җырчы диләр иде. Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәкемнән миндә туган телемезне сөю тугъды. Әгәр миңа җырулар ярдәм итмәсә, ...туган телемезне сөймәк кеби бер олуг нигъмәткә малик[48] була алыр идемме?!

***

● Минем исемдә калган: мәдрәсәдә ...бер җырлаучы, үзенең иренен каты кәгазь сыярлык итеп кенә ачып, озын вә кыска көйләрне җырлап җибәрә иде... Безнең бер көйне руслар арасында бик яхшы тавышлы саналган бер кешедән җырлатсаң, әллә ничек, шуның безнең күңелгә ошарына күңел ышанмый. Көемезнең алтынын кояр шикелле тоела.

● Безнең халыкның җырлау вә көйләвендә, минемчә, үзенә бер төрле хосусият бар кеби. Башка милләтләрдә булдыгы кеби, бездә калын тавыш илә вә мөмкин кадәр көчләнеп вә авызны

Дәвамы. Башы журналның 2014 елгы 9 нчы санында.

бик зур итеп ачып җырлау бер дә мәкъбүл түгел[49].

● Халык каршында җен теле төсле ят телләр илә мөнбәргә менеп җырлауны изге эш дип, әдәбият ахшамындагы халыкның ана теле илә шул ук мөнбәрдәге сүзләрне шамил булган[50] шигырьләрне яман дип, кыек күз берлә карамаска кирәктер.

● Халыкка дәрсе гыйбрәттер — театр, күңелдә йоклаган дәртне уятыр. Театр яктылыкка, нурга илтә, кире юлга җибәрми, уңга илтә.

● Татар кардәшләремез милли музыка вә җырулар тавышын ишеткәндә: «Ах, Дәҗҗал чыккан икән инде!» — дип, мич башына менеп, колакларына мамык тыгып, күзләрен бәйләп, өстләренә дә 9 кабат юрган, 5 кабат толып ябынып, «Кяһәф» сүрәсе укып ятмаска тиештер.

● Граммофонда татар җырлары... Тынычлыкны боза анын әче тавышы, килә аннан, бер тыңласаң, мәче тавышы; бер тыңласаң, чинау килә; бер тыңласаң — майламаган арба тәгәрмәче тавышы!

● Зинага чакыра торган музыка хәрәм булса да, алга китәргә, тәрәккыйгә чакыра торган музыка мөстәхәб[51], хәтта ваҗиб[52] уктыр.

***

● Гөл кадерен былбыл белер, асылташ кадерен — белгече.

● Чәчмәгән җир кук — күңелнең һәр гүзәлгә бушлыгы, тик кояшны һәм табигатьне сөюдән хушлыгы!

● Һәр чәчәк — сеңлең, апаң; абзаң — үсеп торган агач.

● Һәрбер кош үз тавышы белән ләззәтләнә.

● Барча кошның да үзенчә сайравы бар, шигыре бар.

● Җырлагыз сез күңелегезгә Тәңре нәрсә салганын.

IV

● Мин, ахрысы, сөюдә дә милләтче... Мин татар кызының телен, сөйләшү рәвешен яратам.

● Син үзең (хур кызы. — *З.М.*) һәрвакыт изге, хөрмәтле... Гүзәлсең син, матурсың син, матурсың, матурларның матурыннан матурсың. Гүзәлсең син, зөбәрҗәтсең, асыл ташсың... Күркәмлегең, дөрес, һәртөрле мактауга лаек, шулай да Җир кызы синнән сөеклерәк.

● Наз итәр кемнәргә гөл — каршында былбыл булмаса?

● Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә[53] дөнья бәһа; ул болай бер кыз гына — каршында Мәҗнүн булмаса.

● Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы.

● Сөюнең мәгънәсе... бигүк гали, бигүк нечкә.

● Мин кечкенә чагымда малайлар белән алма бакчасы тирәсенә бара идем. Миннән бүтән малайлар алманы коялар һәм урлыйлар иде. Әмма мин һичбер данәсенә тимидер идем. Бакчачы, минем яхшылыгымны белгәнгә, ул алманы миңа үзе бирәдер иде. Мин шул «үзе биргән» алманы, урлаган алманы ашап торган малайлар алдында: «Менә үзе бирде!» — дип, мәгърурланып ашыйдыр идем. Мин әле кызлар тугърысында да шул ук мөгамәләдә. Бер кыз, үзе танышырга теләп, миңа яучы җибәрмәсә, мин һичвакыт танышырга эзләп, ваксынып йөрмим. Әмма үзе кул бирсә, тагы да: «Үзе бирде», — дип горурланам, кадерлим ул кулны!

● Бик юашлатты мине яшерен сөюдән җан көю, бар иде булган чагым хәтта арысланнан кыю!

---

[46] Мәгъмур — төзек;
[47] Һәдия - бүләк;
[48] Малик булу — ия булу;
[49] Мәкъбүл түгел — килешми;
[50] Шамил булу — үз эченә алу;
[51] Мөстәхәб — гүзәл эш;
[52] Ваҗиб — мәҗбүри эш;
[53] Мәхбүбә — сөелгән хатын-кыз;

Текстны басмага ***Зиннур Мансуров*** *әзерләде.* ■

АТНАБАЙ КАНАТЫ АСТЫНДА

Марат Кәбиров

Әнгам Атнабаев әдәбиятыбызның йөзек кашы, халкыбызның үз шагыйре иде. Әдәбиятчыларыбыз, галимнәребез аның тормыш юлын да, иҗат үзенчәлекләрен дә җентекләп өйрәнер әле. Бу хакта җитди хезмәтләр барлыкка килер. Мин әлеге язмамда ул кадәр тирәнлекләрне ачуга дәгъва итмим. Сүз монда, гомумән, Әнгам Атнабаевның үзе турында түгел. Сүз аның үзеннән башка да хәрәкәт итә торган көч – Атнабай рухы турында бара.

Фикердәшләр «Өмет» газетасы редакциясендә. Сулдан уңга, утырганнар: Тамьян Бикмаев, Әнгам Атнабаев. Басканнар: Марат Кәбиров, Рамил Миннәхмәтов, Ратмир Әхияров. Уфа. 1995 еллар тирәсе

1. БАРЫБЕР, МОЛОДЕЦ!

Әгәр бүген берәрсе: «Атнабай иҗаты белән кайчан таныштың?» — дип сораса, төгәл җавап бирә алыр идем микән? Юктыр. Мин аны бу дөньяга килгәнче үк белгәнмендер, Атнабай шигырьләре ана суты белән җаныма сеңгәндер кебек. Бездә аны нык яраталар иде шул. Бер сыйныф белеме булмаса да, җыр-моңга, әдәбиятка мөкиббән киткән дәү әнием озын-озын дастаннарны яттан белә иде. Тукай әсәрләренә гашыйк иде

ул. Һәм, әлбәттә, Атнабайга. «Кара икмәк», «Кешегә нәрсә җитми» кебек шигырьләрен хәтердән сөйләр дә: «Эх, шушы баланы бер генә күреп, аркаларыннан сөйсәң иде!» — дип куяр иде. Гомер буе терлекчелектә эшләгән әнием дә Атнабай шигырьләренә мөкиббән кеше. Менә шушы мохит миндә Атнабай иҗатына кызыксыну уятты да инде. Әле укырга да бармаган малай, танавымны тарта-тарта, авыл клубында урнашкан китапханәгә килдем: «Миңа Әнгам Атнабаевның берәр китабы кирәк иде». Китапханәче сәерсенеп карап торды да, елмайгандай итте: «Үскәнем, син, беренчедән, укый белмисеңдер, икенчедән, андый әйберләр бездә озак ятмый. Әнә теге апаларың урлап бетерәләр».

Башны түбән иеп кайтып китүдән гайре чара калмады. Шулай да, мин Атнабай шигырьләрен уку бәхетенә ирештем. Бер дустым бар иде. Беркемгә дә сөйләмәскә ант иттергәннән соң, серемне чиштем:

— Уфада Әнгам Атнабаев дигән шагыйрь бар икән. Китаплары да бар икән. Давай, берәр китабын сорап хат язабыз! Бәлки, җибәрер?

Дустымның күзе шар булды:

— Ә син яза беләсеңме соң?!

Мин яза белми идем. Тагын башымны ияргә мәҗбүр булдым. Ләкин дустым озак кайгырырга ирек бирмәде:

— Минем апада бар аның китабы. Юка гына үзе. Урларга да җайлы.

Мәсьәлә шуның белән хәл ителде. Икенче көнне «Йөрәгем юллары» дигән җыентыгы кулымда иде инде. Хәзер китап бар-барын. Ләкин укып булмый. Әнием өйрәткән хәрефләр запасы гына моңа мөмкинлек бирми.

Әлегәчә кәнфит биргәннәре өчен генә «Әлифба» актарып маташкан малай берзаман үзе теләп хәреф өйрәнергә тотынмасынмы! Беренче сыйныфка барганда Әнгам Атнабаевның берничә шигырен яттан белә идем инде. Һәм моның белән чиксез горурлана идем.

Берсендә шундый хәл булды. Бишенчедә укыганда, «иртәгә, Октябрь бәйрәменә багышланган концертта шушы шигырьне сөйләрсең» дип, Хәниф Кәримнең «Ленин һәйкәле» дигән шигырен бирделәр. Бик авыр ятладым. Шулай да, «интонация белән» сөйләрлек дәрәҗәгә җиткердем. Концерт башланды. Минем чират. Исемемне игълан иттеләр. Сәхнәгә чыгып бастым. Бастым да... каттым. «Ничек башлана иде соң әле?!» Көннәр буе интектергән, йөзәр кабат укылган шигырь искә төшми генә бит. Исемен дә хәтерли алмыйм. Зал көтә, халык көтә. Ә мин газапланам. Күңелдә — яттан белгән шигырьләр парады. Тик берсен дә тотып укып булмый. Алан-йолан карангалап алам. Укытучым сәхнә артында нәрсәдер пышылдый, ләкин мин аны ишетерлек дәрәҗәдә түгел. Сәхнәдән йөгереп чыгып китәсем, инде түземлеге бетеп, алкышлый башлаган халыкны кайдадыр олактырасым килә. Кузгалырлык та көч юк. Нишләргә?

Шулчак һәрвакыт хәтеремдә йөргән бер шигырьне укырга тотынам:

Мин беркөнне кинәт үлеп киттем,
Шундый рәхәт, шундый күңелле...

Зал тын. Югары пафослы, патриотик шигырь көткән халык авызын ера биребрәк миңа төбәлгән.

Хәтта хатын мактый, эчмәгәнмен,
Гүләйт итмәгәнмен, уңганмын.
Алтын кебек кеше булганмын бит,
Үлеп кенә харап булганмын...

Бот буедай малайның Октябрь бәйрәмендә шундый шигырь сөйләп торуын күз алдына китерегез әле! Зал шаулатып кул чаба. Зал тәгәрәп ятып көлә...

Сәхнәдән чыгуга, япь-яшь сыйныф җитәкчесе (яңа укып кайткан гына иде әле ул) мине ачуланырга тотына:

— Яндырдың бит син мине!.. Харап иттең бит...

Үзе шундук кочаклап ала:

— Барыбер, молодец! Барыбер, молодец!

Ни өчендер, укытучымның шушы сүзләре хәтергә нык сеңеп калган. Юньлерәк әсәр язганда, сизелерлек ялгышлар эшләп ташласам да, үземне «Барыбер, молодец!» дип юатам. Бәләкәй чакта Атнабай китапларын урлаганда тотылгалаган да булды. Яхшы ук тиргәделәр дә. Ә мин «барыбер, молодец»...

Мин генәме соң әле! Кеше малына кул сузу түгел, кырын да карамаган әнием дә «молодец». Сиксәненче еллар башында ул «Янган тау» шифаханәсенә ял итәргә барды. Шулвакытта (колхозчы, димә инде!) кибеттән кирза итек алган. Бүлмәгә кайткач, кияргә итеп караса... балтыр эченнән бер төргәк акча килеп чыккан. Унике мең! Укымышлырак кеше булса, бәлки, Аллаһы Тәгаләгә һәм коммунистлар партиясенә рәхмәт әйтеп, күктән төшкән байлыкны чемоданына тыгып кына куяр иде. Әни, гади авыл хатыны, тиенենә кадәр кибеткә кире илтеп биргән. Бу турыда нигә язып утыраммы? Унике меңнән баш тарткан әни шифаханә китапханәсеннән Әнгам Атнабаевның ике китабын урлап алып кайтты! Миңа шуннан да зуррак бүләк юк иде. Бу хакта уйласам да, теге «гыйбарә» искә төшә: «барыбер, молодец!»

2. ТӘҮГЕ ДӘРЕС

Шул рәвешле миңа шигырь йокты, Атнабайлык йокты. Үземчә, бер-ике генә строфалык нәрсәләр маташтырган булам. Ярыйсы гына килеп чыккандай. Мин үземне бик зур кеше итеп тойганмын, күрәсең — мәхәббәт, тормыш-көнкүреш, сугыш турында язганмын. Соңгыларына Муса Җәлил иҗаты йогынты ясагандыр. Чөнки ул минем өчен батырлык символы иде.

Көннәрдән бер көнне мин иҗат җимешләремне газета-журналларга җибәрергә уйладым. Юк, үз исемемне басмада күрер өчен генә түгел... Күршеләрнең миннән бер генә яшькә зуррак кызлары бар. Гашыйк булырга кайчан өлгергәнмендер, хәтерләмим, әмма авылда бер туй уздырылганда: «Тукта! Көтеп тор, мин дә сиңа өйләнәм!» — дип, шул кыз артыннан йөгергәнемне халык хәтсез вакыт кызык итеп сөйләде. Миңа ул чакта биш яшь чамасы идеме икән? Шуңа да: «Беренче шигырегезне кайчан яздыгыз?» — дигән сорауга: «Биш яшемдә. Күрше кызына гашыйк булгач», — дип җаваплыйм икән, бу — дөреслектән мәхрүм түгел.

Мәктәптә укыганда «отличник»ларга ел саен мактау кәгазе, грамота бирәләр. «Сөйгәнем» дә — отличница. Минем дә грамота аласым, «мәхәббәтемә» тиң буласым килә. Тик чирек ахырында йә берәр «дүртле», йә «өчле» чыга да, барлык бүләкләрдән коры калам. Читен. Көтмәгәндә бер кызга «Пионер» журналыннан грамота килеп төште. Рәсемнәр конкурсында катнашып, беренче урын алган. Грамотасы шәп, матур! Мактау кәгазьләре моның янында пүчтәк кенә. Бөтен мәктәп алдында зурлап тапшырдылар. Озак итеп кул чаптык. Мин чәмләнеп киттем һәм шигырьләрне бер-бер артлы матбугатка җибәрә башладым. «Кызыл таң»га, «Совет Башкортстаны»на... Исәбем — дәрәҗәлерәк газетадан дәрәҗәлерәк грамота алу.

Шигырьләр беркая да күренмәгән иде әле. Көннәрнең берендә «Совет Башкортстаны»нан зур конверт килеп төште. Эчендә катыркага охшаш нәрсәсе дә бар. Күңелгә рәхәт җылылык йөгерде. Һәм шундук диярлек үкенеч уянды: «Ә нигә мәктәпкә җибәрмәделәр икән?! Бөтен мәктәп алдында тапшырмагач, бу грамотаның ни хаҗәте бар инде?..» Әмма тагын җан юатырлык уй ялтлап китте: «Ә мин аны район үзәгенә баргач, яңа конвертка салып, мәктәп адресына юллармын. Тапшырсыннар, зурлап! Заслужил!»

Конвертны эченнән, чыннан да, бер катыргы чыкты. Язылу-абу-

нә буенча реклама кәгазе икән. Һәм... гади кәгазь битенә машинкада басылган хат. «Хөрмәтле Марат Кәбиров иптәш! Хатыгызны алдык. Каләмегез бар. Ләкин шигырьләрегез әлегә гәзиттә бастырырлык түгел. Күңелегезне төшермәгез, язышып торыгыз. Гәзитебезгә авыл тормышын чагылдырган мәкаләләр, үткен телле фельетоннар бик кирәк...»

Бернинди грамота да юк.

Мондый хатлар башка редакцияләрдән дә килде. Шуннан соң мин беркайчан да, бер газетага да шигырь җибәрмәскә булдым.

Җиденче сыйныфта укыганда әдәбият укытучысы булып Рәшидә апа Шәмсетдинова килде. Ул әдәби түгәрәк ачып җибәрде. Рәшидә апа үзе дә шигырьләр яза, әсәрләре әллә никадәр газета-журналда басылган, әллә никадәр язучы белән күзгә-күз карап сөйләшкән кеше. Хәтта Әнгам Атнабаевны да күргәне бар икән. Еракта, әлбәттә...

Озакламый ул минем шигырьләрне сорап йөдәтә башлады. Ә мин бирергә ашыкмыйм. Беренчедән, яшь укытучы кызлар безнең өчен әллә ни «апа» булып күренми инде. Шаяртасы, ялындырасы, һәрвакыт игътибар үзәгендә буласы килә. Икенчедән, теге хатлар яхшы сабак бирде. Өстәвенә, шигырьләремнең бигүк өлгереп җитмәгәнлеген үзем дә чамалап торам.

Сигезенчене тәмамлап, җәйге каникулга чыккач, «Башкортстан пионеры» газетасында бер шәлкем шигырьләр дөнья күрде. Рәшидә апаның баш сүзе белән. Язмаларны әнидән сорап алган икән. Шул ук җәйдә ул мине район газетасында эшләп йөргән шагыйрь Ринат Хәйри белән таныштырды.

Үрге Яркәй һөнәрчелек училищесында укыганда мин Ринат абый белән еш очраша идем. Сөйләшәбез. Үземне борчыган сораулар белән башын катырып бетерәм. Шигырьләремне күрсәтәм. Ул киңәшләр бирә...

Көннәрнең берендә Ринат абый миңа Әнгам Атнабаевның визит карточкасын тоттырды. Үзе мыек астыннан елмая. Карточка артындагы язуга күз салгач, елмаюының сәбәбе дә ачыкланды. Анда: «Марат! Шушы адрес белән шигырьләреңне җибәр. Шушы адрес белән килеп кер. Ә.Атнабай», — дип язылган иде.

Мин, әлбәттә, анда тиз генә барып керә алмадым. Ни өчендер шигырьләрне дә җибәрмичә калдым.

1987 елның 23-26 мартында Республиканың яшь язучылар семинары үтте. Ринат абыйның хәстәрлеге белән анда без фәкыйрегез дә эләкте. Һәм... Вәт, могҗиза! Вәт, әкәмәт! Семинарның яртысы диярлек минем шигырьләргә багышланып китте. Шәриф Биккол, Тимер Йосыпов, Асылгужа Багуманов кебек шагыйрьләрнең мактау сүзләре башны әйләндерерлек иде. Тик, ни сәбәптер, моңа артык нык шатланмадым, нибары «чынлап шулай шәп язам микәнни?» дип гаҗәпләндем генә. Куанычның зурысы — семинарга килгән яшьтәшләрем белән аралашу булды. Мин аларның күбесен «Башкортстан пионеры» аша укып белә идем.

«Башкортстан пионеры»нда эшләгән шагыйрә Зөһрә апа Котлыгилдина мине семинардан соң редакциягә алып китте. Шунда Әнгам Атнабаев белән таныштырырга тәкъдим итмәсенме! (Зөһрә апа, гомумән, миңа зур таяныч булды. Акыллы киңәшләре, җылы карашы, кайгыртучанлыгы белән үзүземә ышаныч уятканы өчен әле дә рәхмәт укыйм. Ләкин бу игелекләрнең берсен дә кылмыйча, Атнабай белән очраштырып-күрештереп чикләнсә дә, мин аңа мәңге бурычлы булыр идем.)

Без «Һәнәк» журналының бер бүлмәсенә кергәндә, шагыйрь үзендә түгел иде, аз гына көтәргә туры килде. Менә килеп керде. Әнгам Атнабаев! Үзе!.. Озын буйлы. Салмак кына, дәрәҗәсен белеп кенә атлый... Беренче карашка ул бик тә кырыс, бик тә тәкәббер,



үтә дә җитди булып тоелды. Мин, әле Язучылар берлеге идарәсендә генә «яңа ачылган талант», «әдәбиятның киләчәге», аның янында бермә-бер кечерәеп калдым. Юньле-рәтле исәнләшә дә алмадым шикелле. Ул нәрсәдер сөйли башлады. Карале, тавышы шундый ягымлы икән бит! Нәрсәгәдер көлешеп алдылар. Көлүе дә җанга ятышлы икән.

— Ничек язасың соң?

Миңа эндәшә ләбаса! Күтәрелеп карадым: алдымда искиткеч ягымлы һәм бик тәгади кеше тора иде. Кыюланып киттем.

— Ничек инде?

— Язмый торала сыңмы? — Атнабайның күзләре ялтырый, иреннәре елмаерга әзерләнеп бөрелгән... Мыек астыннан көлү эталоны!

— Язылганда язам инде... — дидем мин.

— Илһам килсә, язабыз, дисеңме?..

Ул Толстой турында сөйләп алды. Тәмләп кенә, сүз кадерен белеп кенә сүтә бу.

Толстой үзе янына килгән бер яшь язучыдан: «Язмый торала сыңмы?» — дип сораган. Тегесе: «Торалам», — дип җаваплагач, әйткән бу: «Алайса, бөтенләй язма!» — дигән.

— Әгәр язмый торалмыйсың икән, әгәр үзеңдә көч, сәләт сизәсең икән — яз. Бу эшеңне ташлама. Язучы өчен иң мөһиме — күпне күрә белү. Язучының үз биографиясе, үз географиясе булырга тиеш. Әсәр тормыштан алынырга тиеш. Әсәр тормышка кагылырга тиеш. Шул очракта гына ул озын гомерле була.

Редакциягә җибәрелгән беренче шигырьләрем уңышсызлыкка очрагач, мин әдәбият гыйлеменә кагылышлы бик күп китаплар укыдым. Башкортчасын да, татарчасын да, урысчасын да. Алар белән соңыннан университетта гына очрашырга туры килде. Әлбәттә, яхшы китаплар иде алар, күп нәрсәгә өйрәттеләр. Тик Әнгам Атнабаев әйткән әлеге сүзләр миңа бөтенләй бүтән яссылыкны ачарга ярдәм итте. Язучының үз биографиясе булырга тиеш! Бу инде: «Син нәкъ үзеңчә, җаның кушканча яшә. Хаталан, адаш, дөрес юлны эзлә. Син безгә нәкъ үзеңнеке генә булган ялгышың, үзеңнеке генә булган табышың, үзеңнеке генә булган язмышың белән кадерле. Чөнки бары тик шунда гына син башка беркем дә язмаган әсәрләр иҗат итә алачаксың», — дигән сүз. Бу инде...

Әлеге очрашу Әнгам Атнабаевтан алыначак әдәбият дәресләренең беренчесе иде.

Ахыры киләсе санда ■

ӘДИП АВЫЛЫ

ФӘТХИ БУРНАШ ЯКТЫЛЫГЫ

Нәкыйп Каштанов

Күренекле язучы, драматург, әдәбият тәнкыйтьчесе, журналист, җәмәгать эшлеклесе Фәтхи (Фәтхелислам) Бурнаш 1898 елның 13 (1) гыйнварында Сембер губернасы Буа өязе Кыр-Бикшик авылында дин әһелләре гаиләсендә дөньяга килә. Туган ягының әкияти матурлыгы белән хозурланып, Түгәрәк кизләү суын эчеп, Зирекле, Бола елгалары буенда уйнап үсә.

Кыр-Бикшик авылы күренеше (Азау кизләве)

Архив язмаларыннан күренгәнчә, бу авылны 1647 елда егерме дүрт йомышлы татар нигезләгән. Аларга биредә җир бүлеп бирелгән. Җан башыннан салым алынган. Абрейка Сатлаев (1705-1765) дигән йомышлы татар турында документлар да сакланып калган.

Кыр-Бикшикнең әүвәл — Казан, соңрак Сембер губернасына каравы, Буа өязенең Шыгырдан волостена керүе мәгълүм. Совет хакимияте урнашып, автономияле республикалар оеша башлагач, Буа кантонына караган берничә волость, шул исәптән Шыгырдан да, Чувашстанга тапшырыла.

Белгәнебезчә, ул елларда имам, мөәзин, мөгаллимнәр авылның зыялыларыннан саналган, ә муллалык буыннан-буынга күчкән. Фәтхелисламның әтисе — Мөхәммәтзакир хәзрәт (1845 елда туган). Мөхәммәтзакирның әтисе — Абделхәким (1809). Абделхәкимнең әтисе — Вәлит (1772). Вәлитнең әтисе Аит Баймөхәммәт улының (1738) тамырлары Бурнаш кенәз нәселенә барып тоташа. Алар барысы да указлы имам була.

Фәтхинең әнисе Гайнелхәятнең (Шыгырдан кызы) әтисе дә Мөхәммәтзакир (1823) исемле. Аның әтисе — Сөйфелмөлек (1791). Сәйфелмөлекнең әтисе — Габдессәлам (1736). Болар һәммәсе дә имамнар. Габдессәламнең әтисе — Махмун (Мәхмүт) Бихайкин — морза.

Әнием Майсәрвәр (Маһисәрвәр) Каштанованың нәсел җепләре Вәлит хәзрәтнең җәмәгате Хәбибәгә (морза Сәләй Сүлиевнең оныгы, 1780 еда туган) килеп ялгана.

Сембер губернаторының 1884 елгы хисабыннан күренгәнчә, Кыр-Бикшиктә мәктәп эшләгән. Фәтхелисламның башлангыч белемне үз әти-әнисеннән дә, мәктәптә дә алу мөмкинлеге булган.

1907 елны Мөхәммәтзакир абзый уллары Фәтхелислам белән Вафаны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә урнаштыра. Булачак язучы шулвакыттан шәһри Казанда төпләнеп кала.

Вафа Бурнаш. XX гасыр башы

Авыл борын-борыннан игенчелек, сәүдә эше, һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Тормыш бигүк җиңел булмаган. Һәр гаиләдә дистәләгән бала үскән. Төрле реформалар, сугышлар кешеләрне тагын да бөлгенлеккә төшергән. Имам хәзрәтләр авыл халкы, башкача әйтсәк, мәхәллә тәрбиясендә яшәгән. Дәүләт дин әһелләренә берниндиярдәм күрсәтмәгән.

Мөхәммәтзакир хәзрәтнең гаиләсе дә авыр шартларда гомер кичергән, күрәсең. Аның Идел елгасы буйлап Әстерханга кадәр бурлак булып җигелүе мәгълүм. (Фәтхелислам да шәкерт чагында казакъ далаларында укыта, ярминкәдә пешекче ярдәмчесе сыйфатында акча эшли.)

Бурнаш мәдрәсәдә белем эстәгәндә үк «Сәйяр» труппасы егетләре белән таныша, энесе Вафаны ияртеп, спектакльләргә йөри, тамаша кыла. Нәкый Исәнбәт катнашында берничә кулъязма әдәби-сатирик журнал чыгаралар. Фәтхи күп укый. Аеруча Шекспирны, урыс язучыларын ярата. 1914 елның 15 (2) апрелендә шәкертләр «Мөхәммәдия»дә Габдулла Тукай истәлегенә мәрасим үткәрә. Фәтхи,

Фәтхи Бурнашның әнисе Гайнелхәят. 1930 еллар

оештыручы буларак, нотык сөйли. Бу турыда хәбәр тиз арада җитәкчеләргә барып ирешә, Бурнаш җәбергә тарый һәм, нәтиҗәдә, 1915 елны мәдрәсәне ташлап китәргә мәҗбүр була. Бер елдан соң, үзлегеннән хәзерләнеп, учительская семинариядә имтихан тота, «диплом» ала, шуннан соң, күпмедер вакыт мөгаллимлек итә.

Габдулла Кариев белән дуслыгы көннән-көн ныгый бара. Бурнаш 1914 елда урыс язучысы С.А.Найденовның «Ванюшин балалары» драмасын сәхнәгә куярлык итеп татар теленә аудара. «Сәйяр» труппасы аны озакламый куя да. Фәтхине хезмәтенең җимешен күрү канатландырып җибәрә һәм ул унҗиде яшьтә (!) баштанаяк драматургиягә кереп китә, бер-бер артлы «Язмыш» (1914), «Сукбай» (1915), «Саташкан кыз» (1916) кебек әсәрләр яза. Шул ук вакытта тәүге шигырь-поэмаларын тудыра башлый, алар «Аң» журналында басылып чыга.

Бурнаш Февраль түнтәрелешеннән соң — 1917 елның маенда — солдатка алына. Сентябрьгә кадәр Сембердә хезмәт итә, ләкин фронтка җибәрелми, укытучылыгы өчен азат ителә. Шуннан соң әдип Буада һәм Сембердә татар теле

Хөршид (Фәтхи Бурнашның апасы) гаиләсе белән. 1930 еллар

белән әдәбияты буенча дәресләр бирә.

Фәтхи Октябрь инкыйлабы дулкынында «Яшь йөрәкләр» пьесасын яза... Илдә буталчыклык хөкем сөрә, Гражданнар сугышы бара, язучы да бу хәлләрдән читтә кала алмый. Ул 1918 елның 28 маенда Казаннан Сембергә китә, анда барып урнашуга, кыска вакыт эчендә газета оештырып җибәрә. Гафуров исемле дусты белән бергә педагогик курслар ача. 23 июльдә ак чехлар Сембергә бәреп керә... Редакция Уфага күченә. Әмма 5 августта аларны кулга алалар. Кызыллар бу вакытта Бөгелмәдә була инде. Аклар Уфаны калдыра. Фәтхи Бурнаш 25 октябрьдә, тоткыннарны бер урыннан икенче урынга күчергән вакытта, бер станциядә кача. 28 ноябрьдә Сембердә аның имзасы белән «Көн» газетасы чыга башлый.

Берсендә Фәтхи Бурнаш белән киңәшләшергә (әдипнең Буада чагы туры килсә кирәк) авылдашлары җайдак озата: баксаң, сугышка дип җыйган егетләрне Буага китергәннәр

Фәтхи Бурнаш нигезендәге мәчет һәм язучы утыртып калдырган тупыл. Язмыш җилләре агачны да һәрь яктан сыный, имгәтә, сындыра. Әмма ул барыбер исән кала, тернәкләнә, яңарып китә...

икән дә хәзер акларга кушмакчылар икән. Кызыллар ерак түгел — Ибрәс станциясенә (Чувашстан) җиткән инде. Нишләргә? Кыр-Бикшикнең Сабир исемле кешесе, авыл бае кыяфәтенә кереп, «иген урырга кирәк» дигән хәйлә табып, тиешле кешесенә ришвәт биреп (күмәкләшеп акча җыялар), «сөлекләрне» кире алып кайтып китә. Икесенең суга киткән чагы туры килә. Алар аклар белән бергә югала. Бу вакыйгадан күренә ки: авылдашлары да Фәтхи аганы хөрмәт иткән, кыен чакларда киңәшен ишетүне хуп санаган.

Әдип Сембердә дәртләнеп эшли, «Көн» газетасын «Таң» дип үзгәртәләр, аның оста оештыручы, публицист, шагыйрь дигән даны тарала.

Озакламый Үзәк мөселман хәрби коллегиясе Фәтхи Бурнашны «Кызыл Армия» газетасына баш мөхәррир итеп чакыра (политбүлек мөдире Шамил Усманов телеграмма арты телеграмма юллый). Язучы 1920 елның 11 маенда Казанга килә.

Фәтхи ага гаять җаваплы гамәлләр башкаруына, җәмәгать эшләрендә кайнап яшәвенә карамастан («Татарстан», «Безнең байрак» газеталарын җитәкли, «Чаян» журналын оештырып, аның беренче баш мөхәррире була, Татар академия театры директоры вазифасын били һ.б.), киңкырлы иҗат өчен дә вакыт таба: Александр Пушкинның «Евгений Онегин», Николай Островскийның «Корыч ничек чыныкты», Максим Горькийның «Ана», Лев Толстойның «Хаҗи Морат» әсәрләрен тәрҗемә итә, опера либреттолары, хикәяләр, публицистик мәкаләләр яза.

Бурнашның тормыш юлына кагылышлы булып та күпчелек халыкка нәмәгълүм вакыйгалар бар[1]: мәсәлән, утызынчы елларда Фәтхи ага җан дусты Салих Сәйдәшевне ияртеп Буага кайта, алар биредә татар театры оештыра, спектакльләр куя, үзләре дә төрле рольләрдә уйный. Кыр-Бикшиктә дә булалар. Авыл картлары сөйләве буенча, Зирекле елгасы буйларында йөриләр, урманга, Каенсарга ял итәргә баралар.

[1] Фәтхи Бурнашның нәсел җепләре турындагы мәгълүмат та беренче мәртәбә басыла, бу — Кыр-Бикшиктә дөньяга килгән һәм Фәтхи Бурнашка чыбык очы туган булган авторның шәхси архивында җыелган материаллар.

Кыр-Бикшиктә гомер-гомергә гыйлемгә хирыс халык яшәгән. Биредә туып-үскән имам-хәзрәтләр үзендә генә түгел (бездә өч мәчет икәнен хәтергә алыйк), күрше-тирә авылларда да халыкка хезмәт күрсәткән. Әйтик, Чичканда Зәмдихан карт (дүртенче буын бабам) имам булып торган. Ул үзе — Абделкәрим хәзрәтнең оныгы. Тимәштә Фәтхи Бурнашның әтисе Мөхәммәтзакирның бертуганы Шәкүр хәзрәт имамлык иткән. Вольнистанда (Үти Чатказы) — Мәхмүт хәзрәт. Соңрак аны улы Нургали алыштырган, икенче улы Сабирҗан исә Кече Чынлыга чакырылган. Бертуган Мостафа һәм Садыйк Гаженовлар Томскида урнашып, анда иман тараткан.

Авылыбызның өч мәчетендә дә дин гыйлеме өйрәтелә. Икенче мәчеттә Хәмидулла хәзрәтнең хатыны Камилә абыстай кызлар укыта. Камилә — Зәмдихан оныгы. Өченче тау мәчетендәге имам — Әхмәтсафа Бурнашев — Фәтхинең беренче анадан туган абыйсы. Хәйретдин мөәзин — Зәмдиханның улы. Беренче мәчеттә Әхмәтзәки Бурнашев имам, ул да сөекле язучыбызның абыйсы. Указлы мөәзин Арифулла Алим улы — Зәмдихан хәзрәтнең оныгы. Арифулланың хатыны — Мөхәммәтзакир кызы, ягъни Бурнашның беренче анадан туган апасы. Хәйретдин бабайның җәмәгате Алимә әби — Татар Согыты имамы кызы. Ул да илле ел инде кызларга белем өләшә.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган чакта Фәтхи үзләренең йорты янына тупыл үсентесе төртә. Шул йөзьяшәр агач, сырхау булса да, әлегәчә һәр язда яфрак ярып, хуш ис таратып, һәр җәйдә бөдрәләнеп, шау яшеллектә утыра. Бездә Фәтхи Бурнаш урамы бар. Мәктәп музее да аңа бәйле истәлекләр саклый. Уку йорты үзе дә Фәтхи Бурнаш исемен йөртә.

Авылдашларым дөньяга мәшһүр каләм иясен биргән гаиләнең бик зур җимеш бакчалары булуын да хәтерли әле. Өйләренең арткы ишеге шунда чыккан. Гайнелхәят абыстай (Фәтхелисламның әнисе) хасталарны дәвалау белән дә шөгыльләнгән.

Мөхәммәтзакирның вафатыннан соң нигездә аның улы Әхмәтзәки хәзрәт төпләнеп кала, ләкин шомлы елларда, репрессиянең ни-нәрсәләргә китерәчәген чамалап, Мәскәүгә күченә. Әхмәтсафа хәзрәт исә үлем машинасыннан качып котыла алмый, Серов шәһәре зинданында ачтан үлә. Әниләре Гайнелхәятне улы Вафа Казанга алып китеп тәрбия кыла. Ул Татар зиратында җирләнгән.

Казан медицина институтының элеккеге доценты Дилбәр Вафа кызының сөйләгәне бар: бервакыт ул пианинода (Фәтхи Бурнашның Алманиядә эшләнгән пианиносы!) ниндидер урысча көй уйнап утыра икән, ишектән гаилә дусты Салих Сәйдәшев килеп керә дә, «Ник татарча уйнамыйсың?» — дип сорый. Дилбәр: «Ноталар юк бит», — дип җавап кайтара. Күренекле композитор аңа шундук «Әпипә»нең ноталарын язып бирә…

Ә Фәтхи Бурнашның язмышы бик аянычлы тәмамлана. Ул да, абыйсы Әхмәтсафа кебек, репрессия корбаны була. Аны 1942 елда атып үтерәләр.

***

Татар милләтенең затлы шәхесләре гаять катлаулы заманда яшәп тә, үз халкы өчен биниһая зур, гасырлар тузаны да күммәслек сәнгати мирас калдырган. Галим Азат Әхмәдуллин Фәтхи Бурнашның иҗатын биш томга туплап, китап итеп бастырырга әзерләгән. Алар арасында — егерме ике драма әсәре генә! Тамашачы «Яшь йөрәкләр»не бүген дә аягүрә торып алкышлый… Утыздан артык поэма, ике йөзләп шигырь, биш опера либреттосы, биш йөзләп публицистик мәкалә һәм әдәби рецензияләр авторы да ул.

Шуңа күрә, Фәтхи Бурнаш яктылыгы Кыр-Бикшик, Татарстан һәм бөтен татар дөньясы күген әле озын-озак балкытыр, иншаллаһ! ■

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

Сәхифәне филология фәннәре докторы, профессор ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

НОГМАН Мостафа (Мостафа Ногман улы Ногманов; 1912-1976), шагыйрь, тел галиме, педагог. Күпсанлы шигырьләр, популяр җырлар, поэмалар авторы. Әдәби мирасында бөек әдипкә багышланган әсәрләрдән иң билгелесе — «Апрель таңы» — Тукайны шагыйрьлек баскычының иң югары биеклегенә күтәрә. Ул аның иҗатыннан «Азмы какканны вә сукканны / Күтәрдең, син — ятим / Җырладың шуңа халкыңның / Моң тулы хиссиятен» һәм киң даирәләргә мәгълүм булган кайбер башка цитаталарны трансформацияләү юлы белән иҗат ителгән. М.Ногман текстыннан Тукай әсәрләренең мелодиясе, ритмы, шигъри үлчәме, иң мөһиме — лексик катламы һәркемгә ачык тоемлана. Автор, Тукай белән диалог коргандай, риторик рәвештә куйган сорауларына җавап биргәндәй яза. М.Ногман, Тукайның «Өзелгән өмид»енә каршы зур горурлык белән һәм бер үк вакытта юаткандай, күңелен үсендергәндәй: «Тынмый сазың, моңлы сазың, / Кем тыя алсын аны?! / Син яшәрсең, мең яшәрсең, / Син — шагыйрьләр солтаны!» — дип белдерә. Шагыйрьнең Тукайга мөнәсәбәтле икенче атаклы ядкаре — «Иделләр буйлап» циклына кергән «Тукай пароходында» шигыре («Таң йолдызы»). Анда борынгыда булган хәл — Тукайның Уфага баруы һәм яр буена аны каршыларга М.Гафуриның килүе җанландырыла. М. Ногманның бу әсәрне иҗат итүенә, әлеге вакыйгадан соң озак еллар узгач, лирик геройның нәкъ менә «Тукай» пароходында Агыйделгә агып керергә, Тукай узган юлны үз күзе белән күрергә теләве, ә юлчыларны портта «Гафури» пароходының каршы алуы сәбәп булып тора. Циклның «Күптән-күптән...» шигырендә исә Г.Тукайның Кырлайдагы кечкенә вакыты, шигырьләрендә чагылыш тапкан кайбер мизгелләр, шул исәптән, балаларның яңгыр явып узганнан соңгы уеннары тасвирлана. Габдулла иптәш малайлары белән чабыша, гөрләвектә көймә агыза. Автор кечкенә Апуш агызган көймәчек детален аның исемен йөрткән зәңгәр пароход образына китереп тоташтыра («Акчарлаклар оча Иделдә» китабына «Зәңгәр пароход» исеме белән кергән). М.Ногман сугыш вакытында язган «Илһам чишмәсе»нә эпиграф сыйфатында Г.Тукайның «Мәхәббәт» әсәренең тәүге юлларын куя, әмма аның илһам чыганагы хакындагы фикерен заман шартларына, сугыш вакыйгаларына бәйле үзгәртә — чын шагыйрь өчен солдат булу, дошманны җиңү, юк итүнең дә иҗатка теләк тудыра алуын күрсәтә. Бу текстта Г.Тукай һәм Такташ иҗатына хас стиль, алар иҗатында яңгыраган кайбер фикерләр бергә үрелгән кебек.

Әсәр.: Ногман М. Давыллы еллар лирикасы. К., 1944. Б.15-18; аныкылар. Таң йолдызы. К., 1959. Б.5-10, 16; Акчарлаклар оча Иделдә. К., 1982. Б.29, 72.
Әдәб.: Мәҗитов З. Җырлап яшәүче шагыйрь// Мостафа Ногман. Иртәнге җырлар: җырлар, шигырьләр, поэмалар. К., 1973. Б.3-6.

Р. Харрасова

ҺАВАДАГЫ ТОРНА

Кулымда – вакыт саргайткан, еллар тузанын йоткан кәгазьләр. Дөресрәге, тарихи елъязмалар...
Беркетмә – тавышсыз магнитофон. Эшлекле сөйләшүләрне, кайнар бәхәсләрне, шапырынуларны, тәнкыйтьләрне – һәммәсен үзенә сеңдергән.
Укыйм (бу беркетмәнең бер өлеше турында язма заманында «Идел» журналының тәүге санында дөнья күргән иде)...

12 август, 1969 ел.
Татарстан Язучылар союзы
идарәсенең чираттагы утырышы.

Катнашалар:

Ибраһим Гази, Афзал Шамов, Мирсәй Әмир, Валерий Синев, Әхмәт Исхак, Гази Кашшаф, Сибгат Хәким, Хатип Госман, Гариф Ахунов, Ләбибә Ихсанова, Илдар Юзеев, Риза Ишморат, Ибраһим Нуруллин, Фатих Хөсни, Лирон Хәмидуллин, Зәки Нури, Хәсән Туфан, Гамил Афзал, Марс Шабаев, архитектор Зиннуров.

Председатель – Ибраһим Гази.

Шулай итеп...

Көн тәртибендә:

1. Язучылар йорты проектын карау.
2. Балалар әдәбиятына багышланган җыелышка докладчылар билгеләү.
3. Үзбәк әдәбияты декадасы йомгаклары.
4. 1970 елда РСФСРда үткәреләчәк татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре турында.
5. «Казан утлары» журналының чираттагы саннарын тикшерергә кешеләр билгеләү.
6. Муса Җәлил премиясенә кандидатлар тәкъдим итү.
7. Фаил Шәфигуллинны Язучылар союзына әгъза итеп алу.
8. Оештыру мәсьәләләре.

Тыңланды:

Беренче көн тәртибе буенча архитектор иптәш Зиннуров сөйли.

Иптәш ЗИННУРОВ. Язучылар йорты Карл Маркс һәм Комлев (хәзерге Мөштәри) урамнары чатында худфонд бинасы белән бер ансамбль тәшкил итәргә тиеш! Каршысында – бассейнлы сквер һәм балалар кинотеатры булачак (ошбу җөмләне укыгач, нигәдер, «Сиксәненче елдан коммунизмда яши башлаячакбыз!» дигән «канатлы сүзләр» искә төште. – *Л.Л.*)

Йорт үзе, нигез этажы белән исәпләгәндә, 4 катлы, тыштан карагандa – өч катлы. Тимер-бетон, кирпеч һәм пыяладан салынырга тиеш.

Нигез этажында (ярым подвалда) 100 кешелек ресторан, бильярд бүлмәсе

Ибраһим Нуруллин


Хәсән Туфан

Мирсәй Әмир

(80 м^2) ишегалды ягында складлар, ике машиналык гараж күздә тотыла.

Беренче этажда 365 урынлы зур тамаша залы (ике этаж биеклегендә), иркен фойе, 60 урынлы конференц-зал, 10 мең томлык китапханә, уку залы белән яңадан 3 бүлмә һәм санузел.

Икенче этажда кунаклар өчен холл, Союз аппараты өчен эш бүлмәләре, иҗат бүлмәләре — барлыгы 9 бүлмә.

Өченче этажда «Казан утлары» һәм «Идел» (бу сүзнең астына сызылган. — *Л.Л.*) журналы редакцияләре.

Фикер алышулар башлана.

Ибраһим НУРУЛЛИН. Әдәби музей юкмы?

Җавап (архитектор иптәш **ЗИННУРОВ**). Юк. Музей башка урында булырга тиеш.

Ибраһим ГАЗИ. Милли колориты булырмы? Нәкъ менә татар язучылары йорты икәне күренеп торсын иде.

Иптәш ЗИННУРОВ. Анысы инде эскиз-проект раслангач хәл ителәчәк.

Ресторан хакында кайнар бәхәс китә. Ниһаять, «кереп-чыгып йөрергә аерым ишеге булса, ресторан кирәк», дигән фикергә киләләр.

Чү! Хәсән Туфан сүз ала.

Хәсән ТУФАН. Яңа проект миңа ошамый. Мин хәзерге республика китапханәсе бинасын үзебезгә сорарга тәкъдим итәм. Бер комиссия барып карасын иде аны.

Гомәр Бәширов та Хәсән Туфан фикерен куәтли.

Яңадан бәхәсләр.

Ибраһим ГАЗИ. Безнең өчен бик кечкенә ул. Иске. Аны яңадан үзгәртеп кора башласаң, матурлыгы да калмый, акча да күп китәчәк.

Мирсәй ӘМИР. Ни стиле, ни уңайлыгы юк. Ярамый ул безгә, иптәшләр.

Проект тавышка куела: 12 язучы — риза, 1 әдип — каршы (Хәсән Туфан), 1 аксакал — бер якка да кушылмады (Гомәр Бәширов). (Алты каләм әһеле, димәк, идарә әгъзасы булмаган. — *Л. Л.*)

Карар кылынды:

Язучылар йорты проектын «ярый» дип кабул итәргә. Ресторан өчен урам яктан икенче ишек тә булдырырга.

Искәрмә:

Әлеге дүрт катлы «җәннәт сарае»н Карл Маркс һәм Комлев (Мөштәри) урамнары чатыннан, көндез чыра ян-

Гариф Ахунов һәм Гомәр Бәширов

Ибраһим Гази

дырып эзләсәң дә табалмыйсың бүген. Юк ул. Булмады да. Булмаячак та. Бассейнлы сквер да, балалар кинотеатры да юк.

Кайчандыр (1986 елның яз башларында булса кирәк) Туфан Миңнуллин тырышлыгы белән алынган, берничә ел элек кенә менә дигән итеп төзекләндерелгән Татарстан Язучылар йорты бүгенге көндә Мөштәри урамында (14 нче йорт) урнашкан. Мөштәри урамындагы әлеге йортка узган гасырның башларында нигез салынган. Аның төп хуҗасы — Оконишинков дигән купец булган, диләр. (Заманында бу бинада «Идел» белән «Салават күпере» журналханәләре эшләде. — *Л.Л.)*

Идарә утырышы дәвам итә. Икенче көн тәртибе буенча сентябрьнең уникеләрендә булачак җыелышка докладчылар билгеләү турында Ибраһим Гази белдерү ясый...

Карар кылынды:

Балалар әдәбияты мәсьәләләренә багышланган җыелышка докладчылар итеп түбәндәге иптәшләрне билгеләргә.

1. Шәүкәт Галиев — поэзия.
2. Шамил Рәкыйпов — проза.
3. Туфан Миңнуллин — драматургия.
4. Хәмзә Зарипов — нәниләр.
5. Разил Вәлиев — поэзия.

Өченче көн тәртибе:

Үзбәк әдәбияты декадасы йомгаклары турында Гариф Ахунов белдерү ясады. Өлкә комитетына рәхмәте зур. Үзбәкләрдән бик җылы телеграмма килде. Шул уңай белән бер фикер туды: кунакларны алып барырга ял базабыз юк. Займище белән Обсерватория арасында буш җир бар. Шуннан бер гектар аласы иде.

Карар кылынды: ял базасы өчен участок сорарга.

Дүртенче көн тәртибе:

Мәскәүдә һәм РСФСР шәһәрләрендә үткәреләчәк әдәбият-сәнгать хакында Марс Шабаев белдерү ясады.

Карар кылынды:

Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәрен декада итеп үткәрергә. 10 көн сорарга.

Вакыты: 1970 елның май ае.

Маршруты: Волгоград, Куйбышев (хәзерге Самара), Мәскәү.

Язучылар саны: 15-20 кеше. Составын, кемнәр икәнен соңыннанрак билгеләргә. Нәшрият белән элемтәдә булып, бүләк китаплар (М.Җәлил, Г.Тукай, Г.Ибраһимов) чыгарырга.

Бишенче көн тәртибе:

«Казан утлары»ның 5-8 саннарына күзәтүчеләр билгеләү. И.Гази белдерү ясый.

Карар кылынды:

1. Зәет Мәҗитов — поэзия.

2. Кыям Миңлебаев — проза, тәрҗемә.

3. Нурихан Фәттах — проза.

4. Мәдинә Маликова — тәнкыйть.

Алтынчы көн тәртибе:

Муса Җәлил премиясенә кандидатлар билгеләү. Ибраһим Гази Шәйхи Маннурның «Муса» романын тәкъдим итте.

Карар кылынды:

1969 ел өчен республика күләмендәге Муса Җәлил премиясенә Шәйхи Маннурның «Муса» романын тәкъдим итәргә. (Бу көн тәртибендә берни аңлашылмый: Шәйхи Маннурның ни Г.Тукай, ни М.Җәлил пермияләре юк. 1969, гомумән, М.Җәлил бүләге бирелә торган ел булмый. Ул ике елга бер генә тапшырыла (1968, 1970...) — *Л.Л.*)

Җиденче көн тәртибе:

Фаил Шәфигуллинны Язучылар союзына кабул итү. Марс Шабаев документлар белән таныштыра. Хәсән Туфан, Нәби Дәүли рекомендацияләре укыла.

Зәки НУРИ. Рекомендация бирүче буларак, шуны әйтәсе килә: мин Фаил Шәфигуллинны күптәннән беләм. Бик үзенчәлекле, сәләтле язучы. Тормышның эченнән килә. Совет кешесе — гражданин турында җырлый Фаил. Үзе дә эшче. Шәһәр советы депутаты. Читтән торып университетта укый. Киләчәге зур аның. Һич икеләнүсез кабул итәргә кирәк.

Гомәр БӘШИРОВ. Без кабул итү комиссиясендә Фаил Шәфигуллин хакында бәхәсләшеп тә тормадык. Ул Союзга керергә күптән җитлеккән. Ике китабы чыккан. Һәр икесе — чын әсәрләр. Рәхәтләнеп тәкъдим итәм.



Марс Шабаев

Афзал ШАМОВ. Нинди әсәрләр язасың?

Җавап (Фаил ШӘФИГУЛЛИН): Яңа шигырьләр китабымны нәшриятка тапшырдым. В.И.Ленинның 100 еллыгына поэма язам хәзер.

Карар кылынды:

Яшерен тавыш бирү юлы белән бертавыштан Язучылар союзына әгъза итеп кабул ителә.

Сигезенче көн тәртибе:

Оештыру мәсьәләләре.

1. Фатих Хөсни яңа повесть язу өчен Мөслимгә бер айлык иҗат командировкасы сорый.

Карар кылынды:

Язучы Фатих Хөснигә яңа повесть язу өчен Мөслим районына бер айлык иҗат командировкасы бирергә. <...>

Язучылар союзы идарәсе
председателе **Ибраһим Гази**
Җаваплы секретарь өчен
Марс Шабаев (имза).

Редакциядән: *беркетмәнең стиле, язу тәртибе, орфографиясе оригиналдагыча калдырылды.*

Ләбиб Лерон әзерләде. ■

Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакировка – 80 яшь

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ИЛҺАМ

Минтимер Шәймиев

Мин һәрвакыт татар халкы олы талантларга бик бай дип куанам. Әдәбият, сәнгатьнең һәр өлкәсендә безнең гүзәл йолдызларыбыз бар. Ә Илһам — алар арасында да илаһи таланты белән балкып торган йолдызларның йолдызы. Ул гасырларга бер генә туа торган, тулы мәгънәсендә мәшһүр халык җырчысы.

Нәкый Исәнбәт

Татар җырчылык тарихында үзенә аерым эз һәм мәктәп тудыра алган җырчыларыбыз, баксаң, күп түгел. Шулар арасында халыкта аеруча зур мәхәббәт һәм дан казанганы, әлбәттә, Илһам Шакиров.

Сибгат Хәким

Илһам Шакиров — чын талант, халык улы. Тукай исән булса, башыннан сыйпар иде аның.

Гомәр Бәширов

Язмыш татарга Муса Җәлил, Абдулла Алиш кебек батыр йөрәкле пәһлеваннарны бүләк иткән икән, нигә ул халыкның күңел түрендәге тирән моңын җыр белән әйтеп бирүче үзенә хас, үзенчәлекле талантлар белән дә куандырмасын икән! Илһам Шакиров — әнә шундый сирәк пәйда була торган ифрат үзенчәлекле зур талантларның берсе.

Мостай Кәрим

Илһам Шакиров җыр сәнгатендә үзе бер дәвер, дисәм, һич кенә дә арттыру булмас. Миңа чаклы да күпләр әйткәндер, моннан соң да әйтерләр. Шакировлы дәвер... Илһамлы дәвер...

Илдар Юзеев

Даһи табигать тудырган
Гасырлар Илһамы син,
Җыр дәүләтенең ханы син,
Халкыбызның җаны син.
Татар мең яшәде инде,
Алла бирсә, гел яшәр!
Җырда Илһамнар хан булса,
Җирдә ханнар Илһам булса,
Моң яшәр һәм мең яшәр. ■

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

«ДӨМБЕР КАРЧЫК ЙОРТЫ» *тар.* – Иске Казанда гадәттә татар бәндәсе тоткан фәхешханә, сәфаләтханә, тәтәйләр йорты. Г.Тукай «Дөмбер карчык»ның гомере «дөмбердәп» үткән, исеме шуннан килә, дип фараз итә. Икенче бер шигырендә («Казан вә Кабан арты», 1912) Г.Тукай фәхешханә тоткан карчыкны әкияти убырлы карчыкка тиңли һәм: *«Ул өй алдында хисапсыз, ди, имеш, кыз түшкәсе, Мөслимә, ди, барчасы, юк бер генә Катюшкасы»,* – дип яза. Автор фахишәләрдән Рабигә, Гайшә, Мәрьям исемнәрен телгә ала, ихтимал, бу исемнәрнең чын ияләре дә булгандыр (мәс., шәкертләр җырында телгә алынган «җылы куенлы җырчы Мәрьям туташ»?). Без мондый фәхешханәләрдә үзенә бертөрле «дөмбер туе» үткән, дип фараз итә алабыз.

Рус законнары буенча фахишәлек (проституция) 1649 елда ук тыелган була. Ләкин 1843 елда фахишәлек «түзәрлек» (русча – «терпимая») нәрсә дип игълан ителә һәм Петербургта, Мәскәүдә, Варшавада, Казанда һәм башка шәһәрләрдә фахишәләрне ачыклау, теркәү һәм медицина тикшерүе аша үткәрү өчен махсус табиб-полиция комитетлары булдырыла. Рус телендәге «публичный дом» һәм «дом терпимости» дигән атамалар шулвакыттан калган. Закон фахишәлек кәсебен җенси азгынлыктан һәм никахсыз бәйләнешләрдән катгый аерган.

Ф.Әмирхан сүзләренә караганда, XX гасыр башларында Казанда уннан артык татар фәхешханәсе булган. Ркаил Зәйдулла рус телендә язучы татар әдибе Гадел Хаировның «Суконкин сын» әсәре буенча китергән мәгълүматларга караганда, XX гасыр башларында Казан шәһәрендә 17 фәхешханә булып, аларда 330 фахишә «хезмәт иткән», шуларның 282се марҗа, 29ы ләх хатыны, 19ы нимес хатыны, 2се яһүдә, 1се татар хатыны булган. Ләкин шуны искәртик, монда татар бистәләрендәге фәхешханәләр исәпкә алынмаган. Кеше аңламасын өчен татарлар фәхешханәне *җиңгәчи* яки *мәхәл* дип кенә атаганнар («мәхәл» – [теге] җир мәгънәсендә). Фәхишәләрдән һәм фәхешханә тотучылардан «Кәҗә Маһи», «Подвал Фатыйма», «Этле Хөсни», «Кәмали» (бусы Уфада) кушаматлары билгеле. Аларның үзләрен дә *тәтәй* дип атау булган: *«Тәтәйләргә бик күп йөрсәң, Актык туның сатарсың»,* дигәннәр. Телдә «тәтәйләр рәте» дигән сүз йөргән.

* Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә. Автор искәрткәнчә, «...бу сүзлекнең чирек өлеше 2007 елда «Мәгариф» нәшрияты тарафыннан 1000 данәлек тираж белән бастырып чыгарылган иде».

Югары Ослан «туташы»ның «сары билеты»

Г.Тукайда тагын «Прахуд Мәзүб» дигән кушамат очрый. Бу фахишә ахырда, *«Казан муллалары һәм бер татар гәзитәсенең фатихаи хәйриясе бәрәкәтендә сихере кайтарылып, «тәүфыйклы» хатынга әйләнгән һәм эчми-тартмый торган татар сәүдәгәренә кияүгә чыккан»*, имеш.

XX гасыр башында арзанлы фәхешханәгә 20 тиенгә керергә мөмкин булган, ә «аруырак» фәхешханәләргә визит 1-2 сумга төшкән, диләр.

Җиңгәчи кызларының ачы язмышы Сәгыйть Рәмиевнең «Галәветдин хаҗи корбаны — Җаек Хәдичә» хикәясендә тасвирлана. Ризаэддин Фәхреддиннең «Әсма яки гамәл вә җәза» романында да татар кызларының фахишәлек баткагына ничек килеп эләгүләре турында шактый мәгълүмат бар.

Фәхешханәләрнең узган гасыр азакларында ук инде Казанда гына түгел, Төркестанда да тамыр җибәргәнлеге Заһир Бигиевкә Сәмәрканд сәүдәгәре Хөсәенов Гани бай әйткән сүзләрдән билгеле. Ул Төркестан мөселманнарында исерткеч эчүнең таралуы, картлар-яшьләрнең башларына чалма ураган килеш фәхешханәләргә барып, кәеф-сафа сөреп кайтуын бик борчылып сөйләгән.

Патша Россиясе заманында фахишәләргә сары кәгазьгә басылган паспорт («сары билет») бирә торган булганнар.

Җаһилият чорында гарәпләрдә фахишәлек бик зур гаеп саналмаган. Мәшһүр фахишәләр үзләрен белдерер өчен ишекләренә махсус флаглар (өленгеләр) элеп куя торган булганнар. Пәйгамбәр заманында яшәгән бер монафыйк Габдулла ибне Гобәй фахишәлек өчен кәнизәкләр тоткан. Бу кеше хәзрәте Гайшә турында гайбәт таратып йөрүе белән дә билгеле. Шулай да, Габдулла ибне Гобәй вафат булгач, Пәйгамбәр үзенең иң явыз дошманын гафу иткән, дип сөйлиләр.

Исламият, зинаны катгый сурәттә тыеп, аны кылучыларга тиешле җәзалар билгеләгән.

Казанда рәсми рөхсәт ителгән фәхешханәләрнең күпчелеге Кабан буендагы Пески (соңгы вакытларга кадәр *Дегтярная*) урамында булган. Губерна земство идарәсе мәгълүматларына караганда, XIX гасырның 80 нче елларында шәһәрдә шундый «ханәләр» 30лап булып, аларда 250 хатын исәпләнгән. Ләкин ялгыз килеш яисә яшерен йортларда «эшләүчеләр» берничә тапкыр күбрәк исәпләнгән. Алары еш кына «сунарга» хәзерге Опера театры янындагы бакчага чыкканнар (бу хакта Галиәсгар Камалның «Уйнаш» әсәрендә шактый мәгълүмат бар).

Фәхешханәләрнең ишегенә кызыл фонарь элеп куйганнар, шуңа күрә мондый йортлар «кызыл фонарьлар» яки «фонарьлы йорт» дип тә аталган. Галимҗан Ибраһимов язганнарга караганда, «кызыл фонарьларга якынлашу белән тыштан ук гармунның исерек кулда гырылдаган тавышы, «Дүдәк» көенә әйттерүләре» ишетелеп торган. Мәйханә һәм трактирларда җырлана торган «Кече (Кәҗә? —*А.Т.*) Маһи» көе дә булган («Татары», 2001). Гаяз Исхакыйның «Теләнче кызы» романы, аерым алганда, Казан

шәһәрендәге фәхешханәләр, андагы «әчке» тәртипләр һәм әхлаксызлыклар, фахишәлек юлына баскан татар хатыннары, фәхешханәгә килеп йөрүче мөселманнар турында шактый тулы мәгълүмат бирә.

Фәхешханәләр өчен төзелгән рәсми кагыйдәләрдән бер өзекне русчадан тәрҗемә итеп бирәбез: *«Караватлар бер-берсеннән бүлеп алынган яки, һич югында, чаршау белән аерылган булырга тиеш. Хуҗабикә хатын-кызларының урын-җир һәм эчке киемнәренең пөхтәлеген ничек саклауларын, гаурәт җирләрен җылы су белән юып торуларын, бигрәк тә кыз-кыркыннарның бер кунактан икенчесенә юынмыйча һәм ял итмичә генә күчмәүләрен, айлыклары тотканда һөнәрләре белән шөгыльләнми торуларын күзәтергә тиеш»*.

Казанда Пески урамында яшәгән халык якындагы «кызыл фонарьлар» шау-шуыннан, исерекләрдән, гауга-талашлардан тәмам туеп, җирле хакимиятләргә күптапкырлар шикаять иткән. Ниһаять, Георгий чиркәве каршындагы мәхәллә нәзарәте (попечительлеге) рәисе А.О.Тихомирнов (большевик В.А.Тихомирновның әтисе) акчасы хисабына монда чиркәү мәхәлләсе мәктәбе салгач, гамәлдәге закон нигезендә, уку йортларыннан 150 сажиннан да якынрак булган фәхешханәләрне ябалар. 1907 елның ахырында Кабан күле буендагы йорт хуҗалары, фәхешханәләрнең үзләре янына күчеп килүен булдырмас өчен, якында часовня төзергә урын сорап Шәһәр думасына үтенеч белән мөрәҗәгать итәләр. Дума аларның да үтенечен канәгатьләндерә. Дөрес, фәхешханә хуҗалары Пески белән янәшәдәге башка урамнарда яңа урын тапканнар. Өлкән буын вәкилләре хәзерге Свердлов урамының «Победа» кинотеатры (хәзер «Офицерлар йорты») тирәсендә кичләрен кызыл оек кигән фахишәләрнең әрле-бирле «сунарда йөрүләре» турында сөйлиләр. Шунда ук Александр Пушкинга да таныш «Горловой кабак» эшләп торган.

Тукайның сатирик «Кисекбаш»ыннан Карахмәтнең прототибы, Тукай белән бер кунакханәдә яшәгән цирк артистына «чылбырсыз алтын сәгать» бүләк ителүен беләбез. Ул заманнарда исә «чылбырсыз көмеш сәгать» дип венерик авыруны атаганнар икән. Цирк баһадиры «алиһә чире»н (диалектта — «кыргаяк» авыруын) якындагы Пески урамында йоктыргандыр, дип фараз итик.

Хәзерге вакытта Казан шәһәрендә 250ләп фахиш «Досуг» фирмасы бар, диләр. Болардан тыш, аерым «эшләүче» бихисап «индивидуалка»ларның телефон номерлары йорт диварларында чекерәеп тора... Бу язуларны кырып бетерү өчен генә дә шәһәр хакимияте аена бер миллион сумнан артык акча исраф итә, имеш.

Ләкин фахишәлек пропагандасы алай гына бирешми. Хәзерге вакытта «индивидуалка»ларның адресларын йорт стеналарында гына түгел, интернетта да табарга була, диләр. Кайбер илләрдә фахишәләр өчен берничә айлык курслар эшләп килә.

Ихтимал, безнең көннәрдә яңа битлек кигән фәхешханәләргә һәм массакүләм секс индустриясенә каршы көрәштә югарыда әйтелгән кебек «сыналган» чаралар һәм алымнар эзләргә туры килер. Вөҗдансыз уен автоматларын шәһәр урамнарыннан сөргән кебек, бәлки, «Дөмбер карчык йортлары»н да җимереп ташлый алырбыз...

ДУНИ — Русча: *Донской* (Дон — *Тын* елгасы). *Дмитрий бине Иван әд-Дуни* (бу исем Ш.Мәрҗани хезмәтләрендә очрый) — Дмитрий Иванович Донской (1350-1389), Калталы Иванның оныгы. Шунысы кызык, Көнбатыш Европада Дмитрий Донскойны «Урус-хан» дип йөрткәннәр икән (С.И.Валянский, Д.В.Калюжный).

Олуг кенәз Дмитрий Донской — болгар-татарларга да мәгълүм шәхес.

Дмитрий Донской Куликово кырында

Әле Дон буенда Мамайга каршы сугышканчыга кадәр, ул 1376 елда кенәз Дмитрий Михайлович Волынский җитәкчелегендә Болгар өстенә Мәскәү гаскәрен җибәрә. Рус гаскәре мондагы авылларны, кышлакларны (рус елъязмасында — «зимовища») һәм Идел буендагы бакалтайларны туздыра башлый. Бу сугышта болгар-татарлар ук-җәяләр генә түгел, туп та кулланганнар, дигән хәбәр бар. Ләкин алар мәскәүлеләр чирүенә каршы тора алмаганнар һәм Олуг кенәзгә мең сум, яу башларына һәм гаскәргә 3 мең сум түләргә мәҗбүр булганнар. Мәскәүлеләр Болгарда һәм Казанда үз даругаларын һәм тамгачыларын утыртканнар, элек исә аларны Алтын Урда ханы билгели торган булган.

1380 елда Куликово кырындагы (И.Р.Мусинада — *Һәлак кыры*) сугыштан соң, Дмитрий Донской Мәскәү кенәзлегендә акча сугу эшен кабат торгыза. Ул чыгарган акчалардагы язу шактый кызыклы нәтиҗәләр ясарга урын калдыра. Мәс., Дмитрий Донской акчасының бер ягына: «Султан Туктамыш хан. Да упрочится царство его» дип язылган. Ягъни «Туктамыш хан-солтан. Ныгысын аның хакимлеге» була инде. Димәк, Мәскәү кенәзе үзен һич тә Алтын Урданы җиңүче дип санамаган, киресенчә, ул *ханлыкның ныгуын теләгән*. Бөек кенәз Василий Дмитриевич (Дмитрий Донскойның улы) чыгарган акчаларда да шундый ук язма бар. Ә Мамайны җиңүгә килгәндә, Мамай — хан түгел, бәлки ханнарга буйсынудан чыккан «төмән башы» гына. Хәер, кайбер тикшеренүчеләр Куликово сугышында Донской җиңмәгән, дип тә хисаплыйлар. Аның Донской — *Дуни* кушаматына килгәндә, анысы да Куликово сугышыннан соң башта Серпухов кенәзе, шулай ук Калталы Иван оныгы Владимир Андреевичка (1353-1410) бирелгән була. Сугыш тәмамланып, куркак Дмитрий Иванович агач астыннан сау-сәламәт килеш табылганнан соң исә, «гомуми җыелыш» Донской исемен Дмитрийга тагып, Владимирга «Хоробрый» (Храбрый) ләкабен бирергә карар чыгара.

Югарыда сөйләнгәннәр нигездә «рәсми тарих» мәгълүматларын кабатлаудан гыйбарәт. Ләкин соңгы елларда аерым галимнәр (Фоменко А.Т., Носовский Г.В.) күтәреп чыккан «Яңа хронология» гипотезасы Куликово сугышын Тула өлкәсеннән Мәскәү шәһәре территориясенә («Куличково/Кулишки кырына») күчерә. Сугыш кырында ятып калган күп меңләгән рус сугышчылары, рәсми тарихта язылганча, Куликово кырында (сигез көн буена!) җирләнгән, ләкин анда үткәрелгән җентекле архе-

ологик эзләнүләр җир куенында бернинди кеше сөякләре дә таба алмады. Аның каравы Мәскәүнең үзендә XX гасырның 30 елларында ЗИС (Сталин фаш ителгәннән соң ЗИЛ га әйләнде) автомобиль заводының Культура сарае төзелгән урында әле хәзер дә күпсанлы туганнар каберләре ачыла тора. Бу онытылган каберләр нәкъ менә «Куликово/Куличково кыры» сугышы булган чорга нисбәт ителәләр. Тагын шунысы әһәмиятле: җир астыннан чыккан баш сөякләренә караганда, монда җирләнгән кешеләр башлыча яшь кешеләр булып, тешләре таза һәм яхшы сакланган икән. Соңгы факт аларның сугышта үлгәнлекләре турында сөйли. Әлеге гипотеза авторлары сугышның Мәскәү территориясендә булуына шактый саллы башка дәлилләр дә китерәләр («Мамай сугышы»на нисбәтле барлык географик атамаларны Мәскәүнең үзендә табып була икән, шул ук вакытта аларга тәңгәл обьектларны Дон — Непрядва буйларында таба алмыйсың). Бу сугыш турында төп чыганак булып исәпләнгән «Задонщина» хикәятендәге «Дон» һәм «Непрядва» атамалары да соңыннан өстәлгән булырга охшый. Янә шунысына басым ясап әйтергә кирәк, Дмитрий Донскойның атлы гаскәрендәге сугышчылар арасында керәшен татарлары, шулай ук Себер һәм Идел буе болгар-татарлары да булган (Л.Н.Гумилёв буенча). Шуңа күрә Мәскәүдәге әлеге каберлектә гади чокырларга тәртипсез рәвештә шыплап тутырылган адәм сөякләрен антропологик яктан тикшерү дә соң түгелдер әле. Казан алынганда һәлак булган «рус» сугышчыларының Казансу уртасындагы пирамида эчендә саклана торган баш сөякләре арасында да төркиләргә хас сөякләр бар, дип сөйлиләр бит.

Әгәр бу гипотеза раслана калса, рус тарихындагы иң зур вакыйгаларның берсе булган «Куликово кыры сугышы»н бөтенләй башкача бәяләргә һәм кенәз Дмитрийның үзен Донской ләкабеннән «мәхрүм итәргә» туры киләчәк.

Туктамышның Мәскәүне камавы

Икенче яктан исә, Алтын Урда чикләрен тикшергән В.В.Похлебкин язганча, хәзерге Тула өлкәсендәге «Куликово поле» территориясе Алтын Урда җирләре саналган һәм куркак табигатьле Дмитрий Донскойның бирегә гаскәр белән килүен «Мамай явы» һөҗүме дип атап булмый. Шуңа күрә «Куликово сугышы» вакыйгасының чынлап та хәзерге Мәскәү территориясендә булу ихтималы арта.

Билгеле булганча, 1382 елда Туктамыш Мәскәүгә яу белән килгәч, Дмитрий Донской каладан чыгып кача. Ә шәһәрдәге «яман бәндәләр өй борынча йөреп, нәүрәпләрдән бай хуҗаларның ачы балларын алып чыкканнар һәм ләх булганчы эчеп исергәннәр». Туктамышка Мәскәүне алу инде кыен булмаган... Дмитрий Алтын Урдага яңадан баш иярга мәҗбүр булган.

Дмитрий Донской чорында (1367 елда) Мәскәү кремле диварлары таштан торгызылган.

Патша Россиясе чорында әйләнештә йөргән 5 сумлык кәгазь акчага Дмитрий Донскойның сурәте басылган була. ■

БЕЛӘЗЕГЕМ, ЙӨЗЕГЕМ...

(ТР Милли музее фондларыннан)

Татар хатын-кызларының яратып киеп йөри торган бизәнү әйберләренең берсе — беләзек белән танышып китик. Татар хатын-кызлары кулына, ким дигәндә, ике кайвакыт аннан да күбрәк беләзек һәм шулкадәр үк йөзекне парлап кигән. Беләзекләрне көмештән, алтыннан яисә алтын йөгертеп, кайбер очракларда алтын һәм көмеш эретмәсеннән ясаганнар. Җиз һәм бронзадан эшләнгәннәре дә очраган. Формаларына, бизәү алымнарына карап аларны берничә төргә бүләләр. Мәсәлән, тар һәм киң, чокып, бөтереп, бөртекләп, оялап эшләнгәннәре. Беләзекләрне бизәүдә төрледән-төрле кыйммәтле ташлар кулланылган. Җемелдәве тонык, аксыл сары, кырыйлары буйлап бераз яктылык төшерүчән күк төсле ачык зәңгәр яки яшькелт-ачык зәңгәр фирүзәне еш кулланганнар. Якут, топаз, ахак кебек чын ташлар белән дә бизәгәннәр беләзекләрне. Гадәттә, беләзекләргә чәчәк, үсемлек рәсемнәре, геометрик бизәкләр, Коръән сүрәләреннән аятьләр уелган. Ә кайвакыт иясенең исеме дә язылган.

***Руфия Мөхетдинова** әзерләде.*

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1915 елның февраль ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Приютның кызлар мәктәбе

Казан хәйрия җәмгыяте приютының кызлар мәктәбендә бу ел мәүлид бәйрәме ясалып, бәйрәм көнне укучы кызларның мәүлид касыйдәләрен тыңларга бик күп хатыннар да килгән булганнар. Бәйрәм күңелле генә үткән.

Кояш. — 1915. — №619. — 2 февраль.

Базарда кызыклы бер күренеш

Православныйларның уразасы керү мөнәсәбәте илә кичә иртә белән мөселманнарның кибетләре яптырылган иде. Базар көн булу мөнәсәбәте белән тирә-як авыллардан бик күп мөселманнар килгән икән. Аларга мөселман кибетләренең ябык булуы гаҗәп тоелган булса кирәк.

Кояш. — 1915. — №620. — 3 февраль.

Хәйрия җәмгыяте файдасына

Казанда Печән базарындагы Апанаевское подворье номерлары, пакь, чиста номерлар тоту илә шөһрәт алган борадәран Рамазановлар кулына күчте. Шушы Апанаевское подворье номерларын Рамазановлар исеменнән ачу тантанасы 8 нче февральдә якшәмбе көн булачак. Борадәран Рамазановлар бу ачу тантанасы көнне номерларның залларыннан килгән бөтен акчаны хәйрия җәмгыяте кассасына иганә итәргә карар биргәннәр икән. Җәмгыятьнең шундый матди ихтыяҗы вакытында Рамазановларның бу ниятләрен тәбрикләмәскә мөмкин түгел. Шәһәребезнең халкы да, бу хәерле эшкә җавап йөзеннән, ул көнне яңа номерларның залын карап чыгып, җәмгыятебезгә тиешле ярдәмне итәрләр, дип өмет итәбез[1].

Кояш — 1915. — №621. — 4 февраль.

Этләр өчен түләү

Этләрдән түләү алу хакындагы мәҗбүри карар 1 нче гыйнварда ук канун хөкеменә кергән булса да, этләр өчен галәмәтләр[2] алу хәзергә кадәр бик аз булган. Шәһәр управасы, бу мәҗбүри карарны җиренә җиткерү өчен эт тотучыларның ишегалларына кереп, галәмәтсез этләрне тотарга вә боларның ияләре түләп галәмәт сатып алганга кадәр «Этләр йорты»нда асрарга боерык биргән.

---

* Даталар иске стиль белән бирелә

[1] Газетаның 629 нчы санында 13 февральдә Рамазановларның «Апанаевское подворье чәйханәсе» ачачаклары һәм ачылу көнендә килгән барлык керемнең Казан хәйрия җәмгыятенә тапшырачаклары турында, ә 630 нчы санында 76 сум 17 сум тапшырганнары турында хәбәр ителә.

Хөрмәтле мөхәррир әфәнде!

Минем ошбу рәхмәт хатыма газетагызның бер почмагында урын бирсәгез иде. Шәһәребезнең хәйриячеләреннән Садыйк әфәнде Галикәев минем идарәмдәге кызлар мәктәбендә укучы фәкыйрь балаларга өләшер өчен йөздән артык күлмәклек җибәртте. Бу күлмәклекләр мәктәптә укучы кызларның иң фәкыйрьләренә өләшенде. Балалар шат булып, Садыйк әфәндегә догалар әйттеләр вә рәхмәтләр укыдылар. Яңа бистәдә мөселманнарның фәкыйрь өлеше тора икәне мәгълүм. Аларның укый торган балаларына ителгән ярдәм — иң урынлы ярдәмдер. Шәкерт кызларым исеменнән Садыйк әфәндегә рәхмәт әйтүне үземнең бурычым саныйм. Яңа бистәнең 9 нчы мәхәллә кызлар мәктәбе мөдирәсе Рабигә Әмирхания.

Кояш. — 1915. — №623. — 6 февраль.

Бәһа күтәрүгә каршы

Шәһәр финанс һәм техника комиссияләренең 5 нче февральдә булган уртак мәҗлесендә хәзерге көндә шәһәрдә икмәк бәһасен күтәрү мәсьәләсе каралды. Арыш онының бәһасе потына 8 тиен генә күтәрелгән булса да, икмәк бәһасе потына 40 тиен күтәрелүе дикъкатьне җәлеп итте. Комиссия мәҗлесе бу мөнәсәбәт белән шәһәр Думасының ашамлык әйберләргә такса төзү (бәһа билгеләү) турында канун буенча бирелгән хокукын игътибарга алып, ике атна саен була торган Дума мәҗлесләренең һәрберендә күмәч вә икмәк бәһаләрен билгеләргә вә һәр билгеләнгән бәһанең икенче Дума мәҗлесенә кадәр хөкемен йөртергә, дигән карарны кабул итте. Дума мәҗлесләре, үзенең хокукыннан файдаланып, һәртөрле ашамлык әйберләргә такса куйса (бәһа билгеләсә), шәһәр халкы өчен файда гына итәчәктер. Чөнки сәүдәгәрләрнең комсызлыгыннан шәһәр халкы шуннан башка котыла алмаска охшыйдыр. Шәһәр халкының күбрәк кыйсеме мөгалләмә итә торган урам кибетләрендә икмәк, күмәч көннән-көн начарланганы хәлдә, бәһасе күтәрелә барганы сизеләдер.

Фаҗигале үлем

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укучы Суыксу волосте Өбрә авылының Ибраһим Гомәров дигән 16 яшьлек шәкерт, 12 нче гыйнварда мәүлид бәйрәменә бирелгән ял көннәреннән файдаланып, авылына кайтырга уйлаган. Ибраһим, авылына тизрәк кайтып җитү нияте белән чаңгылар табып алып, иртән таң белән юлга чыгып киткән. Юлда барганда, Өбрә авылыннан ерак түгел генә урында, авылдан китеп баручы авылдашларына да очраган. Бу очраган авыл кешеләре икенче көнне Ибраһимның аталарына шәкерт белән күрешергә диеп килсәләр, шәкерт әле кайтып җитмәгән булган вә хәтта ата-аналарына да аның кайтуы яңа хәбәр булып күренгән. Хәбәр ишетелгәндә, угылыбыз күрше авылда кардәшләрендәдер, дип уйлап кына калган ата-ана, ике-өч атна үткәч пошына башлаган һәм күрше авыллардагы кардәшләреннән сораша башлаган. Никадәр сорашып та бер җирдән дә канәгатьләндерерлек җавап булмагач, ата-ана вакыйганы полициягә хәбәр иткән. Өяз полициясе, бөтен авыл халкы белән бергә аякка басып, бөтен тирә-якны актара башлагач, Өбрәдән 4 чакрым читтә шәкертне карга күмелеп үлгән хәлдә тапкан. Чаңгылар мәетнең янында көе табылган. Шәкерт туңып үлгәнме, әллә сугып үтергәннәрме — хәзергә

ачык мәгълүм түгел. Һәрхәлдә, дошман күрүчеләр тарафыннан үтерелгәндер, дип шикләнү бик куәтледер[3].

Кояш. — 1915. — №624. — 8 февраль.

Игълан шәргый

Казан губернасы һәм өязе Яңа Кишет волосте Иябаш авылындагы Габдрахман Габдулла углының 8 ел хәбәре килмәү вә кайда икәнлеге мәгълүм булмау сәбәпле, шул ук волостьның Өтнә авылындагы Дәүләтшаһ Вәлишә углының әлеге кеше никахында булган кызы Бибизарифә, иренең 8 елдан бирле акча җибәрмәвеннән һәм дә яшәешне тәэмин итү гаять авыр булуыннан зарланып, миннән фәсех никах[4] таләп итә. Шул сәбәпле, Габдрахман Габдулла углы 15 нче елның апреленә кадәр үзе кайтып җитмәсә яки минем исемемә хатыны Бибизарифа өчен акча җибәрмәсә, мин боларның арасында нихакны бозып, книгага язам. Үтенәмен: кем дә кем Иябашы Г.Габдулла углының кайда икәнен белә, хәбәр итсен. Өтнәдә имам Минһаҗетдин Әхмәров.

Кояш. — 1915. — №627. — 11 февраль.

Карс[5] мөселманнары файдасына театр уены

Хәйрия җәмгыятенең башлап йөрүе белән 18 нче февральдә Карс мөселманнары файдасына театр уены куелды[6]. Ханымнарыбыз һәм яшь сәүдәгәрләребезнең тырышып сатулары аркасында бәһаләре гаять кыйммәт куелган билетлар көтелгәннән артык яхшы сатылган иде. Бу билетлар моңа кадәр һич тә театр билеты күрмәгән гаиләләргә дә барып кергәннәр. Моңа кадәр театрда бер дә күренмәгән кешеләрдән дә берникадәресен татар театрына әүвәл мәртәбә китергәннәр. Башка вакытлардан аермалы буларак, бу көн театр залының өчтән ике өлешен ирләр вә ирләрнең дә яшьрәкләре тутырганнар иде.

Тамашага «Ачлык кушты» пьесасы куелды. Пьеса, әдәби җәһәттән кыйммәтле бер нәрсә булмаса да, ачлыктан һәлак була торган мөселманнар файдасына ясалган кичә өчен куярга бик яраклыдыр. Моннан соң куелган музыка номерлары вә Кавказ биюләре, хосусый бер әһәмияткә ия булыр дәрәҗәгә ирешмәсәләр дә, килүчеләрне канәгать итәргә ярадылар. Театр файдасына чәчәкләр сатар өчен шәрык ысулында бер киоска, фрукта сатар өчен янә бер киоска һәм чәй өстәле әзерләнгән иде. Уен башланганчы вә антракт вакытларында киоскалар һәм чәй өстәле бик кызу сәүдә итте. Ханымнардан кайберләре бик тырышып программалар сатып шактый акча җыйдылар. Чәй өстәленең вә киоскаларның ханым вә туташлары иҗтиһад белән халыкны юмартлык итәргә мәҗбүр итәләр. Халык, аеруча урта сыйныф, хуш күңел белән иганә яудыралар иде.

Җыелган халыкның мондый мәҗлесләрдә азрак була торган сыйныф

---

[3] Газетаның 625 нчы санындагы «Шикләнмиләр» дигән мәгълүматта: «Вафат булучының кардәшләре, әлеге шәкертнең вафатында һичкемнән шикләнмәгәнлекләрен идарәбезгә хәбәр иттеләр», — дип язылa.

[4] Фәсех никах — никахны таркату, аеру.

[5] Карс — Карск өлкәсе — 1878-1917 елларда Россия империясенең Кавказ аръягындагы административ-территориаль берәмлеге. Хәзер бу җирләрнең бер өлешенә әрмәннәр, ә бер өлешенә төрекләр хуҗа.

[6] Газетаның 618 нче санында басылган «Казан[нан] — Кавказ мөселманнарына» дигән мәкаләдә «Казан хәйрия җәмгыяте Кавказ мөселманнары файдасына Новый клуб залында спектакль куярга карар биреп, бу эш артыннан башлап йөрүне Зиннәтулла Госманов, Нургазиз Хөсәенов һәм Фәхрелислам Агиев вә Ибраһим Бикколовларга тапшырды», — дип язылa.

халкы булуына да карамыйча, кичә гаҗәеп бер тәртип белән барды. Халкыбызның һәр сыйныфында иҗтимагый әдәпнең җирләшеп баруын күрсәтә торган бу тәртипне хөрмәт итеп, хосусый бер канәгатьлек белән искә алып китәргә мөмкин. Хәйрия җәмгыятенең яшь әгъзалары, һәммәсе диярлек эштә иделәр. Алар үзләре билет саткан белеш-танышларын чәй өстәле тирәсенә, киоскалар янына җәлеп итүдә зур эшлеклелек күрсәттеләр. Урта сыйныф халкыбызның һиммәтен һәммәбезгә үрнәккә алырлык. Ул үз-үзен сынатырга бер дә риза түгел: байлар килгән һәрбер җиргә ул да килә ала икәнен, башкалар биргән кадәрне ул да бирә ала икәнен әлеге сыйныф хосусый бер әзерлек берлән күрсәтә бирә.

Бу кичәнең тагын бер хосусияте күзгә бәрелде. Монда әүвәл мәртәбә яшьләр вә картлар кулга кул тотынышып эшләделәр. Бу әүвәлге тәҗрибә бик уңышлы чыкты. Картлар үз эшләрен беләләр, яшьләр үз эшләрен беләләр, бер-берсенә ярдәм итешәләр. Бу әүвәлге адымның уңышлы чыгуы хәйрия җәмгыятебезнең моннан соңгы адымнарында да хәтергә алынырга тиеш буладыр.

Кичәнең хисабы әле тәмам булганы юк. Шулай да аның килере якынча түбәндәгечәдер. Билетлар — 1700 сум, иганәләр — 550 сум, чәчәкләр сатудан — 200 сум, фрукта сәүдәсеннән — 150 сум, чәй сәүдәсеннән — 140 сум, программалардан — 93 сум. Җәмгысе — 2833 сум. Моннан әле уен куйган өчен булган һәм алынган нәрсәләргә тотылган расходлар чигерелергә тиеш буладыр. Ничек булса да, саф файда ике мең ярым сумнардан ким булмаячак. Хисаплар тәмам ителгәч, табигый, хәйрия җәмгыяте идарәсе аны җирле матбугатта җентекле рәвештә игълан итәр[7].

Кояш. — 1995. — №635. — 20 февраль.

Гаскәриләргә җибәрелгән бүләкләр

Казан мөселманнарыннан сугыш сафындагы гаскәриләргә өләшергә диеп управа аркылы 11 ящик кием, ат итеннән бәлешләр һәм ат казылыклары җибәрелгән иде. Управа бу әйберләрне шәһәрләр иттифакы сафына кергән Казан адвокатларының сәламәтлек саклау комиссиясе ярдәмендә җибәрде. Инде хәзер шәһәр управасына бу комиссия вәкиленнән түбәндәге мәгълүмат килгән: «Казан мөселманнарыннан мөселманнарга диеп җибәрелгән 170 күлмәк, 130 штанны һәм дә ат итеннән ясалган 6 ящик бәлешне, бөтен полкы мөселманнардан гына гыйбарәт булган 2 нче Дагстанский полкка тапшырдым. Бу рәвешчә иганә кылучыларның Казаннан киткән гаскәриләргә дип билгеләнгән бүләкләренең бүтән урынга сарыф ителүенә, комиссиябезнең барырга билгеләнгән урыны алмашынуы, һәм дә бүләк, ияләре билгеләнгән урынга җибәрелгәндә, югалу ихтимал икәнлеге сәбәп булды. Әлеге бүләкләр бирелгән полк Казан мөселманнарына рәхмәт әйтте. Ат казылыклары тутырылган 4 ящик исә, чиктән тыш бозылганлыктан, кызганычка каршы, бүләк итеп бирерлек булмады».

Кояш. — 1915. — №638. — 24 февраль. ■

---

[7] Газетаның 640 нчы санындагы хисапта җәмгысе — 3013 сум 27 тиен, саф файда — 2675 сум 42 тиен дип күрсәтелә. «Карс мөселманнары файдасына» дигән хәбәрдә: «Татарча театрдан килгән саф файда, Баку хәйрия җәмгыятенә җибәрергә, Казан губернаторы җәнабләренә тапшырылган», — дип языла.

ТАТАРЛАР БАР ҖИРДӘ – БАТЫРЛАР БАР!

Осталыклары белән дөнья стадионнарында, спорт залларында, манеж һәм келәмнәрдә тамашачыларны сокландырган милләттәшләребез шактый. Иксез-чиксез дөньяның төрле төбәкләреннән килеп чыгалар да алар, зур нәтиҗәләргә ирешәләр, тамашачы ихтирамын казаналар, Ватаныбызның спорт данын арттыралар.

Элеккеге СССР дип аталган зур дәүләтнең спортчылары егерменче гасыр башында кире кайтарылган Олимпия уеннарында 1952 елдан башлап катнаша башладылар. Хельсинкида узган әлеге зур бәйгедә грек-рим көрәше остасы, Сергач якларында туып-үскән **Шәгъзам Сафин** үз үлчәү авырлыгында барлык көндәшләрен аркага салды.

...1963 елда велосипедчыларның дөньякүләм Тынычлык узышында **Гайнан Сәетхуҗин** җиңеп чыкты. «Тау короле» дигән кушаматы да булган бу спортчыны байтак стадионнарда алкышладылар, ул 18 ел дәвамында велосипедта узышуда СССР җыелма командасының капитаны булып торды. Бу рекордлы күрсәткечне әлегә кадәр берәүнең дә уздыра алганы юк.

...1966 елда дөнья чемпионатында мәйданга чыккач, буе нибары 166 см булган, үзе дә туп кебек җитез **Галимҗан Хөсәенов** турында Чили газеталары: «Советларның яшерен коралы дөньяга чыкты», — дип яздылар.

...1972 ел. Татар егете **Фёдор Симашев** Саппоро Олимпиадасында чаңгычыларның эстафета узышында алтын медаль яулады. **Ринат Сафин** исә биатлон ярышларында ил командасын унынчы урыннан беренчегә чыгарды.

Мюнхен Олимпиадасында **Шамил Хисаметдинов**, барлык көндәшләрен җиңеп, грек-рим көрәше буенча мактау баскычының иң югарысына менде. Югары техник алымнар күрсәткәне өчен итальяннар аны «Маэстро» дип атадылар.

...1976 ел. Монреаль. Финалда татар кызы **Наилә Гыйләҗева** фехтование Ватаны булган Франция спортчысын бәхәскә бернинди урын калдырмыйча отты.

...1983 ел. Японнарның дзю-до көрәше буенча Европа беренчелегендә **Хәбил Бикташев**, үзеннән күпкә авыррак булган атаклы көрәшчеләрне аркаларына салып, абсолют чемпион исемен яулады.

...1988 ел. Германиядә үткән континент беренчелегендә **Ринат Дасаев** белән **Вәгыйзь Һидиятуллин** оста уеннары өчен символик җыелма команда исемлегенә кертелделәр.

Бу исемлекне алга таба да дәвам итеп булыр иде. Шахматчылар **Алисә Гәлләмова**, **Гатаулла Камский**, **Рәшит Нәҗметдинов**, **Артур Йосыпов**, көрәшчеләр **Ленар Сәлимуллин**, **Наил Измайлов**, йөгерешче **Равил Кашапов** белән **Лилия Нуретдинова**, боксчы егетләребез **Айрат Хаматов** белән **Фоат Гатин**, гимнасткалар **Галимә Шөгерова**, **Венера Зарипова**, **Яна Батыршина**, **Алинә Кабаева**... Һәркайсы хакында аерым язма гына түгел, китап язарлык күрсәткечләре, уңышлары бар.

Кайда гына, кемнәр алдында гына чыгыш ясарга туры килмәсен, алар һәрчак үзләре булып калалар, совет һәм Россия спорты данын югары тоталар һәм иң мөһиме — үзләренең татар халкы вәкиле икәннәрен бервакытта да онытмыйлар. Әнә 1989 елда Мәскәүдә бокс буенча үткән дөнья беренчелегендә финал алдыннан Казан егете **Айрат Хаматовка** болгариялеләр: «Әгәр дә безнең Киркоровка оттырсаң, без сиңа «Мерседес» машинасы бүләк итәбез», — диләр. «Минем өчен машина түгел, ә җиңеп якташларымны сөендерү кыйммәт!» — дип җавап бирә татар егете.

Нәфис гимнастика буенча дөнья күләмендә ун еллап җиңелү белмәгән **Галимә Шөгерова** турында ишеткәнегез бардыр. Бервакыт чемпион калгач, ялгышмы-болаймы, аңа **Галина Шөгерова** дип язылган грамота бирәләр. Әмма кыз аны алмый. «Исемемне дөрес языгыз!» дип таләп итә. Ярыш судьяларына, яңа грамота табып, исемне дөресләп язып бирүдән башка чара калмый.

Хоккейчы **Зиннәтулла Билалетдинов** белән дә шундыйрак хәл була. Бервакыт дөнья чемпионатыннан безнең илгә репортаж биреп баручы комментатор аны Захар дип кенә әйтеп җибәрә.



Галимә Шөгерова

Татар спортчылары иң күп медальне көрәш һәм гимнастика буенча яулаган икән. Моннан инде гап-гади нәтиҗә килеп чыга: безнең ир-егетләр элек-электән таза, көчле, ә кызларыбыз чибәр һәм зифа буйлы булган.

Бу хакта белеп алган Зиннәтулла, әгәр теге комментатор аннан килеп гафу үтенмәсә һәм яңадан исемен дөрес әйтмәсә, киләсе уенга чыкмаячагын белдерә. Шуннан соң дикторлар, әйтелеше авыр булса да, Зиннәтулла Билалетдинов дип исем-фамилияне тулысынча әйтә башлыйлар.

Бу инде аларның үз милләтләре белән горурланулары, башка халыклар белән бертигез хокукта булуларын бик шәп белүләре хакында сөйли. Әйе, әгәр дә үз фикерләре булмаса, Галимҗан белән Гайнанны Гена дип, ә Ринатны Рома дип кенә йөртерләр иде.

Милләттәшләребезнең спортның кайсы төрләреннән аеруча уңышка ирешүләрен карый башласак, бик тә

кызыклы фактларга тап булырбыз. Татар спортчылары иң күп медальне көрәш һәм гимнастика буенча яулаган икән. Моннан инде гап-гади нәтиҗә килеп чыга: безнең ир-егетләр элек-электән таза, көчле, ә кызларыбыз чибәр һәм зифа буйлы булган.

Узган гасырның илленче-алтмышынчы елларында гимнастика күгендә Свердловск (хәзер Екатеринбург) шәһәреннән берьюлы дүрт бертуган **Нәҗметдиноваларның** балкуын дөнья газеталары могҗизага тиңләде. Иң олылары — **Лилия** нәфис гимнастика буенча СССРда беренче булып «Атказанган спорт остасы» исемен алды. Аннан соң **Әлфия** дә шушы исемгә лаек булды, апалары юлыннан **Розалия** белән **Илмира** да атладылар.

Омск гүзәле **Галимә Шөгерова** җитмешенче елларда Европаның да, дөньяның да абсолют чемпионы булды һәм берничә ел дәвамында бу исемнәрне үз кулында тотты.

1972 һәм 1976 елларда спорт гимнастикасы буенча СССР командасы составында Олимпия уеннарында җиңү яулаган **Эльвира Саади** — кайчандыр Казаннан Ташкент якларына күчеп китәргә мәҗбүр булган галим **Габдрахман Сәгъди** оныгы. Белеп торыгыз: Монреаль һәм Мәскәү Олимпиадаларының 5 алтын медаленә хуҗа булган Чимкент (Казахстан) гүзәле **Нелли Кимның** да әнисе — татар хатыны. Соңгы елларда нәфис гимнастикадан халыкара ярышларда **Венера** һәм **Әминә Зарипова-лар**, **Роза Галиева**, **Яна Батыршина**, **Алинә Кабаева**, **Ләйсән Үтәшева** кебек милләттәшләребез дан казанды. Димәк, үткән гасыр урталарыннан ук башланган традиция бүгенге көндә дә дәвам итә, яңадан-яңа талантлар ачыла.

Шахмат уенын спортмы, фәнме яисә сәнгатьме дип күптән бәхәсләшәләр. Бик күп акыл һәм физик көч, түземлелек сорый торган бу уен осталары

Гатаулла Камский

арасында хәзер инде мәрхүм **Рәшит Нәҗметдинов** аерым урын тота. Халыкара гроссмейстер дигән дәрәҗәне йөртмәсә дә, мондый титулга ия булучыларны гына түгел, ә дөнья чемпионнары **Михаил Таль** белән **Борис Спасскийны** да откан шәхес. Ул татар егетләре һәм кызлары арасында гроссмейстерлар үсеп чыгуын бик теләгән иде. Аллага шөкер, дөнья чемпионы исеме өчен финалда уйнаган **Алисә Галләмова** белән **Гатаулла Камский**, халыкара турнирларда җиңү яулаган **Артур Йосыпов**, **Евгений Барыев**, **Илдар Ибраһимов**, **Сандугач Шәйдуллина** кебек гроссмейстерларыбыз бар.

Марат Сафин

Татарларны без элегрәк күбрәк көч, җитезлек, түземлелек таләп иткән көрәш, гер күтәрү, ерак араларга йөгерү, велосипедта узышу кебек төрләрне күреп иярләнсәк, хәзер

инде алар баскетбол (**Руслан Әблиев**, **Ядкәр Кәримов**), зур теннис (**Марат Сафин**, **Шамил Тарпищев**, **Динара Сафина**), футбол (**Ринат Дасаев**, **Вәгыйз Һидиятуллин**, **Марат Измайлов**, **Динияр Биләлетдинов**) кебек безгә бөтенләй ят саналган уеннарда очрата башладык.

2000 елда АКШның ачык беренчелегендә җиңелгәннән соң әле кичә генә миллионлаган теннис сөючеләрнең кумиры булган **Пит Сампрас Марат Сафинны** «Егерме беренче гасыр уенчысы» дип атады.

Әйе, XXI гасыр башында Марат Сафин теннис буенча дөньяның иң көчле уенчысы исемлегендә торды. Аның сеңлесе **Динара** да теннис Олимпын көннән-көн ныграк штурмлап, иң көчле 10 хатын-кыз теннисчы рәтендә исәпләнде.

Милләттәшләребезне бүген спортчылар арасында гына түгел, ә тренерлар, белгечләр арасында да күпләп очратабыз. Хоккей буенча **«Динамо»** (Мәскәү), **«Ак барс»** (Казан) командаларын ил чемпионы иткән **Зиннәтулла Биләлетдинов** АКШ һәм Швейцария командаларында да эшләп кайтты. Туплы хоккей остасы **Ирек Фәсхетдинов** Швеция командаларының тренеры булды. Бүген **Ринат Билалетдинов** Казанның **«Рубин»** футбол командасында, **Ришат Гайнетдинов «Динамо-Казан»** хатын-кызлар волейбол командасында баш тренерлар.

Тагын бер танылган милләттәшебез **Шамил Тарпищев** — Россия теннис федерациясе президенты, ил җыелма командасының баш тренеры. Ул җитәкләгән егетләр берничә тапкыр **Дэвис** кубогын, ә хатын-кызлар белән **Федерация** кубогын отты.

Татарларның спорттагы уңышларының сәбәпләре хакында уйлаганда, халкыбызның милли бәйрәме сабантуйга әйләнеп кайтырга кирәктер. Игътибар иткәнегез бардыр: сабантуйдагы

Ринат Дасаев

күп кенә уен төрләре, алышлар безнең эрага кадәр үк борынгы Грециядә үткәрелә башлаган Олимпия уеннары программасы белән аваздаш. Әйтик, көрәш, ат чабышлары, йөгерү, авырлык күтәрү сабантуйның да, уеннарның да төп көч сынашуларын тәшкил итә. Без үзебез сабантуй бәйрәмен Олимпия уеннарына кадәр үк барлыкка килгән, дип уйлыйбыз. Дөньяда халыклар күп булса да, һәркем катнаша алырлык мондый олуг бәйрәм бер генә халыкта да юк. Дөрес, һәр халыкның үзенә генә хас көч сынашлары, бәйрәмнәре бар, ләкин масштаблылыгы, эчтәлеге, мәгънәсе ягыннан аларның берсе дә сабантуй белән тиңләшә алмый. Андагы һәр көч сынашу, һәр аттракцион яшьләрдә җитезлек, кыюлык, көч, тапкырлык тәрбияләгән. Шуңа да Олимпия уеннарының мактау пьедесталына менгән милләттәшләребезнең күбесе зур спортка юл башларының нәкъ менә сабантуйлардан килүен әйтәләр.

Милләттәшләребез арасыннан алга таба да зур спортчылар, чемпионнар чыгар, дип уйлыйк, чөнки, **Тукай** әйтмешли, «халык зур ул, көчле ул...»

Ә тагын бер татар шагыйре **Сибгат Хәким** сүзләрен бераз үзгәртебрәк әйтсәк, «Татарлар бар җирдә батырлар бар — кимендә бер урын татарга!»

Алмаз Гафиятов,
КФУ аспиранты.

«ТЫНГЫСЫЗ КАЛӘМ» БИТЛӘРЕННӘН

ТМИН (Туфан Миңнуллин),
(1935-2012)

ИҖАТ ЛАБОРАТОРИЯСЕННӘН

(«Урманда яз. Агачларда бөреләр». Шушы фактны кайсы шагыйрь ничек күрә һәм ниндиерәк шигырь яза?)

Сибгат ХӘКИМ

Авылыңа кайт та икән,
Урманга кермә икән,
Сукмагында йөр дә икән,
Бөрене күрмә икән.
Урман, агач, ботак, бөре,
Сез һаман бергә икән,
Сез һаман бергә икән…

Роберт ӘХМӘТҖАНОВ

Галактика —
урман,
Планеталар —
агачлар,
Җир —
бөре…
Мин —
аучы,
Кем бүре?!!

Гәрәй РӘХИМ

Бөреләр турында язасы бар әле.
Уянган бөреләр,
Уйланган бөреләр,
Ачылган бөреләр,
Корыган бөреләр…
Бөреләр турында язасы бар әле.

Корыган бөреләр һаман да ботакта,
Ачылган бөреләр әйләнгән яфракка.
Бөреләр турында язасы бар әле,
Бөреләр турында...
Бөреләр турында...

1974

Г.ГАЗИЗ (Газиз Гобәйдуллин), 1887-1937)

ХАТЫНЫМ ҖӘДИТ БУЛДЫ

— Менә әле, Әхмәтҗан абзый, син сәүдә яхшымы, дип сорыйсың. Әле эш анда түгел, минем өйдә бер дә рәт юк әле: хатын әллә нишләгән.

— Нишләгән соң, Батырша? Әллә авырыймы? Чирлиме? Әле минем хатынга да былтыр менә жинcки булис булган иде дә, теге Симунски дигән бабкы карап, сихәтләнде.

— Юк, Әхмәтҗан абзый, сихәте бар барын да... Менә әйтсәң дә оят инде...

— Йә, Батырша әйт... Аның ояты юк. Миннән чыкмый ул сүз.

— Менә, Әхмәтҗан абзый, ничек дип әйтим инде... Мине бик йөдәтә башлады, сөям, ди, гыйшык тотам, ди... Мин әйтәм: соң, гашыйк булсаң, син минем хатыным ич, тагын ни кирәк, дим. Муеныма сарыла, ашарга-эчәргә ирек бирми. Әллә нинди робагыйлар укый: синнән башка, ди, тора алмыйм, ди. Тормасаң, мин әйтәм, дөмек инде, һаман да, дим, бергә торабыз ич, дим.

— Вәсвәсә булмады микән, Батырша? Хиффәтләнмәде* микән? Хатыннар корсакка узгач шулай була торган...

— Юк.... Мин, ди, башта, ди, сине белмәгәнмен, ди... Менә ай яктысы булыр хәл юк, әллә ниләр сөйли; мин сине, ди, ничә елдан бирле сөям, ди... Бер, ди, ут яктысы шикелле нәрсә, ди, эчемдә һаман да: «Батырша, Батырша!» дип кычкыра, ди...

— Йә әле, ни сәбәптән ул болай икән, сөйлә әле...

— Белмим... Бары шул: бер асламчы карчык былтыр әллә нинди китаплар сатып йөрде дә минем җәмәгатькә дә саткан; шуларны укыгач кына булды инде ул... Берсе «Мескен Газизә» атлы китап. Шуннан ул миңа да укып йөдәтә, бер кыз бер кешегә гайшык булган: теге кеше аны алмаган да, аерылган. Син, ди, шуның күк, ди, мине сөймисең менә, ди... Валлаһи менә, ялап бетерә, кеше нәфәсе** авыр бит ул. Менә, ул инде яз җитсә, Арча кырына барыйк, ди... Шунда, сандугач сайрый башлагач та, миңа ябыша, сөям, ди. Аны нишләтәсең? Кешедән ояласың бит...

— Ә, Батырша, ул инде алай булса җәдит булган, җәдит... Алар бит шул гыйшык китаплары язалар бит. Робагыйның шәбе аларда инде... Мин аны бер дә хатынга бирмим: укыма, димен. Соң, кеше бит ул аза аннан соң. Әле безнең бай улы да: мин, дип әйтә ди, шагыйрь Пушкин, дип әйтә ди бит, мин язам, дип әйтә ди... Гыйльме горуз*** дигән бер гыйлем бар, ди, шуны укыйм да, дип әйтә ди, робагый яза башлыйм, дип әйтә, ди. Шуның бер язуын безнең Шәйхетдин укыган. Шул язган, ди, «сөйгәнемә» дип куйган да, ди, синең тырнагың — Каф тавы гәүһәре, кашларың сандугачныкыдай кәкре, дип язган ди.

— Табалар бит сүз, Әхмәтҗан абзый, ә? Минем җәмәгатем дә мачтыр инде ул сүз табарга. Соң беркөн, минем гомеремнең ап-ачык алмасы син, кайчан кавышырбыз инде, дип язган... Соң бит инде кич белән кайтам лабаса!

— Шулай инде ул, Батырша, хатыннар азса, харап эш ул. Ул дәрт бит ирләрдә бер өлеш булса, хатыннарда

*Хиффәтләнү — акылга җиңеләю, тилерү.
**Нәфәс — сулыш, сулу.
***Гыйльме горуз — шигырь үлчәве турындагы гыйлем.

җиде өлеш була, ди. Әмма инде хозур андый хатын, ә?

— Юк, Әхмәтҗан абзый, пүчтәк эш ул… Туйдыра бит ул… Соң ул менә харап инде… Мине, ди, син Гөлгазар дип йөр, ди… Шул исемдә бер китап укыган ул, күрәсең! Ни эшлим икән, Әхмәтҗан абзый, ә?

— Соң син аны теге бабкыга күрсәтеп кара… Алар бит тәҗрибәле булалар…

— Әйттем… Әле быел бала төшерде ул. Шуңа әйттем. Мин әйтәм, мая жана миңа лубуф диржет, дим. Бик яхшы, ди. Яхшы менә монда һаман да ялап торгач: кеше сулуы авыр бит ул…

— Дөрес, дөрес, Батырша.

— Менә әле, Әхмәтҗан абзый, беркөн, бәйрәм алдыннан, кәндитергә барабыз да, шунда, гөнаһ шомлыгына каршы, күрше Котбетдиннең кызы белән хатыны кергәннәр. Шуңа карыйсың ди бит, менә шабаш! Соң, мин әйтәм, сабый лабаса ул, дим. Аңар карамый, гыйшык хәле ул, ди, яшькә карамый, ди.

— Күрәсең, тәшвишләнә инде ул…

(«Юмор һәм сатира» китабыннан. 1966)

Разил ВӘЛИЕВ

ИКЕ ЭПИГРАММА

Марсель ГАЛИЕВКӘ

Тынак булдык — күрмәделәр,
Усалландык — багалар.
Ышанмасаң, укып кара —
Шәп бит «Кар абагалар!»

Фәннур САФИНГА



Язам дисәң, кырларың бар,
Җырлыйм дисәң, җырларың бар.
Тик син гел сөю җырлыйсың
Әллә инде күңелең тар,
Әллә сөйгән ярың бар.

(«Идел» альманахы, 1977) ■

Суфия Насыйрова һәм
Нияз Хаҗиәхмәтов шаржлары.

Мирасворд

- Дәрдмәнд шигыре
- Борынгы Рим полководецы
- Бурыч
- Урта гасыр болгар шәһәре
- Фатих Әмирхан повесте
- Аяз Гыйләҗев повесте
- Батыр сугышчы, рыцарь (иск.)
- Борынгы төрки-монгол халкы
- Туку станогы детале
- Епископның баш киеме
- Фаил Шафигуллин туган авыл
- ... Шабаев
- Фин-угыр халкы
- Геометрик җисем
- Кыргызстан каласы
- Хәлил Әбҗәлилов, Зәйни Солтанов
- Грек хәрефе
- Баянчы ... Сатиев
- Урал, Карпат
- «... кыры» (Ч.Айтматов)
- Язучы ... Камалов
- Металлдан эшләнгән борынгы хәрби баш киеме
- Алтын Урда ханы
- Актаныш районындагы авыл
- Сугыш, көрәш
- Уң ягы төксел йон тукыма
- 15-16 йөзләрдә Казанда эшләнгән ярминкә
- Мактау җыры, мәдхия
- 17 йөз ахыры - 18 йөз башында яшәгән татар шагыйре
- Көньяк Азия халкы
- ... ютәл
- Төньяк (иск.)
- Данлы исем, яхшы ат
- Күрсәтү алмашлыгы
- ... Урда
- Әдәби әсәр, китап бүлеге
- ... Әлмиев
- Фарсылар патшасы
- Бөек әзербайҗан шагыйре

Рәис Габдулла төзеде.

1 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: кашбау, шаһбаз, силә, рисалә, Акай, лар, кит, Нуры, әл, Лут, Майк, Ага, Арк, Саксин, Луис, ия, Рамзес, Маннур, «Муса», «Аң», тияк, Вера, Сүлти.
Өстән аска: Кәримова, Илу, сарказм, сарт, Кашгарый, аңа, Адлер, Шаһсәнәм, Ус, би, си, ачалак, дастан, Зәки, түр, Атласи, Наил, угия, ят, стан, Фракия.

Зур Проломная урамы. XX йөз башы

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
Елъязмасы / февраль

• 610 ел элек (1405)

Алтын Урда ханы, Казан ханлыгына нигез салучы олуг Мөхәммәд хан (1405-1445) дөньяга килә.

• 245 ел элек (1770)

Казанда Ахунов һәм Апанаевлар мәдрәсәләре ачыла.

• 120 ел элек (1895)

Казанда беренче татар комедиясе — «Комедия Чистайда» сәхнәгә куела.

• 90 ел элек (1925)

24 февральдә Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты коллегиясе утырышында Гыйльми Үзәк каршындагы татар коллегиясенең составы билгеләнә. Рәис — Г.Ибраһимов, әгъзалар — Ш.Әхмәдиев, И.Рәхмәтуллин, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Максуд, Л.Гомәр, М.Парсин, Г.Толымбай, М.Корбангалиев, Г.Рәхим.

• 85 ел элек (1930)

Һади Такташ «Камил» исемле кинокартина либреттосын тәмамлый. Либретто, ТАПП идарәсе утырышында тикшерелгәннән соң, «Шәрык кино» ширкәте тарафыннан куелырга кабул ителә.

• 75 ел элек (1940)

8 февральдә Татар дәүләт академия театрында Нәкый Исәнбәтнең «Болак арты республикасы» исемле пьесасы буенча спектакль куела.

• 70 ел элек (1945)

19 февральдә Көнчыгыш Пруссиядә Бөек Ватан сугышы фронтында күренекле шагыйрь Фатих Кәрим (1909-1945) батырларча һәлак була.

• 60 ел элек (1955)

«Совет әдәбияты» журналында Фатих Кәримнең 1943 елның май-июнь айларында Хәрәкәттәге Армия шартларында язылган «Шакир Шагаев» исемле 4 пәрдәлек пьесасы басылып чыга.

• 55 ел элек (1960)

«Совет әдәбияты» журналында Җәвад Алмазның «Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастаны» исемле мәкаләсе дөнья күрә.

• 50 ел элек (1965)

16 февральдә Казанның Совет районы мәдәният йортында Нәкый Исәнбәт иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә уза. Әдипнең тормыш һәм иҗат юлы хакында Габдулла Шамуков нотык тота.

• 45 ел элек (1970)

1 февральдә «Социалистик Татарстан» газетасында Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур» исемле яңа романыннан өзекләр басыла башлый.

Илдар Касыйм улы Зарипов 1939 елның 13 нче ноябрендә Казанда туа. Казан сәнгать училищесын (1961) һәм В.И.Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт сәнгать институтын тәмамлый. 1970 елдан — Россия рәссамнар берлеге әгъзасы.

1976 елдан ТАССРның атказанган Сәнгать эшлеклесе, 1983 елдан исә РСФСРның атказанган рәссамы. 1994 елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 2002 елдан — Россиянең халык рәссамы. Әсәрләре Россиянең һәм чит илләрнең шәхси вә дәүләти тупланмаларында саклана.

Илдар Зарипов 2012 елның 14 июнендә вафат булды.

ИЛДАР ЗАРИПОВ (1939 -2012)

«Көз кызы». Киндер, майлы буяу

«Хуш исле чәчәк». 1993-1997. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САННАРДА:

«Яхшы, мәгънәле сүзгә колак салу, игътибарлы булу мөһим. Кем әйтсә дә... Шигырьләр аша кешегә күп мәгълүмат, тирән фикер җиткереп була. Җиткерергә кирәк тә! Яхшы сүз, мәгънәле сүз барыбер үзенә җәлеп итә».
МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ. «ЯШӘҮ МӘГЪНӘСЕ».

«Син миңа шулхәтле матур рәсем җибәргәнсең. Аның аркылы мин сине күз алдымда басып торган төсле ачык күрәм. Диңгездә коенганыңны да күрәм, комда кызынганыңны да күрәм; кипарисларга тотына-тотына «Яңа Афон»ның биек ярыннан акрын гына югарыга атлап менгәнеңне дә күрәм».
МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ МОҢАРЧЫ ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТТА ДӨНЬЯ КҮРМӘГӘН БИШ ХАТЫ.

«1945 елның көзендә «Ура!» кычкырып Шәлегә кайтып кергәндә минем әти булмаган әле ул...»
КАМИЛ КӘРИМОВ. «ЯЗЫЛМАГАН КЫЙССА».

«Бохараны буйсындырганнан соң, Чыңгыз хан шәһәр халкына болай ди:
– Бик күп гөнаһлар кылганыгызны сез үзегез дә беләсез һәм үз арагыздагыларның нинди гөнаһлар эшләгәнен дә күреп торасыз. Моны ни өчен сөйләгәнемне сорасагыз, әйтермен: сезне җәзалар өчен мине Тәңре үзе җибәрде!»
РАБИТ БАТУЛЛА. «КЕМНӘР СОҢ БЕЗ – ТАТАРЛАР?»

Индекс:
Татарстанда – 54132
Россиядә – 70275

Башкалабыз Казанда «Безнең мирас» журналын «Книги-Китаплар» (Бауман урамы, 29/11) кибетеннән сатып алырга мөмкин.

4 612750 670172